"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы МБМБУ “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы”

**Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче тәрбиячеләр өчен , татар теле укытучылары һәм әти - әниләр өчен методик ярдәмлек**

# ОНЫТЫЛЫП БАРГАН ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ҺӘМ ЙОЛАЛАР



**Казан, 2024**

**Төзүче авторлар:**
Яруллина М.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе ярдәмчесе;
Габдрахманова Р.Г. - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе мәктәпкәчә белем бирү методисты;
Гыймадиева Л.М. - "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә "Йолдыз" мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе мөдире;
Яруллина А.Р. - "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә "Йолдыз" мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе өлкән тәрбиячесе.
"Онытылып барган гореф – гадәтләр һәм йолалар": тәҗрибә уртаклашу җыентыгы. /төз.авт: Яруллина М.Р., Габдрахманова Р.Г., Гыймадиева Л.М.,Яруллина А.Р. – Казан, 2024.- 104 б.

Рецензент : Төхфәтуллина Ә.Г. – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы "Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте" дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Җыентык туган телдә белем һәм тәрбия бирүче педагоглар өчен ярдәмлек булып тора.
Язмаларның эчтәлеге һәм дөреслеге өчен авторлар җаваплы.

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе белән берлектә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы МБМБУ “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” коллективы төзегән “Онытылып барган гореф – гадәтләр һәм йолалар”: тәҗрибә уртаклашу җыентыгына

# БӘЯЛӘМӘ

Авторлар тарафыннан тәкъдим ителгән җыентык мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларда этномәдәни компетенция тәрбияләү һәм милли традицияләребезгә хөрмәт хисе үстерү максатын тормышка ашыруга юнәлтелүе белән *актуаль.* Анда балаларга халкыбызның мәдәни байлыгын өйрәтү бурычы фольклор мирасыбыз булган йолалар, гореф-гадәтләр аша хәл ителә. Чөнки бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән рухи хәзинәләребезне саклап калу, онытыла башлаган гореф-гадәтләр, уеннарыбызның, иң матурларын сайлап алып, киләчәк буынга өйрәтү – мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе педагоглары алында торган иң мөһим бурычларның берсе.

Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче тәрбиячеләр өчен тәкъдим ителгән җыентыкның *максаты:* татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары аша балаларның милли узаңын үстерү, туган халкына, туган теленә карата горурлык хисе, хөрмәт тәрбияләү.

“Календарь йола бәйрәмнәре”, “Гаилә йола бәйрәмнәре”, “Дини бәйрәмнәр” дигән өч бүлеккә тупланган чаралар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның кызыксынучанлыкларына, яшь үзенчәлекләренә карап, аларда рухи күтәренкелек тудыру, актив эшчәнлеккә дәртләндерү, мөстәкыйльлек үстерү принцибы буенча сайланган. Педагогик яктан да, әһлакый, физик һәм тел үсешенә ярдәм итү ягыннан да уңышлы сайланган чаралар һәр баланың игътибарын җәлеп итәр, телгә кызыксыну арттырыр дип уйлыйбыз.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, “Онытылып барган гореф – гадәтләр һәм йолалар” дип аталган тәҗрибә уртаклашу җыентыгы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә милли тәрбия бирү юнәлешендә эшләү өчен файдалы һәм кирәкле чыганак. Аның аша балаларга халкыбызның гореф-гадәтләре, әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында мәгълүмат бирү белән беррәттән, туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү; милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу; халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе кебек мәсьәләләр дә хәл ителер дип уйлыйбыз.

*Төхфәтуллина Ә.Г.* – Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, филология фәннәре кандидаты.

## ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР – ИҢ ЯХШЫ ТӘРБИЯ ЧАРАСЫ

Һәркемгә дөньяда беренче аваз салган, беренче тапкыр тәпи йөреп киткән туган йорты, туган авылы, аның халкы, гореф-гадәтләре якын. Һәр халыкның үз иткән бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, йолалары була.Бу йолалар – шул халыкны бердәм милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Гореф-гадәтләр, йолалар халык тормышының, мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Алар зәгыйфләнә икән, халыкның мәдәнияте, яшәеше дә гарипләнә. Борынгыдан килгән йолаларыбыз инде онытыла, юкка чыга баралар дип әйтсәләр дә, әле халкыбызның хәтерендә, өлкән буын кешеләренең телендә бик күп истәлекләр, тел һәм рухи байлыгыбыз саклана. Борынгыдан килгән йолалар һәрвакыт төрле ырымнар, серле тылсымлы такмаклар яки җырлар белән үрелеп бара һәм алар шул йоланың аерылмас бер өлеше, аның бизәге булып та торалар. Ел фасылларына караган йолалар һәм бәйрәмнәрнең тарихы бик ерактан килә. Алар буыннар арасында дәвамлылык, бер-берсеннән өйрәнү, үрнәк алу, бердәм рухи халәт тудыруга хезмәт итәләр. Бәйрәмнәр алар күп кешеләр катнашып уздырыла торган күмәк күренеш һәм кешеләр арасында уртак рухи бәйләнеш булган очракта гына бәйрәм төсе барлыкка килә. Кеше һәрвакыт бәйрәмнәрне, рухи бәйләнешне һәм уртаклыкны кирәксенгән. Халык бәйрәмнәре, аларга караган күп кенә гореф-гадәт, йолалар шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләренә күнектерү чарасы да булып хезмәт итә. Бу чараларда халыкның олысы-кечесе теләп катнаша. Һәр буын кешесе анда катнашу тәртибен гадәт, традиция рәвешендә үзенә сеңдерә һәм кайда гына булса да, бу традицияләр аны туган нигезенә тартып тора.

Балалар бакчасында гореф-гадәтләр аша тәрбия бирү бүгенге көндә бик актуаль. Онытылып барган йолаларны торгызу, әти – әниләргә, балаларга җиткезү безнең төп бурычыбыз. Бу җыентык та Рәсәй күләмендә “Гаилә елы” уңаеннан педагоглар һәм әти – әниләр өчен тәкъдим ителә.

**Яруллина Миләүшә Рәшит кызы,**
Мәгариф бүлеге җитәкчесе урынбасары,
**Габрахманова Рамилә Гомәр кызы,**
Мәктәпкәчә белем бирү методисты.

# КАЛЕНДАРЬ ЙОЛА БӘЙРӘМНӘРЕ



# КАРГА БОТКАСЫ

***Гайфуллина Рәмилә Әмирҗан кызы***

*Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы*

*«Гомуми үсеш төрендәге 4 нче “Сандугач”*

*балалар бакчасы”тәрбиячесе*

Зал бәйрәмчә бизәлә. Түрдә кояш, кошлар сүрәтләре төшерелгән. Матур көй уйнатыла. Балалар залда утыралар. Залга Көн белән Төн керә.

Көн: Исәнме, төнкәем!

Төн: Ярый әле син бар, көнкәем!

Көн: Мин дә сине бик сагындым, төнкәем.

Төн: Янар йолдызларым, көмеш аемнан сиңа сәлам китердем.

Көн: Туган ягыбызга яз килә! Бәйрәм белән тәбрик итәм сине, төнкәем.

Төн: Бүген мин кыскарам, ә син озыная барасың.

Көн: Күңелләрдә сагыну хисен тагын да көчәйтәсең икән, төн дустым. Ә мин, сине сагынып, гөрләвекләрмне агызырмын. Тирә-юньне, урман буйларын кардан арындырып, сиңа беренче чәчәкләремне – умырзаяларымны бүләк итәрмен. Яз килә, яз килә! Тиздән җылы яклардан кошлар кайтып, тирә-юньне үзләренең моңлы җырларына күмәрләр.

Төн: Кырлар, басулар кардан ачылгач, язгы кыр эшләре башланыр.

Көн:  Еллар тыныч булсын!

Игеннәр мул булсын!

*“Яз җитә” җыры*

Көн б/н төн: Балалар, карагыз әле, Кара каргалар килгән, алар яз киләсен хәбәр итүчеләр.

Кара каргалар. Исәнмесез, балалар!

Көн: Кая таба очасыз?

1 Кара карга:

Ачылды ак калын юрган,

Исә язгы җилләр дә,

Без кайтабыз сагындырган

Туган үскән җирләргә.

2 Кара карга:

Көннәрне юлда үткәреп,

Куанышып сезгә очтык,

Канатларга күтәреп,

Сезгә яз алып кайттык.

1 Кара карга:

Көннәр аяз, күктән алсу

Нур сибеп кояш көлә,

Җиргә тама көмеш тамчы,

Сагынып көткән яз килә!

2 Кара карга:

Әйтегезче, кайсы вакыт

Яздагыдан ямьлерәк?

Кыш айларын да яратам

Әмма яз күңеллерәк!

1 Кара карга: Әйдәгез әле, балалар, “Очты, очты, каргалар!” уенын уйнап алыйк. Нинди кошларны беләсез икән, сынап карыйк.

*“Очты, очты, каргалар!” уены*

Балалар түгәрәк ясап басалар. Алып баручы түгәрәкнең уртасына чыга һәм: “Очты, очты, казлар очты!” – дип, кулы белән очкан сыман хәрәкәт ясый. Башкалар аның артыннан кабатлый. Шулай берничә кат оча торган кошларны, әйберләрне 9самолет, вертолет, шар һ.б.) очыргач, искәрмәстән генә: “Очты, очты, курчаклар очты!” – дип очмый торган берәр әйбернең исемен атый.Бу вакытта түгәрәктәгеләр кулларын күтәрмәскә тиеш.

Көн:  карагызчы, нинди матурлык, җиргә ямь биреп, Яз килә, Яз килә!

Яз. Исәнмесез, балалар!

Балалар. Исәнме, Яз!

Яз. Гайбәт бетсен телегездә,

Орыш бетсен илегездә

Ачу китсен йөзегездән-

Шулай икән, киләм сезгә!

Балалар. Яз килә, яз килә...

Яз. Бурычларны кичерегез,

Дошманнарга кул сузыгыз,

Шуның белән мәрхәмәткә,

Йөрәгемә юл салыгыз,

Шулай икән, киләм сезгә!

Балалар. Яз килә¸ яз килә...

Яз. Котлап сәлам бирдегез,

Мине көтеп алдыгыз,

Имин йортта торыгыз,
Кәеф-сафа корыгыз.
Инде мине тыңлагыз,
Моңаеп утырмагыз –
Уйнагыз да көлегез,
Биегез дә җырлагыз!
Көн:
Әй, дуслар, килегез,
Күңел ачу көнебез
Татарча матур итеп
Без биибез, күрегез!
*Татарча бию.*
Төн:
Яз иртәсен котлагандай матур булып,
Зәңгәр күкне каплап алды зәңгәр болыт,
Бизәкләгән төсле булды бөтен һава,
Кар өстенә шыбыр-шыбыр Ләйсән ява!
Кечкенәләр белән *“Кояш белән яңгыр” уены* уйнала.
Тәрбияче: “Әйдәгез, балалар, шундый матур кояшлы көндә уйнарга чыгыйк!” – ди. Балалар матур көйгә зал буйлап йөриләр, кулларын чәбәклиләр. Тәрбияче: “Яңгыр килә!” – диюгә, тәрбияче тоткан кулчатыр астына йөгереп килеп качалар. Уен берничә тапкыр кабатлана.
Көн:
Әй, дуслар, килегез
Күңел ачу көнебез,
Әйдәгез, күмәкләшеп,
Әйлән-бәйлән уныйбыз!
“Март-апрель” әйлән-бәйлән уены.
1. Кара каргалар килә, } очу хәрәкәтләре
Түбәдән тамчы тама, } бармак очлары белән чүгәләп идәнгә чиртәләр
Көндез көн җылы була, } куллары өстә чайкала
Суыта кичкә таба. } чүгәлиләр
Тамчылар бии тып та топ, } уң кул бармакларын сул кулның учында уйнаталар
Аларны булмый туктатып, } урыннарында сикерәләр
Алар яз китерәләр. } кул чабалар

2. Гөрләвекләр агалар, } ике кулны кушып дулкын сыман хәрәкәт ясыйлар

Күктә кояш елмая. } кулларын як-якка җәяләр

Каңгылдашып торналар, } кулларын өскә күтәрәләр

Төзелеп үтте бая. } очу хәрәкәтләре ясыйлар

Инешләрдә коена } чуму, йөзү хәрәкәтләре

Канатланып үрдәк, каз. } канынган хәрәкәтләр ясыйлар

Җирне яшәртеп безгә, } кул чабалар

Гөлләр алып килә яз. } кул чабалар

Хуҗа Насретдин керә.

Төн: Әссәламегаләйкем, Хуҗа Насретдин!

Хуҗа Насретдин. Вәгаләйкем әссаләм! Исәнмесез! Әйтегез әле, бу Буа базары буламы?

Балалар: Юк!

Хуҗа Насретдин: Бик зур күренә! Казан базарыдыр, ахрысы! Сөбханалла!

Төн: Хуҗа Насретдин, бу базар түгел, бу бит балалар бакчасы.

Хуҗа Насретдин: Яхшы, яхшы, миңа бакчада да ярый. Бакча булгач, анда ял итеп тә алырмын.

Көн: Хуҗа Насретдин! Ә бүген бездә бәйрәм. Ә сез безнең олы кунагыбыз булырсыз. Сезне бик күп мәзәк, мәкаль, табышмак, такмаклар белә дип ишеткән идек. Безгә дә сөйләмәссез микән?

Хуҗа Насретдин: Була ул, тыңлагыз! Мин мәкальне башлармын, сез тәмамларсыз.

Тырышкан табар... (Балалар: Ташка кадак кагар)

Кем эшләми... (Балалар: Шул ашамый)

Ялкау утырып йоклый... (Балалар. Ятып ашый)

Төн: Ә хәзер ,әйдәгез, уйнап алыйк.

Зур төркемдәге балалар белән уеннар оештыру:

*"Җир сукалау" уены*

Уенда ике бала катнаша. Алар залның бер ягында, ә залның икенче ягына – озын бау бәйләнгән уенчык тракторлар. Уйнаучылар, тәрбияче сигналы буенча, бауны йомгакка чорный-чорный, тракторларны үзләренә таба тартып китерәләр. Тракторы алдан килгән бала җиңүче була.

*"Бәрәңге утырту" уены*

Балалар ике колоннага тезеләләр. Каршыга, ара калдырып, ике рәт кыршаулар тезелә. Ике кәрзингә кыршау саныннан бәрәңге салына һәм Һәр төркемнең беренче уйнаучыга тапшырыла. Сигнал булгач, беренче уйнаучы һәр чокыр саен кәрзиннән бәрәңге алып сала. Аннан соң, йөгереп килеп, кәрзинне икенче уйнаучыга тапшыра. Икенче уйнаучы

бәрәңгеләрне кәрзингә җыя һәм йөгереп килеп өченче уйнаучыга ташара. Уен шулай актык уйнаучыга кадәр дәвам итә. Бәрәңгене беренче утыртып бетергән төркем җиңүче була.

*“Түбәтәй” уены*

Көн:

Яшьләр өчен шатлык син,
Картларга да тансык син,
Халык үлмәс-син үлмәсәң,
Мәңге яшә, Насретдин!
Биеп алчы, Насретдин!
Ялындырма, Насретдин!

*Насретдин бии.*

Хуҗа Насретдин.
Миңа китәргә кирәк,
Атым, кузгал, юлга,
Төшке намазым кала!

Төн: Кырлар, басулар кардан ачылгач, язгы кыр эшләре башланыр. Әйдәгез әле карга боткасы белән сыйланыйк. Иң беренче кашык – туган җиребезгә!

Әйтче, иң матур җир кайда?
Син бит инде беләсең?
Иң матур җир - Туган җир ул,
Онытма моны, балам!
Еллар тыныч булсын!
Игеннәр мул булсын!

Көн: Икенче кашык – һавага, яңгырларын вакытта яудырсын, уңышларны зур итеп үстерсен.

Балалар: Яңгыр, яу, яңгыр яу,
Иләкләп, чиләкләп,
Пәрәмәчләп, коймаклап.
Арышларның башагы
Ач булмасын, тук булсын,
Сыерларның сөтләре
Аз булмасын, күп булсын!

Төн: Өченче кашык – кояшка, җылы, кояшлы көннәр күп булсын, безне, кошларны, җәнлекләрне сөендерсен.

Балалар: Кояш чык, чык,

Майлы ботка бирермен,

Майлы ботка казанда.

Тәти кашык базарда.

Кирәкми безгә салкын,

Кирәк безгә саф алтын.

Көн: Дүртенче кашык – каргаларга, алар безгә язны алып килделәр,

Яратыгыз көзне дә,

Яратыгыз кышны да,

Яратыгыз җәйне дә,

Яратыгыз язны да.

Яратыгыз көннәрне,

Айларны һәм елларны,

Кешеләрне, табигатьне,

Саклагыз сез аларны.

Көн: Еллар тыныч булсын!

Игеннәр мул булсын!

Төн:

Алдагы көннәрегездә

Телибез зур уңышлар.

Муллыкта, тыныч тормышта

Хезмәт итегез, дуслар!

*“Бәхеттә, шатлыкта” җыры*

“Бәхеттә, шатлыкта” җыры белән бәйрәм тәмамлана.

## КАРГА БОТКАСЫ

***Гарифҗанова Гөлнара Рәүф кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*

*"Яңа Кенәр балалар бакчасы"муниципаль бюджет*

*мәктәпкәчә белембирү учреждениесенең тәрбиячесе*

*Сәхнәгә алып баручы чыга.*

**Алып баручы:** Татар халык календаренда иң популяр , иң күңелле язгы бәйрәмнәрнең берсе - һичшиксез , Карга боткасы. Борын-борын заманда кешеләр нилектән җирдә яз булганын белмәгәннәр, ди . Алар ямьле язны җылы яклардан кара каргалар алып килә икән дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп сулар ага башлагач, табигать яңаруга –яшәрүгә йөз боргач , каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны “Карга боткасы” дип атаганнар. Бу көнне балалар матур итеп киенеп йомырка җыйганнар, хуҗаларга рәхмәт әйтеп изге теләкләр теләгәннәр, авыл халкын бәйрәмгә чакырганнар. Шулай итеп балалар ярма, май, сөт алып, табигатьнең иң күркәм җиренә - су буйларына, ялан-кырларга яки тау битләренә җыела торган булганнар. Анда казан асып ботка пешергәннәр. Ботка пешкәнче, төрле уеннар уйнаганнар, җырлар җырлаганнар, такмаклар, табышмаклар әйтешкәннәр. Аннан соң бергәләп , ботка ашаганнар. Ботканы балалар үзләре генә ашап бетермәгәннәр, өйләренә кайтып киткәндә: “Рәхмәт , кошкайлар, безгә язны алып килдегез!” – дип, каргаларга да калдырып кайтып китә торган булганнар.

Балалар бу көнне бәйрәмгә хас булган теләү-теләүләр әйткәннәр, җирдән муллык, күктән яңгыр, кояштан җылылык, табигатьтән бәрәкәт, илгә туклык, гайләгә иминлек теләгәннәр. Җаннары- тәннәре белән кояшлы җылы көннәрнең тизрәк килүен, язгы ташуларның тизрәк агып китүен көткәннәр.

Хөрмәтле кунаклар һәм балалар! Менә хәзер без сезгә шушы борынгы бәйрәмне, яз бәйрәме – **“Карга боткасы”**н үзебезнең балалар бакчасында уйнап күрсәтербез.

Хөрмәтле дуслар, **“Карга боткасы”**на рәхим итегез!

*Салмак матур көй уйный.*

**1 нче бала:** Ачылды ак калын юрган,
Иcте апрель җилләре.
Кошлар кайта - сагындырган
Туып үскән җирләре.

**2 нче бала:** Көннәрен юлда үткәреп,
Куанышып очалар.

Канатларына күтәреп,

Яз китерә ич алар.

**3 нче бала:** Ямьле, бик ямьле

Туган илебез.

Килегез кошлар,

Безгә килегез!

*“ Кошлар биюе ”*

*Карга булып киенгән ике бала керә. Канатларын җилпи- җилпи , карр , карр , дип йөриләр.*

**4 нче бала:** Кара әле , дустым , кара ,

Кара карга очып бара.

Син беләсеңме,

Ул да бит сөйләшә ала.

**1 нче карга:** Ачылды ак калын юрган ,

Исә язгы җилләр дә.

Без кайтабыз сагындырган,

Туып , үскән җирләргә.

**2 нче карга:** Без каргалар **,** карр – карр ,

Тиздән эреп бетәр кар.

Канатымда хатым бар ,

Буең җитсә , тартып ал.

**Алып баручы :** Укымый да беләбез бит

Хатыңда ни язылганын!

Бөтен кошлар һәм балалар

Матур язны сагынганын.

*“Тургайлар” җыры башкарыла.*

**1 нче бала:** Әй , балалар , әйдәгез , каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясыйк , карга боткасы пешерик. Башта өйдән өйгә йөреп , карга боткасына сый җыйыйк .

*Балалар , чиләкләрен тотып , җырлый – җырлый сый җыярга китәләр .*

**Балалар :** Җырлыйк әле ,

Җырлыйк әле ,

Җырлыйк әле алтыны.

Җырласаң да килешәдер –

Бүген бит бәйрәм көнне. *( Бер тәрәзә каршына туктыйлар , шакыйлар)*

**2 нчы бала :** Өйдәме , түтәй ?

Җәтрәк бир күкәй.

Бирсәң безгә өч күкәй ,

Тавыгың салыр йөз күкәй.

**Барысы бергә :** Май кирәк , ярма кирәк ,

Карга туена бар да кирәк .

**3 нче бала :** Тагын булса он чыгар ,

Пешерербез без чумар .

Шикәр кирәк , тоз кирәк ,

Чыгар , түтәй , тизрәк !

**Барысы бергә :** Синең кебек унган түтәй

Бу дөньяда бик сирәк.

**Түтәй:** Бирәм , балалар , мәгез ,

Күпме кирәк алыгыз.*( Сый бирә)*

**Балалар:** Рәхмәт сиңа , түтәй ,

Кулың – аягың сызлаусыз булсын , йөз яшә !

**Түтәй:** Амин , шулай булсын !

*Балалар җырлап башка өйгә китәләр.*

**4 нче бала:** Тәрәзәмдә гөлләр үскән ,

Гөл яфрагын кем өзгән ?

Уйнамыйча , җырламыйча

Бу дөньяда кем үскән ?

*(Тәрәзә шакыйлар)*

**5 нчы бала:** Әби , бабай өйдәмесез ?

Бер йомырка бирәмсез ?

Бер йомырка бирсәң ,

Тавыгың салып утырсын ,

Иләк – чиләк тутырсын ,

Йомыркагыз күп булсын.

**Ак әби :** Мәгез , мәгез , балалар ,

Бәйрәмегез котлы булсын !

**Балалар барысы бергә . Рәхмәт әби !**

**Ак әби:** Балалар , әйдәгез , *“ Чума үрдәк , чума каз”* дигән җырлы-биюле уен уйнап алыйк әле.*( Җырлы- биюле уен уйнала ).*

**6 чы бала :** Сый җитәрлек булды , карга боткасын пешерергә кай җиргәрәк барыйк икән ?

**7 нче бала:** Чыпчык чыбыгым , ди ,
Карга каеным , ди.
Киттек каенлыкка !

*( Карр , карр , дип кычкырып , Ак әбине ияртеп , сый җыйган балалар кулларында чиләкләр казан , утын һәм чыбык – чабыклар тотып ботка пешерергә китәләр)*

**8 нче бала :** Ә , әбекәй , әбекәй ,
Пешер безгә тәмлекәй .
Пешер безгә ботка да ,
Пешер безгә әлбә дә ,
Тагын булсын күкәй ,
Шикәр белән тәмле чәй ,
Рәхмәт әйтеп , әбекәй ,
Без итәрбез чәбекәй .

**Ак әби :** Булыр , балалар , бары да булыр.
Карга килер – казан асар ,
Торна килер – тоз салыр ,
Саескан килер – салма салыр ,
Песнәк килер – пешерер ,
Чыпчык килер – тикшерер ,
Карга ашап – бетерер .
Кап та коп !

*( Көлешәләр . Учак тирәсендә кайнашалар)*

**Алып баручы:** Ак әби , балалар , безгә бит балалар бакчасы балалары безнең бәйрәмебезгә кунакка килгәннәр. Ә үзләре белән матур-матур җырлар, шигырьләр, җырлы-биюле уеннар өйрәнеп килгәннәр. Әйдәгез , ботка пешкән арада кунакларыбызның чыгышларын карап үтик.

Хуш киләсез , үтегез,
Түрдән рәхим итегез.
Бездә бүген зур бәйрәм,
Уйнагыз әйлән-бәйлән.

*“ Чебиләр биюе ” башкарыла*

**Алып баручы :** Әйтегезче, кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк ?

Кыш айларында яратабыз

Әмма яз бит күңеллерәк.

*“ Яз , яз , яз җитә ” җыры башкарыла*

**Алып баручы :** Агачлар яфрак яра,

Алмагачлар чәчәк ата.

Тургайлар тугайларын ,

Сагынып кире кайта.

*“Җырчы кошлар” җыры башкарыла .*

**Шигырь :** *“ Каргалар теле”*

Күктә бик күп карга

“ Кар” , “кар” килә бар да

Телләрендә шул сүз

Кунсалар да талга.

Әни әйтә : “ Димәк,

Тиздән яңгыр явар

Әнә шулай “ Кар” , “кар”

Яңгыр тели алар.

**Җырлы – биюле уен :** *“ Тамчы там , там , там.”*

**Алып баручы :** Ә хәзер мин сезгә *“Шук малай”* шигырен сөйләп үтәрмен .

Тал агачына
Менеп бер бала
Кара карганың
Баласын ала
Аннан ояны
Түгел зыянлы”.

Вата , туздыра,
Шуклыкта Гали
Барысын уздыра.
Әйләнеп оча
Карга “ кар да, кар”.

Гүя әйтә ул.
“ Зур куркыныч бар.
Нигә ватасың
Минем оямны?
Мин сезнең өчен

**Алып баручы :** Балалар , сезнең арагызда Гали кебек балалар юкмы ? Яз хәбәре алып килүче кара каргалар авыл хуҗалыгы өчен күп файда китерәләр. Мәсәлән , җәенә бер кара карга чама белән 8 меңгә кадәр бөҗәкне ашый. Бер өер карга көненә чама белән 6 га басуны бөҗәкләрдән чистарта. Алар урман хуҗалыгына май коңгызларына каршы көрәштә зур ярдәм итәләр. Кара каргалар яфраклар һәм үләннәр арасына төшкән коңгызларны эзләп ашыйлар.

- Балалар , кара каргалар кебек үк башка кошлар да бик файдалы. Шуларныңберсе - **Тукран .** Ә хәзер*“ Тукран”*турында шигырь тыңлап үтәрсез.

*Тукран*

Чуп – чуар тукран

Агачка кунган

“ Тук” та “тук” чукый

Кортларны чүпли.

Корттан арынгач,

Шәп үсә агач.

**Алып баручы:** Менә балалар ни өчен тукранны урман доктары диләр. Ул үзенең үткен томшыгы белән агач кәүсәләрен тикшерә , ябыштыручы озын теле белән кайры астыннан кортларны чүпли.

**Алып баручы:** Ямьле яз башланды . Яз хәбәрчеләре – кара каргалар килде дә инде. Тиздән сыерчыкларда килер дусларым. Сез алар килүгә оялар ясадыгызмы соң?

**Балалар** (бергә). Әйе , ясадык!

**Алып баручы:** Булдыргансыз, балалар. Әйдәгез дусларым, хәзер балаларының сыерчыклар турында өйрәнгән шигырьләрен һәм җырларын тыңлап үтик инде.

*Унган сыерчык .*

Ак буяулы бер оя бар Шунда тора, шунда йоклый,

Бакчада зур агачта, Шунда бала үстерә

Очып килә шул ояга Матур итеп сузып сайрый

Сыерчык яз булгач та Басып оя өстенә.

*“Сыерчык”(Җыры башкарыла).*

**Алып баручы:** Дусларым, сез кошларны таный беләсезме ? Менә безнең балалар кошлар турында табышмаклар да өйрәнеп килгәннәр , әйдәгез сезнең белемнәрегезне тикшереп карыйк.

Канатларын җәя итеп

Ук шикелле оча ул

Очып барган җирдән генә

Бөҗәкләрне тота ул.

Үреп ясый оясын,

Кәрзиндер дип торасың.*(Карлыгач )*

Ялтыравык әйберләрне

Ташый ул оясына

“ Карак” дигән яман аты

Чыккандыр менә шуңа.

Беләсеңме син ул кошның

Ни исемле икәнен? *( Саескан )*

Үзе озын , чабуы кыска. *( Торна )*

Ука-Ука тыш кына,
Су коена иңештә,
Оча алсада , җирдә йори,
Ите яхшы бәлешкә. *( Үрдәк)*

Кыш һәм җәй буе
Кызыл читек кигән,
Күк ефәктән күлмәге
Ул һәркемнең сөйгәне *( Күгәрчен )*

Суда юынып алды,
Өсте коры калды. *( Каз )*

Кулы юк , балчык ташый,
Балтасы юк , оя ясый. *( Карлыгач )*

**Алып баручы :** Бар нәрсә йокыга талгач,
Бакчалар тынып калгач,
Куактан куакка кунып,
Сайрый сары ... ( Сандугач ).

*“ Сайра сандугач”* җыры башкарыла.

**Алып баручы :** Әйдәгез , мәкаль әйтеш уйныйбыз.

*( Балалар түгәрәкләнеп басалар. Алып баручының кулында төйнәлгән кулъяулык.)*

**Алып баручы :** Мәкаль башлыйм , син төгәллә ,
Әгәр тапсаң сүзләрен.
Я , әйдәгез , кемнәр тапкыр
Күрсәтсеннәр үзләрен.

**Алып баручы:** Мин мәкаль әйтүче булам. Мәкальнең беренче яртысы минем телемдә, икенче яртысы шушы төендә. Хәзер мин яулыкны кайсыгызга булса да ыргытырмын, яулык тигән кеше тиз генә шул мәкальнең икенче яртысын әйтеп өлгерергә тиеш . Әйтә алган кеше мәкаль төенен чишкән дип санала, әйтә алмаучыга җаза бирелә . Башладык!

1. Кош канаты белән - Кеше дуслары белән көчле.
2. Язгы көн – ел туйдыра.
3. Бер карлыгач – яз ясамый .
4. Ни чәчсәң - шуны урырсың .
5. Каз килсә – яз килә .

6. Карга килсә – кар китәр .
7. Язгы хезмәт – көзге хөрмәт .
8. Һава, су , кояш – безгә юлдаш

Алып баручы : Көннәр аяз , күктән алсу

Нур сибеп кояш көлә,

Җиргә тама, көмеш тамчы

Сагынып көткән яз килә!

*“ Кил син язым”җыры башкарыла*

**Алып баручы:** Дусларым , ә хәзер абыйларыгыз сезгә, безнең нәни кошларыбыз өчен, нинди матур оялар ясап бирүләре турында шигырь тыңлап үтәрбез.

*“Кошлар туйдырам”*

Җимлек ясап бирде миңа

Абыем сәлим

Шунда хәзер кошлар өчен

Җимнәр сибәм мин.

Бире килә күк күгәрчен,

Песнәк һәм чыпчык.

Җыелалар бер-бер артлы

Пыр-пыр очынып.

Алып баручы : Гөлдер –гөлдер , гөлдер бу,

Кызыл тәпи кемдер бу?

-Әйе , бик дөрес - бу күгәрчен.

Җырлы-биюле уен: *“ Әйт күгәрчен”.*

Әйт күгәрчен , син генә

Яшь кызлар ничек йөри ?

Ул шулай да ул болай

Яшь кызлар йөри шулай.

Куяннар ничек йөри?

Каргалар ничек оча ?

Үрдәкләр ничек йөри ?

Сандугач ничек ничек сайрый?

**Алып баручы**: Дусларым, яз җиткәч җылы яклардан кошлар гына түгел, ә бер-бер артлы тезелешеп, аккошлар да кайталар әле, күргәнегез бармы? Әйдәгез безнең малайларыбыз башкаруында *“ Нәни аккошлар”* биюен карап үтәрсез.

**Ак әби:** Балалар, уеннарыгыздан туктап торыгыз, ботка пеште, аш пеште, чәй кайнады.Табынга, балалар, табынга рәхим итегез.

**Ак әби** ( *ботка бүлә):*

-Менә бусы Җир – анага.
Җир атасы – җирән сакал!
Җир анасы – асыл бикә!
Түбәсенә туклыгың бир,
Тамырына ныклыгың бир,
Ил өстенә муллыгың бир,
Ил эчендә безгә дә бир!
-Менә бусы суга.
Су иясе тотмасын!
-Менә бусы күккә.
Яңгыр бирсен!
Кояшлы җылы көннәр бирсен!
Илгә туклык, гайләгә иминлек килсен!
-Бусы каргаларга.
Канат очларында язны алып килсен өчен. *( Җиргә сибә)*

-Ә калганы сезгә , балалар. Утырыгыз ашарга. Түгеп –чәчеп ашамагыз. Сыйланыгыз. Муллык килсен! Бәхет килсен!

*Балалар ботканы тәмләп ашыйлар.*

**1 нче бала :** Рәхмәт , әби , сыйладыгыз ,
Тагын шулай кыйланыгыз.

**2 нче бала :** Ашаттыгыз , эчерттегез ,
Җырлаттыгыз , биеттегез,
Кеше арасына керттегез.

**3 нче бала :** Рәхмәт сезгә ,
Килегез безгә ,
Киләсе көзгә
Суясы казга.
Сездә булса карга боткасы ,

Бездә булыр каз боты.

**Балалар бергә :** Рәхмәт сезгә ! Рәхмәт яусын !

**Алып баручы:** Хөрмәтле дуслар! Кунакларыбыз! Иң күңелле язгы бәйрәмнәрнең берсе – *“ Карга боткасы”* бәйрәме ахырына якынлашып килә.Әйдәгез әле , барыбыз бергә җыр белән озатыйк бу күңелле бәйрәмебезне!

Җырсыз җирнең яме юк ,
Җырсыз тормыш тәме юк
Җыр сулар һава кебек ,
Җыр яши , җыр – мәңгелек!

*Бәйрәм “ Кояшлы ил” җыры белән ( Л.Батыр-Болгари көе , Ә.Рәшитов сүзләре) тәмамлана*

.

## НӘҮРҮЗ – ЯЗГЫ БӘЙРӘМ

***Зарипова Алсу Рәис кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*“Бөреле “Тиенкәй” балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе*

Залга милли киемнәр кигән кыз һәм малай керә

**Малай**: Тыңлагыз, тыңлагыз!
Табигать патшасының боерыгы бар!

**Кыз**: Дусларым, дускайларым,
Житте ич Нәүрүз айлары.
Эшегезне ташлагыз,
Бәйрәмгә ашыгыгыз.

**Бергә**: Нәүрүз котлы булсын!
Нәүрүз котлы булсын!

**(Башка балалар белән алып баручы чыга.)**

**Ал.б.:** Исәнмесез, балалар, хөрмәтле кунаклар! Менә салкын кыш үтеп китте, ямьле яз җитте. Яз белән Нәүрүз бәйрәме килеп җитте. Дуслар, әйдәгез бәйрәмгә сый җыйык, барлык кешеләрне бәйрәмгә чакырыйк.

**(Балалар парлап өйдән-өйгә сый-хөрмәт җыеп йөриләр).**

**Бала:** Торыгыз, тор, хуҗалар!
Нәүрүз җитте, беләсезме?
Нәүрүзчеләр килде сезгә,
Нәрсә безгә бирәсез?

**Бала:** Әгәр булмаса акчагыз,
Йөзегез кызартмагыз,
Ни булса да бирегез,
Нәүрүз котлы булсын!

**Әби:** Кем бар анда? Исәнмесез, балалар!

**Бергә:** Исәнмесез!

**Әби:** Гөрләп тора ишек алдым.
Җырлап тора матур көйгә.
Нәүрүз килә, Нәүрүз килә
Теләк теләп матур көйгә.

**Бабай:** Хуш киләсең, Нәүрүз!
Бирим әле сезгә күкәй, май.
Бәйрәм көнендә шатланып,
Рәхәтләнеп күңел ачыгыз.

**Балалар:** Рәхмәт! Сау булыгыз! **( китәләр, 2 нче кешенең капкасын шакыйлар)**

**Бала:** Әгәр булса көнегез,
Бардыр сезнең оныгыз.
Савап булыр, бирегез,
Нәүрүз котлы булсын!

**Бала:** Өйдәме түтәй?
Тизрәк бир күкәй!
Бирсәң безгә өч күкәй,
Тавыкларыгыз салыр йөз күкәй!

**Түтәй:** Хуш киләсең, Нәүрүз!
Менә сезгә күкәй, күмәч.
Бәйрәм белән сезне!

**Балалар:** Рәхмәт, түтәй, әйдә безнең белән бәйрәмгә.

3 нче өйгә баралар. Бер хатын белән кечкенә малай чыга.

**Бала:** Ач ишегең, керәбез,

Нәүрүз әйтә киләбез.

Нәүрүз котлы булсын!

Нәүрүз котлы булсын!

**Хатын белән малай:** Исәнмесез! Нәүрүз бәйрәме котлы булсын! Менә сезгә бал.

**Балалар:** Рәхмәт, әйдәгез безнең белән бәйрәмгә.

**Малай:** Әни, ә нәрсә соң ул Нәүрүз? Ул нинди бәйрәм?

**Хатын:** Улым, әйдә бәйрәмгә җыен. Нәүрүз бәйрәмен үз күзләрең белән күрерсең.

**Балалар:** Сау булыгыз! (Балалар китәләр, җыелган күчтәнәчләрне башка балаларга күрсәтеп чыгалар.)

**Ал.б.:** Менә күпме сый-хөрмәт җыелды! Бергәләп чәй эчәрбез.

Нәүрүз бәйрәме турында презентация күрсәтелә

**Ал.б.:** Нинди олы бәхет! Җыелышып уйнау, көлү, бию гел бергә.

Насыйп булсын иде сөенешеп, шатланышып яшәү гомергә.

**Бала:** Кыш китте, яз килде

Канатлы кошлар килде.

Нәүрүз бәйрәме килә,

Безнең җырлыйсы килә.

**Җыр: “Яз килә”.**

1) Җил җылы һәм иркә,

Кояш та елмая.

Бар дөнья уяна,

Бар дөнья уяна.

Кушымта: Яз килә, яз килә

Чәчәкләр уяна.

Йөрәккә яз килде,

Бар дөнья куана,

Бар дөнья куана.

2) Канатлы җырчылар

Моңлана талларда.

Бар дөнья уяна,

Бар дөнья уяна.

Кушымта: Яз килә, яз килә

Чәчәкләр уяна.

Йөрәккә яз килде,

Бар дөнья куана,

Бар дөнья куана.

**Ал.б.:** Әйдәгез, бергәләп Нәүрүзбикәне чакырыйк. Нәүрүзбикә!

**Нәүрүзбикә:** Исәнмесез, балалар, исәнмесез, кунаклар! Мин-Нәүрүзбикә, яз кызы. Сезгә яз шатлыгы алып килдем. Бәйрәм белән котлыйм.

**Ал.б.:** Нәүрүзбикә, без бик шат сине кабат күрүебезгә. Синең килүеңә табигать, барлык кешеләр дә шатлана.

**Нәүрүзбикә:** Бик зур рәхмәт! Ә мин сезгә "Зәңгәр чәчәк" уенын алып килдем.

**"Зәңгәр чәчәк"уены.**

1. Юл читендә зәңгәр чәчәк
   Якты нурлар тарата.
   Безнең кызлар һәм малайлар
   Зәңгәр чәчәк ярата. ( 2 тапкыр.)
2. Дус-ишләрең арасыннан
   Берсен сайлап ал әле.
   Тезләреңә ипле булсын
   Мендәреңне сал әле.

**Ал.б.:** Әйдәгез "Түбәтәй" уенын уйнап алабыз.

1. Түбәтәеңне кигәнсең,
   Бик ерактан килгәнсең,
   Төскә матурлыгың белән
   Шаккатырыйм дигәнсең.

Кушымта: Туп-туп-түбәтәй,

Түбәтәең укалы.

Чиккән матур түбәтәең

Менә кемдә тукталды.

**( Түбәтәй кемнең кулында кала, шуңа җәза бирелә.)**

1. Такмак сөйләтү;
2. Әтәч булып кычкырту;
3. Шигырь сөйләтү һ.б.

**Ал.б.:** Нәүрүз килә, Нәүрүз килә

Нәүрүзне зурлыйк әле.

Гөрләвекләр тавышына

Кушылып җырлыйк әле.

**Җыр “Нәүрүз”.**

1. Җирдәге бар мөселманнар

Бер-берсен ихлас котлый.

Иң изге теләкләр белән

Яңа елны каршылый. (2 тапкыр.)

Әй иркәли язгы кояш

Барсы елмая, көлә.

Кушымта: Һәммәбезгә саулык, ак бәхетләр генә юрап,

Нәүрүз бәйрәме килә, килә, килә, килә.( 2тапкыр)

Яз елмая, көлә, Нәүрүз бәйрәме килә. (3 тапкыр)

2. Яңа туган сабый сыман,

Һәркем бүген шатлансын.

Шушы бәйрәм күңелләрдә

Ел буена саклансын, саклансын.

**Ал.б.:** Тыпыр-тыпыр тыпырдап,

Бергә басаек әле.

Уйнап, көлеп, җырлап, биеп

Күңел ачаек әле.

“Татар халык биюе” (күмәк бию)

**Нәүрүзбикә:** Бик зур рәхмәт! Минем сезгә үтенечем бар. Табигатине саклагыз, елгаларның суы сакмасын, урманнардан кошлар китмәсен, зәңгәр күгебез гел аяз булсын, ә үләннәр гел яшел булсыннар. Сау булыгыз!

Балалар һәм олылар кереп китәләр. Әби белән бабай биеп калалар.

**Әби:** Мәҗлес яме кунак белән,

Табын яме коймак белән. Әйдәгез, бергәләшеп чәйләр эчик. (Кереп китәләр)

**ГАИЛӘМ МОҢЫ**

*Музыка җитәкчесе* ***Костюнина Марина Николай кызы,***

*Татар теле тәрбиячесе* ***Закирова Адилә Фирдинант кызы,***

*Тәрбияче* ***Гилетдинова Рәуфә Миншакир кызы,***

*Тәрбияче* ***Салихова Гөлгенә Миннеәхәт кызы***

*Биектау катнаш төрдәге “Бэлэкэч”балалар бакчасы*

Мәктәпкәчә хәзерлек төркеме балалары өчен
патриотик һәм экологик юнәлештә күңел ачу чарасы
Балалар залга кереп дүртәр колонна ясап тезелеп басалар. (проекторда һәрбер чыгыш слайд белән башкарыла).

**1бала:**

Уңыш җыелды.
Аккошлар китте.
Матур-көз ае-
Октябрь җитте.
Салкын җилләр исә,
Тәрәзәгә чиртә.

**2 бала**

Сап-сары яфраклар
Җиргә очып төшә.
Сары яфрак белән
Безнең урам тулган.
Кояшта елмаймый,
Белмим нәрсә булган?

**3 бала:** Бик күңелле бит урамда
Алтын яфрак бар дөнья,
Җил яфраклар биетә,
Көз шатлана ,туй итә.

**4 бала:**

Безнең өй түрендә үсте
Зифа алмагач.
Җыеп алдык алмаларын,

Аллангач. баллангач.

Көз җиткәнен миләш уйламый да,

Ул кызарып тулган ,күр әле.

Юк, саргаеп түгел, уттай янып,

Каршылый ул көзге көннәрне.

**5 бала:**

Колач җәеп каршы алыйк,

Сөмбелә килә!

Көзге байлык-уңыш кызы

Елмая,көлә.

Җыр "Үтте китте". Автор: Л. Хисматуллина

**Сөмбелә керә:**

Исәнмесез, дуслар!

Мин- Сөмбелә, киләм сезгә,

Көзге байлык кулымда.

Муллык белән байлык телим,

Кем очраса юлымда.

Амбар тулы арыш , бодайларым,

Тау-тау булып өелгән.

Миләшле авыр ботаклар

Җиргә чаклы иелгән.

**Алып баручы:** - Исәнме Сөмбелә! Безнең бәйрәмгә рәхим ит, бирегә үт

2 малай чыга һәм шигырь сөйли

**1 малай:**

Туган җирем басуы

Сары булып өлгергән,

Башлыйбыз хезмәт туен

Озак булыр, кем белгән!

**2 малай:**

Алыйк кулга без урак,

Җыик кулга күүп башак,

Килер табынга икмәк

Тормыш яме һәм терәк!

Ураклар белән бию. (малайлар)

Кыз белән малай чыга, аларның кулында икмәк.

**Кыз:**

Яшәү чыганагы-кояш нурын
Җир җылысын саклап үзендә,
Күкрәкләргә терәп кисәр икмәк
Һәр табынның тора түрендә.
Икмәк игенченең җан җылысы
Шуңа кадерлибез икмәкне.

**Малай:**

Өстәлдә икмәк , ашъяулык япкан,
Тәмле хуш исен өйгә тараткан.
Икмәк кадерен мин яхшы беләм,
Үскәч үзем дә ,игенче булам.

Кыз Сөмбеләгә икмәк бирә!

(Сөмбеләгә икмәкне тапшыралар).

**Сөмбелә:**

Рәхмәт сезгә, балалар!
Дуслар бәйрәмгә килгәнсез
Гөлдәй матур киенгәнсез.
Ниләр китердегез күзгә,
Сөйләп бирегезче безгә!

**Алып баручы:** - бездә бүген зур бәйрәм,
Яңгырасын җыр, сөйләм!

“Гаиләм моңы” буыннарны тоташтырып, киләчәккә якты өмет бүләк итсен!Кемнәрдән үрнәк алабыз, әлбәттә олы кешеләрдән, хөрмәтле әбиләребез, дәү әниләребез сезне бирегә чакырабыз! “Сөмбелә карап утыр, тыңлап утыр!

Залга балаларның әбиләре керә!

Җыр “Тау башына салынгандыр безнең авыл” (Әбиләр башкаруында җыр)

**Әби:** Балалар без буш түгел, табышмаклар алып килдек.Әйдәгез, табышмак уены уйнап алабыз.

1.Ура-суга , җилгәрә,
Үзе төяп җибәрә.
Бик күп эшләп игенне
Баета ул илемне.(комбайн)

2.Ат түгел, кешнәми
Йөз аттан ким эшләми.
Үзе тыр да тыр,
Я, бу нәрсә, кем әйтер? (трактор)
3.Кырлар  буш кала , яңгырлар ява,
Җирләр дымлана, бу кайчак була?(көз)
4. Сары җәймә җәелгән, алтын бөртек сибелгән. (бодай)
5. Ашата да, үстерә дә,
Яшелчә, җимеш өлгертә!
Кыскасы, тормыш бирә (җир)
6.Табигать күренешләре, ел фасыллары
  Өй башына утырган,
  Җир йөзен нуры белән тутырган.
(Кояш)
7. Ашкынамын, талпынам
Төшләремдә күрәмен,
Суы тәмле, хава чиста
Һәр кеше дә сагына....(туган җир)
Табышмаклар күп беләсез,
Зирәк икән  үзегез.
Бәхетле һәм матур булсын
Сезнең һәрбер көнегез.
**Алып баручы: -** Рәхмәт сезгә, бирегә үтегез!

Башаклар белән бию (кызлар)

**Алып баручы:** - Киләсе кунакларны чакырам! Әниләр рәхим итегез!

Г.Уразова репертуарыннан әниләр башкаруында ”Балам” җыры.

**Алып баручы: -** Рәхмәт әниләр, булдырдыгыз!
**Әниләр: -** Балалар сезнең уйныйсыгыз киләме? Без сезгә бүләккә уен алып килдек!

“Кочаклашу” уены

**Алып баручы:** Афәрин балалар, урыннарыгызга үтегез!
**Сөмбелә:** -Дусларым, барыгыз да уңышлы чыгыш ясады!
Рәхмәт сезгә, дуслар!Сез бик зирәк, тапкыр, уңган  , җитез балалар икәнсез.Сезгә карап күңел сөенә. Сезнең уңышларыгызны ишетеп бик шатландым.Бәйрәмнәр мөбәрәк булсын. Ә сез тырышып укыгыз, тәртипле булыгыз!Киләсе елга да уңышларыгызга сөенерлек булсын.

Малай парлы биюгә чакыра

**Малай:**

Урамда көз, өстәлдә сый – хөрмәт!

Килде биюгә теләк!

Бире үтик, биеп үтик!

Парлы бию

**Сөмбелә:** Гаиләм моңы барыбызны буыннарны, гореф – гадәтләрне тоташтыра, киләчәккә якты өмет бүләк итә! Балалар сезгә әйтер сүзем, олыларны хәрмәт итеп, туган якны бер итеп, ана телен хөрмәт итеп яшәгез!

**Алып баручы:** Сөмбелә рәхмәт сина, сине безнең белән җырлап китергә чакырабыз!

Җыр “Дуслык җыры”

**1.**Дуслар белән күңелле

Яшәве рәхәт,

Дустым булганың өчен

Сина зур рәхмәт!

**Кушымта**

Син – минем якын дустым,

Мин – синең дустың

Яхшы һәрвакыт янда

Булганы дусның!

**2.**Безнең дуслык нык булсын

Мәңгелек булсын!

Көннәребез гел шулай

Шатлыкта узсын!

**Кушымта:**

Син – минем якын дустым,

Мин – синең дустың

Яхшы һәрвакыт янда

Булганы дусның!

Сөмбелә китә

**Алып баручы.** Ә хәзер барыгызны биергә чакырам!

# ГАИЛӘ ЙОЛА
# БӘЙРӘМНӘРЕ



# КУНАК КАРШЫЛАУ

***Сәгыйдуллина Ләйсән Рәшит кызы***

***Талипова Наилә Нәкыйп кызы***

*19 нчы «Аленка» балалар бакчасы тәрбиячеләре*

Татар халык көе астында балалар залга керәләр. Зал татар өе күренешен хәтерләтә.

**Алып баручы:**

Мин бәйрәмнәр яратам,

Бәйрәмгә кунак килә.

Яки узең барасың

Кунак булып берсенә.

Бәйрәмнәр күңеллерәк,

Кунакка йөрешсәләр

Кешеләр бер-берсенә.

-Балалар,бу шигырьдә кунакка йөрешү турында ничек матур әйтелгән.Дөрестән дә,кунакка йөрешү татар халкының электән килгән йоласы.Әби-бабаларыбыз элек-электән бик кунакчыл булган.Кунакны тәмле сый,ачык йөз белән каршы алганнар. Бездә бүген сезнең белән Галия әбигә кунакка килдек.

Бүлмәдән Әби чыга.

**Әби:** Исәнмесез,балалар!Мин сезне бүген үземдә кунакта күрүемә бик шат.

**Алып баручы:** Исәнме,әбекәй.

**Әби:** Балалар,мин сезнең килүегезне әзерләнеп көтеп тордым.Түрдән узып,урындыкларга утырыгыз (балалар урындыкларга утыралар). Хәзер мин сезгә бераз Кунак каршылау йоласы турында сөйләп китәм. Элек- электән татар халкы бик кунакчыл халык. Кешеләр бер-берсенә күчтәнәчләр алып, кунакка йөрешкәннәр. Кунакта алар тәмле итеп чәйләр эчеп кенә калмаганнар, ә сөйләшеп утырганнар, төрле уеннар уйнаганнар. Мин үзем дә кунак каршыларга һәм кунакка йөрергә бик яратам.

**Алып баручы:** Рәхмәт,әби,безне бу йола белән таныштырып китүең өчен.

Әбекәй,сез яшь чакта нинди уеннар уйный идегез? Безне дә өйрәтә алмассызмы икән?

**Әби:** Мин уеннар күп беләм. Хәзер бергәләшеп уйнарбыз шул уеннарны.Минем иң яратып уйнаган уеннарымның берсе – “Йөзек салыш ” уены. Әйдәгез шуны уйныйбыз.

“Йөзек салыш” уены.

Балалар төзелешеп утыралар, әби бер баланың учына йөзек сала. Аннан ”Кемдә йөзек, сикереп чык!” дигән сүзләр әйтелә. Йөзек салынган баланы күршеләре тотып калырга тиеш. Бала сикереп чыгарга җитешмәсә, аңа җәза бирелә. Уен шулай дәвам итә

**Алып баручы:** Әбекәй,без балалар белән сиңа бер матур җыр өйрәнеп килдек. Тыңлап кит әле.

“Кунаклар җыры” (Ш.Галиев сүзләре, Г.Гараева көе)

**Әби:** Булдырдыгыз,балалар.!Бик матур җырладыгыз. Балалар, ә сез мәкальләр беләсезме?

**Балалар:**Беләбез.

**Әби:** Әйдәгез әле тикшереп карыйк. Мин мәкальнең башын әйтәм, ә сез дәвам итәрсез.

- Кунак булсаң- (тыйнак бул).
- Тыйнаклык (кешене бизи).
- Кем эшләми - ( шул ашамый).
- Эш беткәч - ( уйнарга ярый).
- Калган эшкә - ( кар ява).

- Рәхмәт, балалар. Бик күп мәкальләр беләсез икән.

**Алып баручы:** Әбекәй,безнең балалар бик матур җырлы-биюле уен “Миңлебай” беләләр.Әйдә бергәләп уйнап китик.

Балалар түгәрәк уртасына бер баланы сайлап чыгаралар да үзләре, кул тотышып, җырлап әйләнәләр. Уртадагы бала, берәр кыланыш эшләргә әйтеп, кыланып күрсәтә, тирәсендәге балалар да аны кабатлый.

Без йөрибез әйләнеп,
Син уртада,Миңлебай.
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Без кыланабыз шулай.
Бер болай, бер болай,
Я, кыланыгыз шулай”.

Аннан соң уртадагы бала түгәрәктән бер баланы чыгара да уен дәвам итә.

**Әби:** Бик күңелле,балалар,сезнең белән уйнавы.Мин сезнең килүегезне тәмле ризыклар әзерләп көттем.Ә сез татар халкының нинди милли ризыкларын беләсез?Хәзер тикшереп карыйбыз.

Уен “Милли ашларны яхшы беләсеңме?” (дөрес җаваплар экранда чыга)

1) Камырдан пешерелгән аш( токмачлы аш).
2) Геометрик фигураны хәтерләткән ашамлык( өчпочмак).
3) Эче тулган ит белән, суган һәм бәрәңге белән (бәлеш).
4) Бәйрәмнәрдә табын яме( чәк-чәк).
5) Камыр эченә төелгән бәрәңге салынган ризык( кыстыбый).

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез хәзер бергәләп әйлән-бәйлән уены“Утыр, утыр, Мәликә” уйныйбыз.

Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, уртага утыра. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк әйләнәләр:

Утыр, утыр, Мәликә,
Алмагачның төбенә,
Кем утырган каршыңа,
Әйтеп бирче тиз генә.

Берәү аның янына утыра, уртадагы бала аны капшап танырга һәм исемен дә әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа “җәза” бирелә.

**Әби:** Бигрәк уңган балалар икәнсез, күп уеннар беләсез.

**Алыр баручы:** Әбекәй, безнең балалар матур шигырьләр дә өйрәнделәр.

**1 нче бала:**Кунакларны бик яраткан
Электән безнең халык.
Юмарт диеп, уңган диеп,
Килгән күптән макталып.

**2 нче бала:** Кунакчыл ул безнең халык.
Аның йорты- кунак йорты.
Син килсәң дә, мин килсәм дә,
Кунак итмәс ярты- йорты.

**3нче бала:**Безнең халык кунакчыл.
“Якты чырай, такта чәй”,- дип,
Каршы ала кунакны.
Ата – баба гадәтләрен,
Без дәвам итәбез.
Безгә кунакка килегез- көтәбез.

**Әби:** Балалар, бик матур шигырьләр, җырлар, уеннар өйрәнеп килгәнсез, акыллы- уңганнар икән үзегез. Мине шулай зурлап килгәнегез өчен зур рәхмәт сезгә! Бәхетле булыгыз! Сәламәт булып, игелекле балалар булып үсегез! Ә хәзер мин сезне чәй эчәргә чакырам. Чәй өстәленә рәхим итегез!

# КОДА ТӨШЕРҮ

***Әүхәдиева  Нурания Әюп кызы,***
***Галиәкбәрова Алсинә Фаил кызы,***
***Шәрипова Динә Ильяз кызы***
*МБМБУ Саба 1 нче номерлы «Шатлык» балалар бакчасы*

Ике көн туйдан соң, Газизләр кода төшерергә әзерләнәләр.

*Авыл өе, бәйрәмчә бизәлгән. Түрдә – өстәл, милли бизәкләр белән чигелгән өстәл япмасы. Өстәл өстендә самавыр, чынаяклар, татар халкының милли ризыклары куелган. Янда чигүле мендәрләр, җәймәләр куелган караваt.*

**Гөлзифа:** -Картым, кодагыйлар юлга чыккандыр син мунчаны ягып җибәрдеңме әле, кодагыйлар килгәнче булдырырга кирәк. Мин өстәл әзерлим, ә син  калганын карап бетер инде яме (чәй өстәле янында кайнаша). Кызым син мунча идәннәрен әйбәтләп юып чык әле.

**Газиз:** -Ярар, карчык борчылма мин үзем карармын. Алар килеп җиткәнче бар да әзер булыр. Малларның алдында, ишек алды себерелгән, бар җир чистартылган, бар да әзер, борчылма.

**Гөлзифа:**-Мин әйтәм, буранлап тора  әле. Нәрсә белән килерләр, ат белән микән? Юлга чыктылар микән? Кәнсәләргә барып телефоннан шалтыратып карамыйсыңмы?

**Газиз:**-Анда барганга карап чакыртырлар микән соң телефонга? Борчылма карчык килерләр, килерләр. Син үзең бүләкләр әзерләдеңме соң әле кода-кодагыйга?

**Гөлзифа:**- Әйе, әйе әзерләдем. Кодага күлмәк, кодагыйга ситса, балаларга да алдым. Аллага шөкер, бар да әзер. (Сандыкны ачып  кулына тотып алып курсәтә).

**Газиз:**- Ничәү килерләр микән?

**Гөлзифа:** - Өерләре белән килсәләр дә, барсына да җитә.

**Газиз:**-  Карчык, алар килеп тә җитәр, капка төбенә чыгып каршы алмасаң күңелле булмас, киттем әле мин.

**Күршеләр керә:**

- И Гөлзифакаем, ничек хәлләрегез, исәнлектә-саулыктамы?

**Гөлзифа:** - Аллага шөкер.

- Мичтә бәлеш тә пешә име, озакламый әзер булачак, Гөлзәйнәп кош теле дә пешерәм дигән иде. (китә сандык карарга)

**Кош теле күтәреп Гөлзәйнәп керә.**

-Нихәлләрегез бар? Кош телләре и уңды, и әйбәт итеп пеште.

**Гөлзифа:** - Иии рәхмәт яугырылары. Әле дә сез бар күршеләрем.

(Газиз тавышы ишетелә) Килделәр, килделәр.

**Гөлзифа:** - Карагыз әле балалар, тәртипме бар җир дә.

**Газиз:** - Кодагыйлар килгән безгә, кулларында чемодан...

**Кыз ягы:** - Чемодан?????

**Килгән кунаклар:** (мактанып)- Чемодааан....

**Газиз:** - Чемоданның эчләренә сыер гына сыймаган...

**Кыз ягы:** - Сыеееерр....????

**Килгән кунаклар:** (мактанып)- Әйе шуууул.

**Газиз:** - Нихәлләрегез бар?

- Аллага шөкер.
- Исәнмесез, саумысыз.
- Нигә кәҗә саумыйсыз?
- Әтәчегез күкәй салган.
- Нигә чыгып алмыйсыз?

**Кыз ягы:** Нигә чыгып алмыйсыз?

- Алдык шууул....
- Ягез бер дога.(КолхуАллаһ)

Утырышалар.

...Дога....

**Кодача:** - Исән саулар гына яшәп ятасызмы?

**Газиз:**Аллага шокер.

**Гөлзифа:** Исән сау гына килдегезме?

**Бөтен кеше баса**.

**Кодача:** “Табын яме-ипи”-диләр

Сүзләр йөри түгелме?

Табынның иң түрендә

Урын ала түгелме?

- Мә әле кодагый, Теләче пичләрендә күпереп пешкән ипине ал әле.

**Гөлзифа:** Ай рәхмәт, бик тәмле күренә.

**Килгән Кода:** Менә, кода, сезгә бүләк,

Парлы каз, парлы канат.

Алып килдек менә сезгә

Симезен генә сайлап.

**Гөлзифа:** Барыгыз әле, балакайларым, казларны күрсәтеп үтегез әле.

**Газиз:** Ай казлары, казлары, тамып тора майлары!

**Кодачалар**: Ай казлары, казлары, тамып тора майлары!

**Гөлзифа:** Рәхмәт, кода, кучтәнәчләрегезгә, казларыгыз да биик зур булган. Кода-кодагыйларның бүләкләрен алдык, хәзер мин дә сезгә әзерләгән буләкләремне бирим әле.

Кодагый сандыктан алып ,бүләкләр тапшыра:

Бездән бүләк кодага күлмәк, кодагыйга ситца.

**Газиз:** Гөлзифа, кодаларны табынга чакырыйк, юлдан арып килгәннәрдер, чәйләп алыйк.

**Гөлзифа**: Әйдәгез табын янына рәхим итегез.

**Табынга утыралар,сөйләшәләр.**

**Гөлзифа:** Ашап,булганнарыннан авыз итеп утырыгыз.

**Бәлеш күтәреп күрше керә**.

Әй кодалар утырыйк,

Өстәл өстен тутырыйк

Ашап-эчү берни түгел

Бер җырлашып утырыйк.

**Кода:** Әйдә, кода, җырлыйк әле

Без уйнаган көйләргә.

Сез уйнаган без җырлаган

Калсын сагынып сөйләргә.

**Кодалар:** Урманнардан җиләк җыйдым

Бөрлегәннәре белән

Кода-кодагый булыштык

Бер дигәннәре белән

**Килгән кунак:** И кодалар, кодалар

Кодалар, кодачалар

Сездә ничек бездә шулай

Җырлап куңел ачалар.

**Кодалар ягы:** Сабаларның урамнарын

Түшәгәннәр таш белән

Теләчедән кода килгән

Кода килгән аш белән.

**Гөлзифа:** Мин үстердем кызымны

**Кодача:** Мин үстердем улымны

Кода кодагый булыштык

Бир кодагый кулыңны

**Бергә:**

Кодаларга зур рәхмәт

Бик зурлаганнар инде

Тигезлектә татулыкта

Шат яшәсеннәр инде.

**Кыз**: Әнкәй, мунча әзер! Әйдәгез Кодаларны җырлап мунчага озатыйк әле!

**Газиз**: Әйе,мунчаны керми булмый, менә каен себеркеләре.

(Як-якка китеп ярымтүгәрәккә тезеләләр)

Алма булса шундый булсын

Берсен бишкә бүләрлек

Кодаң булса шундый булсын

Синең өчен үләрлек.

Эх алмагачлары,

сайрый сандугачлары

Сайрый-сайрый, сайрый-сайрый

Сагындыра башлады.

**Кода ягы:** Әйдәгез, кодалар мунчада вакытта Чүпләм бию биеп алыйк әле.

- Әйдәгез.

**Бииләр**

**Газиз:**Кодалар мунчадан кайтып киләләр, Коймакларыгыз әзерме?

- Әзер-әзер

Самавырны тиз кайната

Кызыл миләш күмере

Килен белән яшь кияүнең

Озын булсын гомере

**Газиз:**Тәмлеме коймаклары?

- Бик тәмле.

**Кодалар:** Алай итәргә кирәк,

Болай итәргә кирәк

Кодаларга рәхмәт әйтеп

Кайтып китәргә кирәк.

## ҮТКӘНЕН ОНЫТКАН ХАЛЫКНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ЮК

***Заһидуллина Гүзәлия Фәрхетдин кызы***

*Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет*

*мәктәпкәчә белем учреждениесе “Сөн балалар бакчасы”*

*Бүлмәгә самовар күтәргән әби керә.*

**Онык.** Әбием! Әйтергә дә онытып торам, бүген безгә минем дусларым килергә тиеш. Мин аларга синең сандыкта кадерләп саклаган милли киемнәр турында сөйләгән идем. Аларның бу әйберләрне күрәсе килә. Ә без әле милли киемнәр турында бик күп шигырь, җыр, бию дә өйрәндек.

**Әби.**Иииии, песиебез әйтәм, иртәдән бирле битен юа иде, кунак килүгә икән. Иптәшләреңне чакырып бик яхшы эшләгәнсең, кызым. Тәмле ризыклар – үзебезнең милли ашларны пешердем. Сыйлармын үзегезне. Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк аның, балам. Шуңа күрә, сандыгымда сакланган милли киемнәр турында да сөйләрмен. Үсеп җиткәч, син үзеңнең оныкларыңа күрсәтерсең, сөйләрсең. Көлмә, кызым, гомер хәзер үтә ул. Без яшь чагында уйнаган уеннарны да уйнарбыз.

**Онык** (экранна карый) Әбием! Кунакларым килеп тә җиттеләр. (Бер төркем балалар керә)

**Балалар.** Исәнмесез! Хәерле көн!

**Әби.** Хәерле көн, балакайларым. Күптән инде үзегезне күргәнем юк, үсеп тә киткәнсез. Түргә узыгыз, утырышыгыз.

**Онык.** Әби, балалар синең сандыгыңны ачып карыйсылары килә. Ачып күрсәтерсеңме?

Әбиебез сандыгында

Сакланмый ниләр генә.

Әйдәгез сорыйк үзеннән.

Ачып күрсәтсен безгә. (Әби сандык янына килә.)

**Әби** Балакайларым, бу сандык бик серле сандык. Ул татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын борынгыдан килгән мирасын саклый. Ул бит болай гына ачылмый, сандык ачылсын өчен аның турында сөйләргә кирәк.

“Авыл көе” яңгырый

**Бала.**

Әбиемнең күңел сандыгы!

Нинди серләр саклый икән ул?

Гомер буе җыйган хәзинәме,

Әллә инде күңел бизәгеме,

Нинди серләр саклый икән ул?

**Бала.**

Әбиемнең күңел сандыгын
Бер ачасы иде, ачасы......
Әби-бабам белгән йолаларны,
Халкыбызның күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде, ачасы.

**Бала.**

Әбиемнең күңел сандыгы
Кызыктыра инде күптәннән.
Ач, әбием безгә күңелеңне
яш буынга мирас булып калсын,
Бер хәзинә калсын үткәннән.

**Әби.** Сандыгымда яшьлек хәтирәсе
Чиккән сөлгем – минем гомер юлым,
Ничәмә төс, ничәмә җыр анда,
Һәр төсендә минем кулларым.

Их, сөлгеләрем, кадерле сөлгеләрем. Сандык төбендә күп еллар буе яткырганым өчен үпкәләмәгез инде миңа. Ниндиләре генә юк монда! Ә менә бу сөлге иң кадерлесе, чөнки ул әнием истәлеге, бу бизәкләр аның кулы белән чигелгән. Мин синең белән бервакытта да аерылырга теләмәдем. Хәзер картайдым инде, сәламәтлегем дә какшады. Ә менә синең гомерең озын әле. Кадерле сөлгеләрем! Сез минем яшьлек шатлыгым, минем җаным да сездә. Менә тагын бер сөлге.

**Бала.**Кызлар, карагыз әле нинди матур сөлге?

**Бала.** Бигрәк матур итеп чигелгән әйе бит, кызлар?

**Бала.** Әби, син бу сөлгеләрне үзең чиктеңме?

**Әби.** Үзем, балакайларым, үзем. Бүген матур итеп чигелгән затлы сөлгеләр әбиләрнең сандыгында гына саклана. Әбиләр аларны кадерләп саклый. Яшь кызлар үз куллары белән чигеп, сугып сөлгеләр әзерләгәннәр. Сөлгеләрнең матурлыгына карап яшь кызларның уңганлыгы, пөхтәлеге, булдыклылыгы бәяләнгән.

**Бала.** Иң матур сөлгеләрне туй атларының дугаларына бәйләгәннәр, миңа әбием шулай диде.

**Бала.** Затлы сөлгеләр белән өй эчләрен бизәгәннәр.

**Бала.** Сөлгеләр халкыбызның Сабантуй кебек милли бәйрәмнәрендә дә аерылгысыз булганнар.

Сөртенсәң - сөлге кирәк,

Көрәшсәң - сөлге кирәк.

Батырларга сабантуйга

Бирелгән сөлге-бүләк.

Ә болары – Казан сөлгеләре. Әбиләребез үзләре тукып эшләгән. Кайсы гына егетнең иңенә ятмаган да, нинди генә батырларга бүләк булмаган бу сөлгеләр.

Алъяпкыч ала

**Әби.** Менә монысы алъяпкыч. Татар кызларының алъяпкычлары канатлы булырга тиеш. Чиккән алъяпкычлар зифа буйлы кызларга бигрәк тә килешеп торган. Киләчәктә сез дә шулай милли алъяпкычлар ябып йөрерсез әле.

**Тәрбияче.** балалар, искә төшереп китик әле, татар милли киемнәрендә нинди чәчәк бизәкләре очрый әле? (лалә, кыңгырау, чалмабаш, канәфер, гөлҗимеш)

**3 кыз.** Әби, бу нинди күлмәк соң?

**Әби**. Бу күлмәк балам бала итәкле күлмәк - татар кызларының милли киеме. Итәкләре никадәр күп булса, шулкадәр матуррак санала, озын булуы белән кызларның балтырларын чит-ят күзләрдән саклый.

**Әби.** Мендәр тышларын да бик тырышып чиккәннәр. Каты телле, яман күңелле кешеләрнең күзләре шушы чигелешле мендәрләргә төшә дә, хатын-кызларга күз тими. Карагыз әле, күпме хезмәт, күңел җылысы салынган бу бизәкләргә!

**Бала.** Ай, нинди матур читекләр! Карагыз әле, кызлар, карагыз.

**Әби.** Борынгы бабаларыбыз – йомшак күннән затлы киемнәр тегүнең, күнне сәнгатьчә эшкәтүнең чын осталары булганнар.

**Бала.**

Ә менә мин читекләрнең килеп чыгышын беләм

Теләсегез сөйлим.

Борын – борын заманнарда

Болгар иле булган, ди.

Безнең борынгы бабайлар

Шушы илдә торган, ди.

Ул бабайлар әйбәт күннән

Читекләр теккәннәр, ди.

Читек киеп ,дөнья буйлап

Сәүдә дә иткәннәр, ди.

**Бала.**

Ул заманда күп халыклар

Чабата кигәннәр, ди.

Ә безнең Болгар бабайлар

Читектән йөргәннәр, ди.

Бизәк төшкән итекләрне

Читекләр дип йөрткәннәр,

Аларны татар кызлары

Бәйрәмнәрдә кигәннәр.

**Тәрбиче.** Бу читекләрне кигәч, гел биисе генә килеп тора торгандыр, әбекәй, әйеме? Сез бии идегезме?

**Әби.** Биедек, кызым, биедек. Гармун тавышын ишетүгә җилкенеп биеп китә торган идек.

**Тәрбияче.** Безнең кызлар да биеп күрсәтсеннәр әле, әбекәй.

**Кызлар башкаруында бию “Татар кызлары”**

**Бала.** Әби түбәтәй белән калфакларны да күрсәт инде.

**Әби.** Менә, балалар, бу ирләрнең милли баш киеме - түбәтәй һәм кәләпүш, бәрхеттән, зиннәтлеләре парчадан тегелгән. Аларны көмеш, алтын, ефәк җеп, сәйләннәр белән белән чигеп, ялтыравыклар белән бизәгәннәр. Түбәтәй, кәләпүш тегә һәм чигә белгән кешене алтын куллы оста дип санаганнар.

**Тәрбияче.** Әби, без түбәтәй турында шигырьләр өйрәндек, тыңлап кара әле.

**Бала.**

Түбәтәй.

Үзе матур, үзе бәләкәй.

Әллә кайдан нурлар сибеп тора

Кызлар чиккән милли түбәтәй.

Бәрхетләрдән тегелгән,

Ука белән чигелгән,

бизәкләре көмешләргә,

Алтыннарга күмелгән.

**Бала.** *Кәләпүшем, кәләпүш.*

*Йөзләремә килешәсен*

*Кайлардан гына белгән,*

*Туган көнгә дәү әтием*

*Кәләпүш алып килгән.*

*Кәләпүшемне кидем мин,*

*Көзге каршына килдем.*

*Менә шундый була ул –*

*Татар малае! - дидем.*

*Кәләпүшем, кәләпүш,*

*Энҗе-мәрҗәннәр чиккән.*

*Чиккән кәләпүш үземә*

*Бигрәк килешә икән.  Р.Вәлиева*

**Әби.** Бу татарның милли баш киеме

Килешә ул кемнәр кисә дә.

Исеңдә тот, балам, кадерен бел,

Гасыр буйлап килгән ул безгә.

**Бала.** Әбием синең яныңда бигрәк күңелле, без уйнарга да бик яратабыз.

Әйдәгез "Түбәтәй" уенын уйнап алыйк!

**"Түбәтәй" уены уйнала.**

Түбәтәеңне кигәнсең

Бик ерактан килгәнсең

Төскә матурлыгың белән

Шаккаттырыйм дигәнсең

Түп-түп-түбәтәй

Түбәтәем укалы

Чиккән матур түбәтәем

Менә кемдә тукталды.

"Түбәтәй" уены уйнала. Балалар түгәрәккә басалар, җыр җырлап түгәрәк буенча хәрәкәт итәләр. Җыр бетүгә, түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә: (шигырь сөйләргә, җырларга, мәзәк сөйләргә һ.б. Уен 2-3 тапкыр кабатлана)

**Әби.** Рәхмәт, балакайларым! Олы кешене сөендергәнегез өчен. Яшь

чакларым искә төшеп китте. Без дә шулай күңелле итеп уйный идек.

**(әби сандыктан, чулпылар, көмеш алкалар ала).** Ә бу әйберләр турында нәрсә әйтә аласыз?

**Тәрбияче.** Чулпы үзе тәңкәләрдән торган. Ясалышы ягыннан алар күптөрле булганнар. Тәңкәләр чулпыга икешәр-өчәр, алтышар, хәтта тугызар итеп тә тезелгәннәр. Чулпылар берюлы ике толымга кушып үрелгән. Чулпы авырлыгыннан чәчләр тизрәк үсә дип уйлаганнар. Шулай ук тәңкәләрнең чыңлавы явыз рухларны да куркыта дип ышанганнар.

**Бала.**

Мин дә сезне әбием белән таныштырыйм әле. *(Әбисен җитәкләп алып керә)*

Менә ул минем әбием, әбием генә тугел, ул минем дәү әнием. Мин аны бик яратам, ул да мине ярата. Мин кайчакта әбиенең кулларына карап торам. Ул куллар кечкенә генә, ләкин шул кечкенә генә куллар ниләр генә эшләмәгән. Аның куллары эшләгән эшне тау итеп өйсәң, ул тау болытка тияр иде, юл итеп сузсаң аны узарга бер гомер кирәк булыр иде. Әбием шул озын юлны узган. Ул шушы куллары белән ничә бала тәрбияләп үстергән. Кайвакытларда әбием арган кулларын тез башларына куя да, радиодан җырлар тыңлый, үзе дә кушылып җырларга ярата.

**Тәрбияче.** Сез мөнәҗәтләр дә әйтәсез бит.Әйдә, Ләйлибәдәр әби, безгә  дә көйләп күрсәтегез әле.

Ләйлибәдәр әби мөнәҗәт әйтә.

БисмиЛләһир-Рахмәнир-Рахим.
Килеп кердем өегезгә,
Тәсбих нуры йөзегездә,
Тәсбих әҗерләрен бирсен
Бер Раббым үзегезгә.
Ошбу өйнең хуҗасына,
Дәхи балаларына,
Дәхи ата - анасына
Рәхмәтен бирсен Аллаһ.
Сагынып килдем үзегезне,
Дәхи күрдем йөзегезне,
Безне каршы алган кебек
Хурлар каршы алсын сезне.
Рәхмәт сезгә Ләйлибәдәр әби.

**Әби.** Сез сөйләгән шигырьләрне, җырларны тыңлап, вакытның үткәнен сизми дә калганмын, минем намаз укыр вакытым җитте. (Кулына коръән китабы ала) Сандыгымда сезгә күрсәтәсе тукыган, чиккән сөлгеләрем дә, эскәтерләрем дә, башка әйберләрем дә бар. Алар турында икенче вакыт сөйләшербез. Аларның матурлыкларын карап, бергә сокланырбыз.

**Бала** . Әби, бу нинди китап соң?

**Әби.** Балалар, бу әби-бабаларыбыздан калган иң изге китап – Коръән китабы. Әби-бабаларыбыз, Коръән укып тәсбих тартып, балаларына, барча якыннарына изге теләкләрен, догаларын юллаганнар. Бу изге китап чисталыкка, пакьлеккә, урлашмаска, кешеләргә бер-берләрен җәберләмәскә, кыерсытмаска, изге күңелле булырга өйрәткән. Китап гаиләдә буыннан буынга, кулдан кулга күчкән. Балалар, бу китап та гаиләбезнең ядкаре булып

буыннан буынга күчә килгән.Иииии хәтер диген инде, китап дигәч искә төште. Минем сезгә әзерләп куйган күчтәнәчем бар иде бит, кая әле ул. Менә балалар сезгә дә китап, аның эчендә бик матур рәсемнәр, сурәтләр, аларга татар бизәкләре төшерелгән, бакчагызга кайткач рәхәтләнеп буярсыз.

**Тәрбияче.** Күпме мирас...Һәркайсы затлы, асыл, зиннәтле...Һәммәсе – хәзер сандыкларда гына сакланырлык кадерле байлык. Ешрак ачыйк без ул сандыкларны. Тагын, тагын ашыкмыйча гына карыйк ул ядкарьләрне. Сокланыйк бу матурлыкка. Үзебез дә өйрәник һәм бездән соң килгән буыннарга да тапшырыйк. Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк аның.

## ОРЧЫК ӨМӘСЕ

***Латыйпова Рузалия Рүфәт кызы***

*Актаныш муниципаль районы муниципаль бюджет*

*белем бирү учреждениесы “Пучы балалар бакчасы”тәрбиячесе.*

**Алып баручы:** Хәерле көн хөрмәтле килгән кунаклар! Татар халкының тәрбияви һәм әхлакый әһәмияткә ия булган, буыннан-буынга күчеп бара торган йола-бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре бар. Тирән эзләр булып халкым үткән юл, аның яшәеве тарихта урын алган. Ләкин аларның кайберләре заманалар үзгәрү белән вакыт тузаны астында калган. Бер-беребез белән очрашып күрешүләр, кич утырулар сирәгәя.

Бүген без әнә шул онытылып бара торган бәйрәмнәребезнең берсе булган “Орчык” бәйрәмен хәтердә яңарту уңаеннан бирегә җыйналдык. Шулай итеп, бүгенге кичәбезне башлыйбыз һәм кичке уенга чакырабыз. Бәйрәмебез мөбәрәк булсын!

Әби өй эчендә.

**Әби:** Карале , бабай өмәчеләрне  алып киләм дип киткән иде, үзе дә юк, өмәчеләр дә күренми. Түбән оч Харисны очратып шуның белән гапләшеп тора микән? Озакламасын иде , яшьләрнең дә киләсе бар, аларны да өйрәтәсе бар бит. Кая әле каба, орчыкларымны карап куйем әле.

*Гармун тавышы ишетелә.* Өлкәннәр бабай белән керәләр.

Әби: Менә-менә  үзләре дә күренә, киләләр икән, самаварымны гөрләтеп җибәрим әле.

(өйгә керәләр)

**1 нче өмәче:** Исәнмесез, хуҗалар.

**Әби:** Исәнмесез, исәнмесез өмәчеләр. Нишләп соңга калдыгыз?

Бабай: Көчкә алып килдем. Әйдәгез, әйдәгез кунаклар түрдән узыгыз, утырыгыз.

2 нче өмәче: Яшьләребез күренми бит әле. Алар да килеп җитсеннәр иде бит.Өмәне бергәләп башлар идек.

Утыралар.

3 нче өмәче: Өйдә, без эшне башлый торый, яшьләр килеп җитәрләр.Кемдер йон эрли, кемдер йон яза. Бабай орчык ясый (пәке белән кырып ясый)

1 нче өмәче: И-и замандаш, гомер буе шулкадәр матур, тигез итеп эрләдең. Ул орчык сере беләсеңме син нәрсәдә? Синең картың ясап бирде ул орчыкны миңа, үзеннән үзе эрләнә.

Әби: Менә сиңа ичмасам үзенең карчыгына орчык ясамыйча күршегә ясап йөри.

Бабай: И-и карчык сина да ясап утырам бит менә. Тукта әле карчык самавырны карап керим әле.(чыгып китә)

Әби: Кая сон безнең яшьләребез, нишләп куренмиләр икән?

2 нче өмәче: Әйе, шул аларга аңлатып, өмәне бергәләп  башлап җибәрсәк, хәерлерәк булыр иде.

(гармунчы егет белән балалар җырлап керәләр)

Җыр “Матур булсын”

1 нче бала: Менә сездә өмә икәнен ишеттек дә, дуслар белән җыелып килдек.

Әби: И-и, рәхмәт инде, әйдәгез җайлашып утырыгыз.

1 нче өмәче: Әйләгез эш башланганчы бер дога укыйп алыйк. (дога укыла бергәләп)

2 нче өмәче: И, ходаем, эшебез җиңел булсын, тиз-тиз генә эшләп алыйк.

Бала: Апалар әйтегез әле нәрсә соң ул орчык өмәсе.

Әби(аңлату): Сезнең белмәвегез бер дә гаеп түгел, орчык өмәсе безгә ата-бабаларыбыздан калган мирас ул. Орчык өмәсе кыш җиткәч, җиргә кар яугач уздырыла. Әйдәгез әле балалар  мин сезгә бик тәфсилләп аңлатып бирермен.. (әкрен генә сандыкны ача) балалар сез монда нәрсә күрәсез? (бияләү, оекбаш) хәзер сез бу әйберләрне ки бетләрдә аласыз. Ә элек без аны үзебез бәйли идек. Бу бияләй, оекбашларны бәйләү өчен безгә йон кирәк. Әйтегез әле, балалар, йонны без каян алабыз. (җавап) Әйе, без йонны үзебезнең ихаталардагы сарык, кәҗәләрдән алабыз.

Бу йоннан әле без бияләй, оекбашлар бәйли алмыйбыз Бу йонны башта чистартырга, ягъни язарга кирәк. Менә бу эшне сезгә Бикә әбиегез курсәтеп бирер.

1нче өмәче: Балалар йонны тигәнәк хәм чүпләрдән арындырабыз. Һәм йонны менә шулай итеп юкартабыз ягъни язабыз. Әйдәгез әле бергәләп эшләп карыйк. Йонны язганнан

соң бер кисәк йон ясала-бу көнҗәлә дип аталган.. Бу йонны без яңадан кабага куябыз һәм менә шулай итеп орчык белән йонны эрләп орчыкка урап барабыз.

2 нче өмәче: Шушы орчыктагы җепне йомгакка ураганнар. Менә безнең инде оекбаш бәйләргә чималыбыз әзер.

Әби: Без, өмәләрдә эшләп кенә утырмадык, уеннар да уйный идек. Әйдәгез шул уенның берсен сезнең белән “Йомгак” уенын уйнап алабыз. (уеннын эчлеген аңлату)

3 нче өмәче: Менә, балакайларым, сез уйнаган арада әзер йомгактан шәл бәйләдем. Карагыз, әле,шәлем матур булганмы?

Әйдәгез әле кызлар, шушы матур шәлләр белән бер биеп алыйк әле.

*БИЮ: “Шәл бәйләдем”*

Бала: Бәйрәмебез бик күңелле бара. Бик куп нәрсәләргә өйрәнсәк тә, без халкыбызның бик куп йолаларын белеп бетермибез икән әле.

Әби: Ярый балалар, без сезгә үзебезнең гореф-гадәтләрне, йолалар белән сезне таныштырырбыз.

Әле безнең орчык өмәсендә уйнала торган тагын бер уеныбыз бар.

Балалар: Нинди уен ул әбекәй?

Әби: Ул “Орчык бөтерү” уены. Мин орчыкны бөтерәм, кемгә орчыкның башы карап кала шул кешегә җәза бирелә.

*“Орчык бөтерү” уены.*

Бабай чыга: И, оланнар, өмә булгач өмә булсын “Орчык такмаклары” н җырламый булмас.

Өмәчеләр: Әйдәгез, әйдәгез.

Йон эрлимен, йон эрлимен
Кил син бездә аулак өй
Орчыклар биеп торганда
Тузеп булмый җырламый.
Тал тамыры агып килә
Түгәрәк күлләренә
Кумәкләшеп без йөрибез
Орчык өмәләренә.

Бала: Ярый әле килгәнбез. Куп нәрсәне, онытылып барган уен- җырларны белдек.

Әби: Менә балалар. “Орчык өмәсе” шулай үтә инде. Эшен дә эшләдек, күңелне дә ачтык.

Я, сезгә орчык өмәсе ошадымы балалар?

Самат: Бик күңелле ял иттек. Без дә буш килмәдек, сезгә үзебезнең матур җырыбызны бүләк итәбез.

*Җыр: “ Куш кулым”*

Әйдәгез, хәзер бергәләп чәй эчеп алыйк.

## БАЛАГА ИСЕМ КУШУ ЙОЛАСЫ

***Шакирова Эльвира Илсур кызы***
***Загидуллина Глюсэ Илфак кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*«Арча 9нчы балалар бакчасы»*

*Әкрен генә көй яңгырый*

**Алып баручы:**

Исәнмесез!- диеп башлыйм әле,
Танышу бит шулай башлана.
Сезнең белән очрашканга, дуслар,
Күңелкәем шундый шатлана!

Исәнмесез хөрмәтле балалар, килгән кунаклар! Бүген без сезгә бәбигә исем кушу йоласын күрсәтербез. Татар халкында борынгыдан килгән тал бишек.Элек-электән аны әтиләр үз куллары белән үреп,үзләренең йөрәк җылыларын биреп ясаганнар. Ә матур чыбылдыкларны әниләр теккән. Ул чыбылдык сабыйны явыз көчләрдән, күзләрдән, салкыннардан саклаган.

*Җыр яңгырый*

Сездә ничек,бездә бишек талдан,
Җырдан үрелә.
Җырлы бишек,җылы бишек
Эленә өй түренә.

*Бишек янында әни тора*

**Әни:** Кызым, бүген ит бит бәбигә исем кушабыз, исем табырга кирәк.

Бик матур исем кирәк...

**Бала:** Әйе энием,

**Әни:** Эле кұмәч тә, әлбә дә пешмәгән, тиз бул тиз -бул хәзер кунаклар килеп җитә бит. Шыпырт кына сөйләшегез, бәбәй уянды бит.

*( бәбине тирбәтеп, Габдулла Тукайның «Әлли-бәлли итәр бу» шигырен тәрбияче башкара. Татар халык көе)*

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып житәр бу.
Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.
Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

*(Кунаклар килә)*

**Кунаклар:** Әссәләмәгәләйкем,
Исәнмесез, саумысез,
Нигә саумыйсыз кәҗә.
Каршылагыз хөрмәт белән
Күчтәнәч тулы әрҗә.

**Әни:** Килдегезме, кунаклар,
Түрдән узыгыз әйдә!
Мичтә күмәч, җамаякта
Изелеп пешкән әлбә.

**Кунаклар:** Кучтәнәчнеееееe җәлләмәдек
Алып килдек мул итеп.
Бәбине күрсәтсеннәр, дип
Апаларына –читеееек.

**Әни:** Күз тимәскә шомырт куйдык

Салдык олы имезлек.

Бүген мунча юындыргач

Көчек күлмәк кигездек.

**Бала:** Нинди күлмәәәәк?

**Әни:** Баланың беренче күлмәген көчек күлмәге дигәннәр борыннгылар.

**Кунаклар:** Исеме ничек сабыйның?

**Әни:** Эйдәгез, бергә уйлыйк инде.

**Кунаклар:** Әйдәгез, бездән калмаган, исемнәр беләбез без, уйлашыйк. Әллә бармак уены белән башлыйкмы?

**Әни:** Әйдәгез, алайса, башлыйк.

*Бергәләп җырлыйлар берәү санаү рәвеше китерә: ( түгәрәкләнеп)*

Бармак уены чыккан диләр

Оталсам ярар иде.

Иң матур затлы исемне

Мин тапсам ярар иде.

*(Берәүне чыгара. Тегесе кисәк кенә):*

**Бала:** Газиза! Шат күңелле, ачык , дигән сүз!

**Бала:** Кит моннан, сабыебыз ир бала бит!

*(җыр, тагын берәүне чыгаралар)*

**Бала:** Мөхәммәтгариф! Укымышлы дигән сүз!

**Бала:** Авылыбызда 12 Гариф бар, шул җитеп торыр мәллә?....

**Бала:** Ярар, алайса . *(җырлыйлар, тагын берәү кала)*

**Бала:** Байтуган! Байтуган булсын!

(*бергәләп)*

**Ботенесе бергэ**: Булсын, булсын, бик күркәм,

Туры килсен үзенә.

Бай күңелле егет булып

Үссен безнең кечкенә.

**Әни:** Аллага шөкер, исем уйлап таптык бит! Әйдәгез , Мулла бабай килгәнче җырлы уен уйнап алыйк, Байтуган да ишетсен!

*Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:*

Юл читендә зәңгәр чәчәк

Якты нурлар тарата.

Безнең кызлар һәм малайлар

Йомшак мендәр ярата.

*(Туктап биеп торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри):*

Якын дуслар арасыннан

Берсен сайлап ал әле.

Тезләреңә ипле булыр -

Мендәреңне сал әле.

*Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.*

**1 бала.** Түгәрәкле уйнаганда

Әйләнеп җырлаганда.

Күңелле дә булмас иде

Сез дуслар булмаганда.

**2 бала.** Алсу чәчәкнең таҗына

Кунган зәңгәр күбәләк

Яшәү рәхәт, көн күңелле,

Дуслар белән бергәләп!

**Абыйсы:** Исем таптык бик матурны

Уянды балабыз да.

Мулла абзый да килә әнә

Төренеп чыпанына.

*(Балалар тезелеп утыралар)*

**Мулла:**

Әссәләмәгәләйкүм!

Хәерле көн сезләргә.

Исем кушу йоласын

Башлап җибәрик, әйдә.

**Әти:** әйдә, рәхим итегез.

*(Хәзрәт балага исем куша)*

**Алып баручы:**

Үз милләте көен ишетеп үссә

Халык хәтерен саклар буыннар.

Тарихлардан килгән гореф-гадәт,

Туган  телен көйли бу җырлар.

*(Балага бишек җыры җырлана)*

**Әни:** Ә хәзер барыгызны да, кунаклар, тәркем бүлмәсенә бәби ашына чакырам. Әйдәгез, рәхим итегез.

**Алып баручы:**

Саклыйк буыннарга рухи хәзинәне,
Бишек җыры-күңел көзгесе.
Киләчәктә шәхес булыр өчен
Тәүге адым,яшәү өлгесе.

Бишек җырлары-безнең киләчәгебезгә нигез сала. Балаларны шул могҗизалы җырлардан мәхрүм итмәсәк иде!Җырларыбыз учагы сүнмәсен,  алга таба дәвам итсен!

## БАЛА ТУДЫ - ШАТЛЫК АРТТЫ
**(Исем кушу йоласы)**

***Шәйдуллина Ләйсән Рәфкат кызы***
***Хөснетдинова Резедә Аюп  кызы***
*Татарстан Республикасы Биектау районы  “Сандугач” катнаш төрдәге балалар бакчасы  мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Халкыбызның рухи мәдәниятенә алып керүче тагын бер чыганак- татар халкының милли, күркәм йолалары.  Милли йолалар, гореф гадәтләр  аша, балалар халкыбызның элеккеге тормышы, яшәү рәвеше  белән танышалар. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга милли  тәрбия бирү һәм  әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә  халкыбызның гореф гадәтләрен истә тотып үткәрелгән чараларның роле бик зур. Без үзебезнең “ Бала туды - шатлык артты” дигән милли чарабызны туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышладык. Балаларны исем кушу йоласы белән таныштырдык. Шушы күркәм милли йола аша  элеккедән бүгенгә кадәр килгән һәм киләсе буынны дәвам итсеннәр иде, дигән максат белән үткәрелде.Хәзерге буын балалары милли хәзинәбезне, ана телен саклап калсыннар иде.

**Катнашалар:** Әти, әни, дәү әни, кыз, кызның сеңлесе , бишектәге бәби, кызның дус кызлары, мулла.

**Кичәнең барышы:**

(Алан күренеше, жәйге көн. Талгын көй яңгырый, ишек алдына кыз бала йөгереп чыга)

Сәфинә: Кызлар, әйдәгез уйныйбыз, килегез тизрәк. Рания, Азалия, Мәликә, буген шундый матур көн.

( Кызлар йөгереп чыгалар, шатланып сикерешәләр )

Сәфинә: Кызлар, минем зур шатлыгым бар.

Азалия: Сиңа матур күлмәк алдылармы әллә?

Сәфинә: Юк

Рания: Сиңа зур курчак алдылармы ?

Сәфинә: Юк

Зәринә: Белдем, белдем, сиңа яңа китап алганнар инде…

Сәфинә: Юк. Минем зур шатлыгым - сеңелем туды. Безнең өйгэ бәби кайтты.

( Кызлар шатланышып сикерешәләр.)

Кызлар: Ә исеме ничек?

Сәфинә: Әле исем кушмадык, буген безгә кунакка килегез, исемен бергәләп сайларбыз.

Кызлар: Киләбез, киләбез.

(Өй күренеше, талгын гына көй яңгырый. Яшь ана бишек янына чыгып утыра, бишеген тирбәтә)

Алып баручы: Бала туды буген җиргә,

Фәрештәләр аңа юл ачты.

Күкләр иле изге җаннан булган

Бер баласын җиргә озатты.

Гаиләгә шатлык булып, өмет һәм куанычлар өстәп, бала туды. Ул, үзенә бәхет даулап, тәүге авазын салды. Ана, сабыена иң иркә сүзләр әйтеп, ак биләүгә биләп, тал бишеккә салып, бишек җырын сузды.

( Яшь әни бишек җырын башкара)

Әни: Аллаху, аллаху.

Кәҗәләрне талга ку.

Кәҗә талны ашасын,

Бәби йоклый башласын.

Әни: Бәхетле бул, балам, сәламәт бул, балам, тәүфыйклы бул балам.

(Баланы бишеккә сала, кызлар килеп керәләр)

Әни: Исәнмесез ,кунаклар, түрдән узыгыз әйдә.

Куңел ачып сыйланыгыз. Сыйларыбыз өстәлдә.

Азалия: Исәнмесез, саумысез.

Бәби күрергә килдек без, нигә каршы алмыйсыз?

Рания: Күчтәнәчне, кызганмадык

Алып килдек мул итеп,

Зәринә: Бәбине күрсәтегез инде

Карарбыз матур диеп

Дәү әни: Күз тимәскә миләш тегеп.

Беләзек бүләк итәм мин.

Сау сәламәт бала булып

Үскәнен дә көтәрмен.

Сәфинә: Сеңелебезгә исем кушабыз бүген, ләкин әле исем сайламадык, бик матур исем кирәк булыр инде кечкенә бәбиебезгә. Кызлар, әйдәгез, исем сайлыйбыз.

(Кызлар тугәрәккә басалар, Сәфинә санамыш әйтә)

Карга, чыпчык, син кал, син чык.

( Уртага бер бала сикереп чыга, уйланып торганнан соң)

Азалия: Айтуган.

Рания: Кит әле, безнең бала малай түгел бит.

Сәфинә: Әйдәгез тагын . Карга чыпчык, син кал , син чык.

Зәринә: Мин таптым мин таптым, Хәят булсын .

Әни: Минем Хәят исемле кызым бар инде.

( Өйгә утын күтәреп, әти кеше килеп керә, мич алдына китереп сала, кулларын кага)

Әти: Әйдәгез Айсылу дип кушабыз, Айсылу бик матур исем, берсе Ай, берсе Сылу. Кызым , сиңа ошыймы Айсылу исеме.

Сәфинә: Әйе, әтием бик ошый.

Әни: (Кечкенә кызын кочаклап, ) Кызым, сина да ошыймы?

Хәят: Ошый.

Әти: Айсылу булсын.

( Шулвакыт бала елаган тавыш ишетелә, әти белән әни, тс-тс-тс, бала елый дип кызларны тынычландыралар, әни баласы янына китә.

Зәринә: Әнвәр абый, шушы булдымы инде балага исем кушу йоласы?

Әти: Балага исемне мулла куша, ул дога укый, азан әйтә, аннан соң исемне баланың колагына кычкыра.

Әни: Балалар, килегез, тәмле күмәч белән сыйланыгыз.

(Бүлмәгә мулла абзый керә)

( Мулла баланың баш очына килеп, дога укып, колагына укып, исем куша).

Әни: Ә хәзер, кунаклар, барыгызны да бәби ашына чакырам. Әйдәгез, рәхим итегез.

Алып баручы: Татар халкы элек-электән кунакчыл булган.Татар халкының йолаларын, гореф гадәтләрен онытмасак иде.

**ҖИТЕЗ ОРЧЫК**

(Уен-йола)

**Якупова Галия Гаптелфартовна**

*Татарстан Республикасы Сабамуниципаль районы*

*ш.т. Б.Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге*

*Саба 4нче “Кыңгырау” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем*

*муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**Татар халкының онытыла барган йолалары, гореф– гадәтләре белән балаларны таныштыру.

Бурычлар:

- Татар халык уеннары, балалар җырлары аша милләтебезгә карата мәхәббәт хисе тәрбияләү.
- Милли киемнәргә, борынгы эш коралларына кызыксыну уяту.
- Милли сәнгатькә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Җиһазлау:**

Зал татар өенә хас зәвык белән бизәлгән**.** Сандык, кечкенә мендәрләр, чиккән алъяпкычлар, түбәтәйләр, йон оекбашлар, бияләйләр, бәйләү энәләре, каба, орчык, сарык йоны, йомгаклар, бәйли башлаган оекбаш.

**Сүзлек өстендә эш:** йон, каба, орчык, оекбаш, ая.

Кичә барышы:

**Психологик халәт (кәефләрен күтәрү)**

Исәнмесез!- Здравствуйте!

-Хәерле иртә!-Доброе утро!

Сәлам, сәлам!- Привет, привет!

Балалар, бер-беребезгә уңышлы көннәр булуын теләп елмаеп алыйк та , урындыкларга утырышыйк.

**Мотивация**.

- Балалар, бүген безнең зал уртасында бик матур бер җиһаз бар. Ни икән ул?

- Сандык.

- Әйе шул балалар, серле сандык ул.

-Балалар, сез ничек уйлыйсыз, аның эчендә ниләр бар икән? (фикерләр тыңлау)

Балалар, серле сандыкны ачып анда ниләр сакланганын безгә сөйләү өчен без буген Нурсолтанның дәү әнисен кунакка чакырдык.

**Яңа белем һәм күнекмәләрне үзләштерү һәм ныгыту**

**Дәү әни:** - Әйе, балалар, бу серле сандык. Сандыктабуыннан-буынгатапшырылганбайлыкларсаклана. Әйдәгезалайса, бергәләп ачыпкарыйк, нәрсәләр бар икәнанда.. (Дәү әни сандыктан кечкен генәс андыкчык (шкатулка) ала. Бу нәни сандыкчыкта элек- электән яшь кызлар, матур хатын –кызлар үзләренең бизәнү әйберләрен (алка, йөзек, беләзек,муенса алып күрсәтә), тәсбихларны саклаганнар. Монда тагын бик матур, милли бизәкләр белән чигелгән канатлы алъяпкычларым да бар әле. (Дәү әни сандыктан чиккән алъяпкычлар ала).

**Тәрбияче:**

- Матур кызлар элек-электән канатлы, чиккән алъяпкычлар кигәннәр. Әйдәгез, матур кызларыбызга аларны бәйлик әле. Алъяпкычлар, кызларга матурлык кына өстәмәгән, аларның матур күлмәкләрен пычыранудан да саклаган, милли төсмер өстәгән. (кызларга киертеп бәйләү.)
- Егетләргә ниләр бар икән дәү әнинең сандыгында?

**Дәү әни:** - Егетләргә затлы түбәтәйләр салдым сандыгыма. Татар егетләре, чиккән затлы кәләпүшләрне киеп йөргәннәр. (малайлар кәләпүш кия).

- Безнең төркем балалары бигрәк матурланып китте бит әле.
- Милли матур киемнәребез белән Дәү әнине сөендереп бер җырлап алыйкмы әллә? (Гармун уйныйм)
- Тагын ниләр саклана , әбекәй, сандыгыңда ?

**Дәү әни:** -Сандыгымда сарык йонынннан бәйләнгән оекбашларга да урын бар. Йон оекбаш, бияләйләр һәрвакыт кирәкле хәзинә. Кышкы салкыннарда олылар да, кечеләр дә шуларны кигән.

**Тәрбияче:**

- Йон  оекбашларны кияр өчен аларны бәйләргә дә кирәк бит әле. Балалар, ничек уйлыйсыз, йонны каян алалар икән?(фикерләр тыңлана)
- Балалар, көзен һәм язын сарыкларның йоннарын кайчы белән кыркып  алалар. Аның махсус кайчысы була.  (кайчы белән таныштыру)
- Йон әзер. Хәзер бәйләп буламы инде?
- Балалар Әйдәгез, дәү әнидән сорыйк әле ничек оекбаш бәйләгәнен.

**Дәү әни:** - Мин сезгә бүген үземнең эш коралларымны алып килдем. Шулар ярдәмендә ничек сарык йоныннан җеп эрләү (җегерләү) һәм оекбаш бәйләү серләре белән таныштырырмын.
 Сарык йонын язып, аны "тетеп" дип тә әйтәләр, чүпләрдән арындыргач, үзенең махсус тарагы белән дә аярга мөмкин. Йонны аялау өчен ая дип аталган эш коралы кулланганнар. Йон кабарып, йомшап китә, шул йонны  кабага бәйлиләр. Каба- ул җепне беркетеп кую өчен элү өчен махсус   ике тактадан ясалган эш коралы.  Шуннан матур орчык ярдәмендә йон эрләү башлана. Бу вакытта орчык зыр-зыр әйләнә. (орчыкка йон эрләп күрсәтү)

**Тәрбияче:**

-Йон эрләүченең кулы, бармак очлары бик сизгер була, йонны бераз гына тартып, бер берсенә ияртеп нечкә генә, нәфис кенә җеп ясап була икән.

Дәү әнибезгә күрсәтә-күрсәтә җеп эрләгән вакытта без балалар сезнең белән "Орчык" уенын уйнап алыйк әле.

**Динамик пауза** (физ.мин.)  Орчык уены. Уртада орчыкның ике башыннан тоткан бер бала тора (орчык очлы шунлыктан, ике баш-башыннан тотуларын таләп итәргә кирәк). Калган балалар түгәрәк ясап җитәкләшеп биеп баралар. Уртадагы бала аларга каршы биеп әйләнә . Көй туктагач уртадагы бала кайсы бала каршында кала шул балага орчыкны тоттыра һәм

- "Синдә кала орчык ,
 Әйдә, уртага чык !"- ди.

Балалар бергәләп: "Без әйтәбез орчык!
 Уртага чыккан бала "Ә мин әйтәм, уенчык!" (сыерчык, кошчык, тал чыбык, чыбылдык....Рифмага туры килгән сүзләр куллана)

**Дәү әни:** - Сез бик матур уен уйнаган вакытта  орчык хәйран гына түгәрәкләнде балалар.(күрсәтә) Орчыктагы җептән йомгаклар ясыйлар. Аннары махсус бәйләү энәләр белән оекбашларны бәйләргә дә була (Энә белән таныштыру) менә шул рәвешле оекбаш бияләйләр бәйләнә дә инде.

 Рефлексия:

**Тәрбияче:** Без бүген Нурсолтанның дәү әнисе белән бергәләп серле сандыкны ачтык. Инде аны ябар вакыт җитте. Сандык эченнән чыккан милли киемнәрне, кулланылган эш коралларының исемнәрен атап җыеп куярга кирәк инде.

- Я,кем әйтер нәрсә салабыз сандыкка? (Йон оекбаш, йон бияләй, орчык бәйләү энәләре, йомгак, ая,түбәтәй, алъяпкыч....) балалар белән өйрәнгән эш коралларын, милли киемнәрне кабатлау.

- Нурсолтанның дәү әнисенә безнең кичәбезгә килгән, шундый эчтәлекле итеп аңлаткан өчен зур рәхмәт! (балалар белән рәхмәт әйтү)

## КАПКА ТӨБЕНДӘ

***Әхмәдуллина Фәридә Фәрит кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының*

*«Гомуми үсеш бирүче төрдәге Балтач 2нче номерлы балалар бакчасы»*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Өй күренеше.** Өй алдында эскәмия. Матур пәрдә эленгән ачык тәрәзәдән бала бишеге күренә. Кызлар шау-шу килеп йөгереп керәләр һәм өй каршындагы эскәмиягә утыралар. Малайлар керә.

1 малай: - Исәнмесез, саумысыз?
Нигә кәҗә саумыйсыз?
Әтәчегез күкәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз?

2 кыз: - Әй, Әпсәләм, әпсәләм
Сәләм бирдем:- Әпсәләм
Синнән безгә тиештер бит.

Малайлар:- Вагаләйкемәссәләм!

2 кыз: - Шуннан!

2 малай: - Тугыз ким уннан.

Кыз: - Шуннан?

Малай: - Утырган да шуган.

Кыз: - Шуннан?

Малай: - Кишер белән суган.

Кыз: - Шуннан?

Малай: - Койрыгы тунган.

3 малай: - Әйдәгез, җырлап-биеп уйныйк әле.

“Алларын да алырбыз” (татар халык көе) дигән көйгә кара-каршы җырлап әйләнәләр, бииләр.

Уйнасак та, җырласак та,
Гармун кулларыбызда,
Алсу гөлләр чәчәк атсын
Йөргән юлларыбызда.
Кушымта: Алын алырбыз микән,
Гөлен алырбыз микән,
Урталарга чыгып сайлап
Кемне алырсыз икән?
Алларын да алырбыз,
Гөлләрен дә алырбыз;
Күңелебезгә кем ошаса
Шуны сайлап алырбыз...
Челтер элдем читәнгә
Җилфер-җилфер итәргә,
Без килмәдек буш китәргә
Килдек алып китәргә.
Кушымта: Алын алырбыз микән,
Гөлен алырбыз микән,
Урталарга чыгып сайлап
Кемне алырсыз икән?
Алларын да алырбыз,
Гөлләрен дә алырбыз;
Күңелебезгә кем ошаса
Шуны сайлап алырбыз...

3 кыз: - Ә мин сезгә хәзер бер кызык такмаза сөйлим.

Җиктем үрдәк,
Киттем үрләп,

Җиктем күркә
Баганадан өркә.
Чанам кабык,
Төядем чыбык-чабык.
Барам чабып,
Киттем авып.
Тәртәсе салам,
Төшәм дә калам,
Төшәм дә калам.
Ничек кайтып җитәргә?
Аптырадым бит тәмам.
1 малай: Кызлар, малайлар, әйдәгез такмаклар әйтешәбезме?
Балалар: Әйтешәбез.
Такмаклар
Малайлар: Бака, бака, бакырган,
Бака кунак чакырган.
Кунаклары килмәгәч,
Тышка чыгып акырган.
Кызлар: Ике сарык юлга чыккан
Кулларында чемодан,
Иреннәрен буяганнар,
Ә битләрен юмаганнар.
Малайлар: Йөгереп чыктым бакчага,
Бастым такыр тактага.
Ике конфет сатып алдым,
Сукыр бер тиен акчага.
4 кыз: - Әх, бар иде яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар,
Саламнан тәртә каерып,
Кырмыска җиккән чаклар...
5 кыз: - Әйдәгез тәңкә салыш уйныйбыз.

“Тәңкә салыш” уенын уйныйлар. Тәңкә учына салынган балалар җәза үтиләр (я җырлап, я биеп күрсәтәләр). Биючеләргә балалар такмак әйтеп торалар:

Әтәчтә дә кикерик,

Тавыкта да кикерик.

Биючегә сүз әйтмәгез,

Үзе төште сикереп.

Әбиемнең кәҗәсе

Бакчада кәбестәдә.

Биемәгәч, җырламагач,

Син монда нәмәстәгә.

Биюченең итәге

Бии-бии сөйрәлә,

Биючегә сүз әйтмәгез,

Бии-бии өйрәнә.

Ике карга суга бара

Сыңар чиләген асып

Безнең мәче карап кала

Баскыч төбенә басып.

*Тәрәзәдән әни эндәшә:*

Әни: Балалар, бик тавышланмагыз әле, мин бәби йоклатам.

(Ул бишек җыры җырлый).

Әллү-бәллү итәргә

Ал бишеге бар моның

Өзгәләнеп тирбәтергә

Үз энисе бар моның.

Әлли-бәлли бәбкәсе,

Чәй әзерли әнкәсе,

Бал китерә әткәсе,

Бармаклар бу бәбкәсе.

Әткәсенә нисе бу?

Алтын ияр кашы бу.

Әнкәсенең нисе бу?

Йөрәгенең мае бу.  (Балалар тыңлыйлар).

Әни: - Улым, көтүне узең каршыларсың әле. (Әни тәрәзәне ябып куя).

Көтү кайткан тавышлар (аудиоязмада) ишетелә. Хайван битлекләре киеп балалар керәләр. Көтүче бабай күренә.

1 кыз: (кәҗәне үртәп)

Кәҗә, кәҗә, кәҗәкәй,

Кермә минем бакчага

Кысылырсың, уләрсен

Йөз сум акча түләрсең.

2 малай: - Бабай, кая, узем куам көтүне. (Бабайның чыбыркысын алып көтүне куып китә, бабай күләгәгә барып утыра).

2 кыз: - Бабай, курайда уйнап күрсәт әле.

Бабай: - Хәзер, балакайларым, уйнармын. (Ул кубыз алып уйный башлый).

1 малай: - Бабай, бу кубыз бит.

Бабай: - Ай, әфәрин, балалар. Сез күп беләсез икән. Кубыз – татар халкының иң борынгы музыка коралларыннан берсе. Аны элек агачтан, сөяктән ясаганнар. Хәзер тимердән ясаган кубызларда уйныйбыз. Ә сез кубызда уйный беләсезме?

3 малай: - Беләбез, без бакчада өйрәндек. Менә хәзер "Әпипә" көен уйнап кәрсәтәбез. (балалар кубызда, бабай курайда уйныйлар).

Бабай: - Менә монысы сез сораган курай була инде, балакайларым. (Шуннан соң бабай сорнай чыгара. Аның белән таныштыра).

Бу – сорнай. Ул мөгездән һәм агачтан ясалган. Мөгезне тавыш көчлерәкчыксын өчен куйганнар. Әгәр сез аларда уйнарга теләсәгез миңа хәбәр итәрсез, мин сезне өйрәтермен. Ә сез үзегез нинди уен коралларында уйный беләсез? (Балалар төрле уен коралларыннан торган оркестр белән татар халык көе "Әпипә"не башкаралар).

Бабай: - Бик матур уйныйсыз икән бит, балалар. (Ул кулъяулыгы белән тирен сөртеп ала).

2 кыз: - Бабай, кулъяулыгың бик матур икән.

Бабай: - Матур шул, аны Әсма әбиегез яшь чагында ук чигеп биргән иде. Шуны бик кадерләп саклыйм. Хәзер мондыйларны чикмиләр бугай инде.

1 кыз: - Чигәләр, бабай, менә безнең әниләр нинди матур кулъяулыклар чигеп бирделәр. (Балалар кулъяулыкларын күрсәтәләр).

Бабай: - Бик матур шул, балалар. Татар халкының киеме дә көзгедәге кебек аның матур, күркәм күңел сыйфатлары чагылган. Ул һәрвакыт матурлыкка омтылган. Татар халык җыры "Матур булсын"ны җырлап кичә тәмамлана.

Син дә җырла, батыр егет,

Син дә җырла, матур кыз!

Матур булсын, матур булсын,

Матур булсын бу тормыш!

Безнең ил кояшы балкый

Якты булыр көн саен;

Якты булсын, якты булсьн,

Якты булсын көн саең!

Илебезнең халыклары

Матур тормыш коралар;

Тыныч булсын, тыныч булсын,

Тыныч булсын дөньялар

## УЯТЫЙК ӘЛЕ, САБЫЙ КҮҢЕЛЕН

**Әдһәмова Кадрия Вәсим кызы**

*«Гомуми үсеш бирүче №7 Актаныш  балалар бакчасы"ның югары категорияле тәрбиячесе*

*(икенче кечкенәләр төркеме әти- әниләре катнашында татар фольклоры кичәсе)*

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Уртада татар кызы һәм татар егете курчаклары. Чигүле сөлгеләр, милли табын итеп әзерләнгән өстәл зал бүлмәсен бизи.  Татар халкының бию көенә биеп балалар залга керәләр. Әти- әниләр каршына басалар.

1 бала. Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар!

2 бала Хәерле көн, әбиләр, бабайлар!

3 бала  Хәерле кич, әтиләр, әниләр!

Алып баручы: Алда, арта һәм уртада утыручылар!

Урын юктан  аптырап басып торучылар!

Балалар бергә: Исәнмесез!

"Ай  йолдызым " исемле татар җырының көе ишетелә.

Алып баручы: Бүген бездә гадәти булмаган кичә-“Уятыйк әле сабый күңелен“ дип исемләнгән татар милләтенең милли кичәсе. Без бүген әби-бабаларыбызның, эти- әниләребезнең күңел сандыгын актарабыз. Шулай ук алар үрнәгендә үзебез дә милли йөзебезне күрсәтербез, нәниләребезнең күңелләрен уятырбыз

Тимур: Исәнмесез, саумысез, һәрберегез, барчагыз.

Бездән сезгә кайнар сәлам- кабул итеп алсагыз.

Гомәр: Исәнмесез, саумысыз?! Нигә сыер саумыйсыз?!

Сыерыгыз бозаулаган Нигә чыгып алмыйсыз?!

Әминә: Исәнмесез, саумысыз? Нигә кәҗә саумыйсыз?!

Әтәчегез күкәй салган, Нигә чыгып алмыйсыз?!

Марьяна:Карап тормый ара еракка Күпме кеше килгән кунакка.

“Алтынчәч” булыр бәйрәм үзәге Фольклор булыр бәйрәм бизәге.

Мәдинә: Бәйрәмсез бит күңелсез бит Күңелсездер Сезгә дә,

Бәйрәмнәр кирәк безгә дә,Бәйрәмнәр кирәк Сезгә дә,

Кирәк һәммәбезгә дә. Бәйрәмнәр кирәк әтигә!

Бәйрәмнәр кирәк әнигә! Бабай белән әбигә!

А.Б. Бәйрәмнәр бик күп болай да Ә шулай да, ә шулай да

Иң күңелле бәйрәм.. Бергә: балачак!!!

А.Б. Һәр гаиләнең үз традицияләре, үз бәйрәмнәре бар. Аларны һәркем үзенчә үткәрә. Бәби туйлары, баланың беренче мәртәбә "әннә” "әттә” диеп эндәшүе, балалар бакчасына, мәктәпкә йөри башлавы һәр гаиләгә бетмәс-төкәнмәс шатлык китерә. Туган көннәрне билгеләп үтү дә матур бер традициягә әверелде. Бүген исә, матур бәйрәм бездә- фольклор кичәсе.

Гомәрнең әнисе Зөһрә: Гаиләнең ныклыгы, матурлыгы бик күп нәрсәләргә бәйле, хәзер мин шуларның берсе турында табышмак әйтәм, ә сез исә барыгыз да аның җавабын уйлагыз:

Кайвакыт корыч кебек каты, кайчагында баллы, татлы,

Ә кайчакта-әремнән дә әче, кайвакытта кылыч кебек үткен,

Елан кебек чага да белә ул... Залдагыларның җавабы: тел

А.б. Дөрес, тел. Рәхмәт, Зөһрә. Аның турында әти-әниләребез нинди мәкальләр белә икән?

-Явыз тел мылтыктан куркынычрак.

Кеше сүзе кеше үтерә.

- Телнең буе кече, гөнаһысы олы.

-Телчән теленнән табар.

-Тик тормаган тел башка бәла китерә.

-Үтергән дә тел, тергезгән дә тел.

-Теле авызына сыймый.

-Теле белән тере агачны корытыр.

-Теле татлы, күңеле каты.

-Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел

А.Б. Балалар арамадыгызмы?

Алидә: Ә без арымадык әле,        Бу көн безгә тантана.

Гармунчылар керегез                Бию уйнап бирегез.

Бүген милли бәйрәмдә           Ут чыгарып биибез.

А.Б. Ә беләсезме, бар икән бит әле ул милли көйләребезне чыгаручы гармунчылар, баянчылар. Бер дә җир читендә дә түгел, башка шәһәрдә дә түгел, мәдәният йортында да түгел, ә менә үзебезнең әтиләребез арасында икән ич. Раилебезнең әтисе- Агыйдел җыр һәм бию ансамблендә дә хезмәт куя, юл төзүче һөнәрен дә үзләштерде. Ә менә Лилиябезнең әтисе Руслан абыегыз ООО "Челны бройлер" да инженер. Аларны баян белән дус булулары берләштерә. Яле аларның бик күркәм чыгышларын карыйк.

Баянчылар чыгышы.

А.Б. Ягез әле, баян көенә ут чыгарып бер биеп алыйк.Татар халкының әпипә биюе. Ахырдан балалар өлкәннәргә басып бииләр.

Лиана: Җырлыйк әле, җырлыйк әле.Өчтән артсын җырыбыз.

Җыр җырларга сүзләр бетсә,Такмак әйтеп торыгыз.

Әйе, шул, шулай, шул Такмак әйтеп торыгыз.

Самат, Алисә: Биек тауның башларында лимонад өләшәләр.

Беребез кыю, беребез матур, шуңа да көнләшәләр.

Ильмирның әти- әнисе: Татарча кая барасың, урысча куда пойдешь,

Улыбыз (кызыбыз) компьютер сорый, пожалуй с ума сойдешь

Раян, Эмиль: Биек тауның башларында трактор буксовать итә.

Безнең төркем кызлары, безне сортовать итә.

Алидәнең Әнисе: Әптчи, әптчи, әнә бара карт песи, Койрыгын төйнәгән, балаларын төягән, койрыгы чишелде, балалары ишелде.

Алидәнең Әтисе: Әти биштә, мин унбиштә, киттек заводка эшкә,

Әти елый мин тибрәтәм, бүрек хәтлек бишектә

Ике бала( теләк буенча) такмаза әйтешә:

-Монда май бар иде кая киткән? -песи ашаган.

Песи кая киткән? -Салам астына качкан.

Салам кая булган? -Сыер ашаган?

Сыер кая киткән? су эчәргә киткән. -Су юлы кая? ....Кети кети кети

А.Б. Арабызда рус милләтеннән булган кунагыбыз- Павелның әнисе Юлия Валентиновна бар. Ул безгә рус халкының такмакларын башкара. Юлия Валентиновна, прошу Вас - ваш выход.

А.Б. Безнең егетләребез дә, кызларыбыз да әниләргә булышулары турында бик матур итеп сөйлиләр. Чынлап та ни дәрәҗәдә булышалар соң? Берничә әти- әни сөйли.

А.б. Ә хәзер Таңсылуның әнисенә ничек булышуы турында тыңлыйк..

14. Таңсылу:Мин дә кер юдым! Сабынлап юдым, әни!

Әнисе: Ай.кызым,үкәнсең Бигрәк чиста иткәнсең.

Таңсылу: Мин дә идән җыйдым, әни! Сабынлап юдым, әни!

Әнисе: Ай, кызым, үскәнсең, Бигрәк матур иткәнсең!

Таңсылу: Мин бәрәнге юдым, әни! сабынлап юдым, әни!

Әнисе: Ай, кызым, үскәнсең, Нишләдең?!

А.Б. Ягез әле, бергәләп татар халкының йола, бәйрәмнәрен, уеннарын санап карыйк.

Балалар һәм өлкәннәр кара каршы саныйлар.

Инде кара-каршы уен-җырларга да чират җитте. Әйдәгез уйнап алабыз.

Җырлы татар халык уены "Зәңгәр чәчәк". Кызлар, егетләр түгәрәктә тотынышып әйләнә әйләнә җырлыйлар. Бер кыз кечкенә мендәрчекне ала. Икенче куплет дәвамында ул мендәрне тотып, бер егет каршына баса, идәнгә мендәрне сала, кушымтада бию көенә парлашып бииләр, калган балалар кул чабып тора.

А.Б. Татар халкы бик ягымлы бит ул. Матур телле, ягымлы сүзле. Әбекәйләр безгә "Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел" дигәннәр бит. Бер әбекәебез дә үзенең әбекәеннән ишеткән ихлас теләкләрен безгә җиткерә .

Дәү әни: Тыңлагыз әле, мин кечкенә чагымда да әбием миңа болай дия иде.Таштан таза булсын, судай сылу булсын,

Аталы-аналы булсын,алтын канатлы булсын,

Ипиле-тозлы булсын, уллы-кызлы булсын,

Тәүфиклы бала булсын, яшьләрне күрсә "абый" да "апа" дисен,

Картларны күрсә"әби"дә "бабай" дисен,

Бәхетле булсын, тәмле телле булсын.

А.Б. балаларның чыгышларын дәвам итәбез:

Самат:. Безнең ялан күлле, күлле Ясле бакчасы гөлле.

Ясле бакчалары гөлле. Уйнаулары күңелле.

Ильмир: Басыгыз әйдә, кызлар, Идәннәре бөгелсен.

Баса белми басканнарның Үзәкләре өзелсен.

А.Б. Әйдәгез, дусларым. "Матур уен" уйныйк, булмаса.

Зәлия: Ал да итәрбез әле Гөл дә итәрбез әле

Матур җырлар җырлый-җырлый Бәйрәм итәрбез әле

Павел: Тыпыр-тыпыр тыпырдашып Бергә басаек әле

Уйнап көлеп, җырлап биеп Күңел ачаек әле.

Айлинә: Әй дүдәле, дүдәле, Гармунчыбыз өйдәме?

Өйдә булса килсен әле биетеп китсен әле!

А.б. Гармунчы, нинди сихри исем Абруе зур, урыны түрдән.

Фольклор кичәбездә катнаша ул, Әйе, аның урыны түрдән.

Әлбәттә, гармуны, баянчы дәү әтиебез Лилиянең бабакае- Айрат абый Хазиев- бәйрәмебездә өлкән кунак. Аның чыгышын да тыңлап узыйк әле. Малайлар җыелыгыз әле, баянчыбыз янына тезелешеп утырыгыз әле, сезнең дә күңелләрегез уянсын.

А.Б.Балалар, иң зур эшебез- уен. Хәзер курчакларыбыз белән уенны карыйк әле. Әтиләр чыгып, ”Бәбиләрне” алалар һәм йоклаталар.

Бишек җыры җырлау Тукай сүзләре, халык җыры

Ике әни "Бәбиләрне” уяту, юату сүзләрен әйтәләр.

Марьянаның әнисе: Тор инде, тор инде. Йокың туйгандыр инде.

Бакчадагы апаларың Көтә торгандыр инде.

Тор тургай, таң ата бугай, Тор чыпчык,чык-чырык

Тагын ике әни чыгып, бәбиләргә мавыктыргыч уеннар уйнаталар. 1 се юата.

Лилиянең әнисе: Аю баласы булсын, бүре баласы булсын,

Бүреккә саласы булсын.Атасына, анасына Шәфкатьле бала булсын,

Сүзе үтемле булсын, үзе сөйкемле булсын.

"Бәбиләр” әниләргә тапшырыла. Алар да "Бәби”йоклата.

А.Б. Ә без әле бер-беребезне үртәргә дә бик яратабыз. Үртәвечләр әйтешү.

Ильдан: Ишми, Ишми, мич башыннан төшми,

Мич башыннан төшми, ничек тәне пешми.

Рахман: Елак-елак, салпы колак, карама таяк, карт әтәч!

Назил: Әллүкәй, әллүкәй,Шакир һаман бәләкәй.

Бармак белән тисәң дә , әткәсенә эләкләй.

Рианна: Җылак-җылак җылкыткан, җылап кеше куркыткан.

А.Б. Безне бик күңелле уеныбыз көтә. Милли уен “Эх, Зилем, Зиләле!”

29. А.Б. Раиль Актаныш авыллары турында бик матур такмаза өйрәнгән.Сүзне аңа бирик әле.

Бара идем, бара идем, Алдымда- Такталачык

каршымда- капка ачык

Барадыр идем, барадыр идем очрады Уразай

Аяк кулы курадай, корсаклары бурадай.

Алга чыкты Әҗәкүл янында бар бер күл.

Килеп чыкты Актаныш ул булды безгә таныш.

Актаныш арты Әлем, анда барыр юк хәлем.

Аннан үткәч Богады, барыр хәлем юк әле.

Арырак бар Кормаш шунда җитми булмас.

Барган идем Аешка утырттылар каешка.

Барган идем Меңнәргә утырттылар мендәргә.

Барган идем Аккүзгә ошаттылар тоз күзгә.

Барган идем Пучыга шап суктылар учыма.

А.б. Рәхмәт, Раиль. Безнең әбиләр әйткән бит "Яшьләр сүзен янчыкка, картлар сүзен капчыкка" дип. Әти- әниләрнең дә әйтер зирәк сүзләре җыелган тыңлыйк әле.

Әтиләр, балаларга зирәк тыюлар турында сөйли.

Пычактан ашама, зәһәр телле булырсың.

Суга төкермә, үзең эчәрсең.

Ашаганда аягыңны селкемә, шайтан чакырасың.

Кич белән идән себермә, өйдән бәрәкәт качар.

Мендәр ишелеп төшсә- кунак көт.

Саескан шаркылдаса да кунак килер.

Кырлы пыяла аша карама- киявең шадра булыр.

Кашыкны шакылдатма- тавыш чыгар.

Өйдә сызгырма- давыл чыгар.

Малай Без күмәк уен уйнадык ич, яле эти- әниләребезне дә уенга дәшик.

Җырлы-биюле татар халык уены. "Чума үрдәк, чума каз"

А.б. Әтиләребезгә дә бирем калды бит әле безнең. Мин 4 әтине бирегә чакырам. Алар әлеге биремне үтәргә тиеш булалар.

Әтиләргә тизәйткечне тиз әйт, дип, кәгазьгә язылган биремнәр тапшырыла.

1.Мич башында 5 мәче. 5 мәченең 5 башы.
5 мәченең 5 башына ишелмәсен мич ташы

2.Кара кара кара карга кырга карый карый бара.

3.Абагага бага бага башым бәрдем баганага.

4. Капкага капка каршы, Капкага капка капма-каршы.

5. Талга кунар бер тартар, Ул тартарны тал тартыр,
Тартар басып талны тартыр,
Тал тартыр, тартар калкыр, Тартар калкыр, тал тартыр.

6. Торма тора тырмада, Торна төште тырмага.

Торма, торна, тырмада. Торна, торма тырнама.

Тукта, тотыйм тырманы, Торна туктап тормады.

Тотып торам тырманы, Торна тишкән торманы.

7. Дару белән өч шешә, Шешә бавын теш чишә, шешә чишсәң теш шешә.

8. Ат та йөри Карда, Карт та йөри Карда.

Атның Картасы бар, Картның Картасы бар.

Карта карап карт та Арып калган артта

А.Б. Районыбызның “Йолдызлык” бәйгесе җиңүчеләренең дә чыгышын карап үтик әле.

ЛИЛИЯ: Нинди төстә икән бәхет? Акмы яки карамы?

Әчеме ул, бик татлымы? Кемнәр татып карады?

Зурмы, әллә кечкенәме? Кайда яши, кай җирдә?

Һич төшенә алмыйм шуңа, Бәхет дигән бу сергә.

РАИЛЬ: Кайда яши, кай җирдә, дия дия мине эзлисеңме син, Лилия?

ЛИЛИЯ: Бәхетне эзлим әле мин, Раиль, синең күзеңә чалынмадымы?

РАИЛЬ:Ә беләсеңме, Лилия, безнең өйдә бит ул бәхет.

ЛИЛИЯ: Әләй, әллә чынлап әйтәсеңме, Раиль?

РАИЛЬ: Чып- чын менәәә..бәхетнең бик зур дигәне әнием тибрәткән бишектә ята. Ярты ел элек кенә туган сеңлемнең бишегенә әтием белән әнием иелә дә, зууур бәхетебез безнең, диләр..... Ә татлы дигәне менә синең каршыңда елмаеп басып тора.

ЛИЛИЯ: Китчәле, егетләр татлы була димени?

РАИЛЬ: Булмаган, ди менә. Әбиемнәргә килеп керүем була, “тәмлүшкәм килгән” дип, кочагын җәеп килеп чыга.

ЛИЛИЯ: Синең белән бәхәсләшеп булмый инде, Раиль. Булмаганны табып бирерсең син!

РАИЛЬ: Мин үзем сәләтсез түгел, күп нәрсә сөйли беләм

Теләсәгез сезнең өчен Әкият сөйләп бирәм.

ЛИЛИЯ: Әкиятеңне сәхнә артында сөйләрсең, әйдә, монда дусларыбыз чыгыш ясарга чират көтәләр.

РАИЛЬ: чыгып барышлый сөйли: Су буенда таллар үсә, былбылларга тәхеткә.

Бер әкият сөйләп бирсәм, ирешер идем бәхеткә.

Кызлар ярымтүгәрәккә басып, “Әтиемнең йолдызы мин” җырын башкара.

Малайлар кулларына рульләр тотып, “Мин – шофер” җырын башкара.

А.Б. Бүгенге күркәм фольклор кичәбез гаилә елы уңаеннан

Узды. Илләребез тынычланып, күкләребез һәрчак аяз, кояшлы булса иде, әтиләребезүз янибызда булып, гаиләләребез тулы булса иде, дигән теләктә кичәбезнең ахырга житүен

хәбәр итәм. Сезгә саулык- сәламәтлек теләп, Мәдинәбезнең әнисе Мирзиева Айзәрәдән музыкаль сәләм.

А.Б.Эшләрегез үрнәк булсын, байлыгыгыз артып торсын.

Гомерегез озын булсын,  Бәхетегез ташып торсын! Сабыйларыбыз сәламәт булып, елмаеп торсын!

## ШЫЙЛЫК

***Сабирҗанова Гөлфирә Гомәровна***

*Казан шәһәре 134 нче балалар бакчасы*

Чәчүлек орлыкны изгеләндерү өчен бөтен җәмәгать җыелып дога уку һәм күмәкләшеп сыйланудан гыйбарәт булган бу йола. Бу йола нигездә керәшен авыллары өчен характерлы булган. Гадәттә аны сөрәннән соң – ат менгән егетләр йомырка җыйганнан соң билгеле бер урында – авыл уртасындагы мәйданда яки авыл читендә  үткәргәннәр. Билгеләнгән көнне бәйрәмчә киенеп шунда килгәннәр.

Бәйрәмгә килүче хуҗа кеше үзе белән азык – төлек һәм орлык салынган җилпуч алган. Хатын – кызлар исә төш вакытында бәйрәмгә барганда үзләре белән сөтле борай яки тары боткасы салынган зур җамаяклар алганнар.

Шыйлыкны үткәрү ритуалы менә ничек булган. Бөтен авылның җилпучлары рәт – рәт итеп -алтышар яки күбрәк рәтләргә тезеп куела. Һәммәсе җыелгач , һәр хуҗа үзенең җилпучын кулына ала һәм кинәт барысы да төшлек якка борылып , җилпучларын күкрәк турысында тоткан килеш , бил бөгеп баш ияләр һәм ходайның уңыш бирүен сорап ялваралар. Часовня янына зур савыт куела. Берничә карт һәр җилпучтан җамаягы белән берәр ипи алып,элеге савытка алып киләләр дә ,җамаяктагы бөтен нәрсәне шунда салалар,әрчегән йомырканы да шунда ташлыйлар. Эремчек ,бал,каймак һәм йомыркадан торган шушы катнашманы таяк белән туглыйлар. Ипинең уртасыннан ике калын телем телеп алалар. Телемнәр савыт янында калдырыла,ә ике кибән башын кире җилпучка салалар. Бу вакытта халык сырадан һәм балдан авыз итә. Хатын-кызлар эскәмиядә утыралар ,ә ир-атлар аяк өсте басып тора. Сыйланыр алдыннан шушы ук картлар часовня каршысында дога укыйлар.

Изгеләндеререлгән орлык,ипи һәм башка ризыкны язгы чәчүгә кадәр саклап тоталар. Дога укудан һәм күмәк сыйланудан башка,шыйлык йола тәртибендә җир сөрү һәм чәчүне дә үз эченә ала. Хуҗа хатын басуга чыгар алдыннан җигүле ат өстенә он сипкән. Хуҗа кеше үз басуының юл буенда өч сажин озынлыгында һәм бер сажин киңлектә җир сөреп,солы яки борай яисә бодай чәчкән. Туфракка орлык белән йомыркаларны салганнар. Шуннан соң җамаякта булган ризыкны ашыйлар. Аннары төрле ярышлар үткәргәннәр.

## ОРЛЫК ЧЫГАРУ

***Яруллина Ләйсән Фирдинатовна***

*Казан шәһәре 134 нче балалар бакчасы*

Язгы (чәчүгә кадәрге) йола һәм бәйрәмнәр циклы чәчү башлануга багышланган йолалар белән төгәлләнгән. Теге яки бу формада алар Урта Идел һәм Урал татарларының барысына да хас булган. Казан татарларының күпчелегенә алар орлык чыгару йоласы рәвешендә үткән.

Казан татарларында "орлык чыгару” йоласы түбәндәгечә үткәрелгән. Иң башта мунча якканнар. Урамга чыккач, беренче очраган кешегә, юл уң булсын дип, йомырка биргәннәр. Чәчкән вакытта туфракка орлык белән бергә өомыркалар да ташлаганнар, ә беренче чәчү көнендә, басуга чыккан балалар ул йомыркаларны җыя барганнар. Бераздан, җиргә ашъяулык җәйгәннәр һәм бергәләшеп йомырка, өйдән алып килгән башка ризыкларны ашаганнар. Ашап-эчкәннән соң: "Хәерле янгырлар булсын, еллар тыныч булсын, йомырка кебек түгәрәк булсын!” – дип теләк теләгәннәр.

Мишәр авылларында исә чәчүгә чыккан көн башкачарак билгеләнгән.Иртәгә чәчүгә чыгасы көнне һәр өйдә ярлыларга һәм ятимнәргә өләшү өчен кечерәк кенә шишаралар пешергәннәр.Ипи шишараларының берсен юка телемнәргә телеп,тоз сипкәннәр.Беренче телемне бабай-хуҗа,калганнарын гаиләнең башка әгъзалары ашаган.Басуга чыгар алдыннан бер кыерчык ипине атка ашатканнар.Кайчагында исә ярлы-ябагайларга ашлык,йомырка.бераз он бирә торган булганнар.Һәр йорт хуҗасы өендә мөселман йоласы буенча хәтем иткән,Коръән укыткан.

Кайбер авылларда бу көнне юача пешергәннәр һәм ашлыклар юача төшләре кебек эре булсын дип теләк теләгәннәр.

Шуның белән бергә, Казан татарлары, төгәлрәк әйткәндә керәшеннәр белән аралашып яшәгән мишәр авылларында татарларга хас йолалар да очраган. Мәсәлән, Спас өязе Әлки авылында чәчү көнне йомырканы җиргә күмеп җиргә садака бирү йоласы язып алынды. Бу вакытта мондый сүзләр әйткәннәр:

Җир хуҗасы Суар ата,
Суар ата су ярата.
Иген тулы амбарда
Бир,Ходаем,мул уңыш.
Игенем түгел капта,
Киң өсәктә.

Иген бирү синнән,
Хезмәт миннән,
Әремнәр шаһит булыгыз,
Бер Ходаем тапшырдым.

## КАЗ ӨМӘСЕ

**Нуриева Гөлия Раиф кызы**

*Балык Бистәсе районы , Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү  мәктәбенең мәктәпкәчә төркем тәрбиячесе*

(Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен)

**А.б:** Хәерле көн,кадерле кунаклар! Бүген без татар халкының традицион бәйрәме – каз өмәсенә жыелдык. Каз өмәсе ул татар халкының иң көтеп ала торган күркәм йолаларының берсе. Авылларда элек-электән күп көч сорый торган эшләрне бергәләшеп, өмә ясап башкарганнар. Күп каз асраган гаиләләрдә каз өмәсе оештыруны тормыш үзе таләп иткән. Өмәдә барыннан да элек кызларның уңганлыгы сыналган. Борынгылар кул арты китә дип каз канатын кешегә бирмәгәннәр. Биргәндә дә канат очын кешегә сиздермәслек итеп кисә ала торган булганнар. Безнең борынгы бабаларыбыз казны бик яратканнар.  Каз  мамыгыннан мендәр, тушәк, ястык ясаганнар. Каз итеннән аш-су, күп төрле каз ашлары да әзерләгәннәр. Каз бәлеше , каз коймагы, тәбикмәге, каклаган каз. Каз маен дәва өчен кулланганнар. Кышкы суыкларда бит, колак очлары өшесә, каз мае сөрткәннәр. Ә менә пар каз туйның хөрмәтле

күчтәнәче булган. Хәзер дә шулай дәвам итә. Аны кунакларга: “ Менә, кодагыйлар күчтәнәче” дип,- мактый-мактый ашатканнар. Нәрсә дип мин боларны сөйләп торам әле. 10 мәртәбә ишеткәне 1 күрү хәерлерәк диләр бит татар халкында.

Беренче күренеш.

Авыл өе күренеше . Талгын гына татар халык көе яңгырый.

**Кыз:** Әни, бүген бездә бәйрәм мәллә!

**Әни:** Әйе,кызым. Бүген бездә “Каз өмәсе”. Бар кызым,каз өмәсенә дус кызларыңны чакырып кил.

**Кыз:** Ярый, ярый әнием, хәзер чакырам. (йөгереп чыгып китә)

Музыка яңгырый. “Ай былбылым,вай былбылым” җырын җырлап кызлар чыгалар.

**Әни:** кызларыбыз өмәбезгә килеп тә җиткәннәр.

**Кызлар:** Исәннәрмесез! Килдек, бик куанып килдек рәхмәт чакырганызга . Йортыгызга бәрәкәт иңсен! Өстәлләрегезгә сыйлы булсын!

**Әни:** Әйдәгез, әйдәгез, узыгыз, утырыгыз.

**Әти:** (казлар тотып керә) Безнең уңган күрше кызлары кереп тә җиткәннәр.

Менә сезгә казлар,баш-аякларын, канатларын кистем,җырлый-җырлый армыйча эшләгез (чыгып китә)

**Әни:** Әйдәгез, эшкә тотыныйк алайса. Иң элек култык астыннан харам канатларын йолкып алыйк. Аннары яндырырбыз. Хәзер калган канатларын йолкабыз. Кая әле кызларым, һәрберебезгә каз бирәм,йолкый башлагыз. (Кызлар каз йолкыйлар )

**1 кыз:** Казларыгыз бигрәк матур ,

Таза булып ускәннәр.

Ә йоннары,каурыйлары

Мамыкланып беткәннәр.

**2 кыз:** Кыйгак-кыйгак дип кычкыра ,

Әллә киек казлармы?

Җырлап-биеп каршы алыйк

Быел килгән көзләрне.

**3 кыз:** Кызлар, ә сез белзсезме?

Каз ярата елганы.

Йөзә дә ул,чума да ул,

Су үстерә бит аны.

**4 кыз:** Көз көннәре бигрәк ямьле,

Өмәгә килгән кызлар.

Матур булсын каз өмәсе,

Әйдәгез,җырлыйк кызлар!

Җыр “Каз канаты” (т.х.к)

1.Каз канаты ак була,

Ир канаты ат була.

Чит җирләрдә йөргән чакта,

Бик сагынган чак була.

2. Каз канаты каурый-каурый,

Коймак майларга ярый.

Уйнамагач та,көлмәгәч

Бу дөнья нигә ярый.

**5 кыз:** Миңа бигрәк зур,симез каз эләкте.

**6 кыз:** Әйе, быел бигрәк уңды шул казлар. Өй борынчы каз. Иртәгә дә өмә!

**Әни:** Балалар, казларын мамыгын аерым,каурыйларын аерым салыгыз. Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына торган мендәр ясыйм әле. Каз мамаыгыннан гына торган мендәр бик йомшак була. Аңа яту белән эреп китәсен инде. Бу каз мамыкларыннан да җыйнак кына ике мендәр ясыйм әле.

**Кыз:** Әтием эрепләр китәр инде яңа мендәрдә йоклап. Иртән йоклап кала күрмәсен тагын. (көлешәләр)

**Әни:** Кызлар, йолкып бетергәч казларны әнә теге өстәлгә куярсыз. Үзем эчләрен алып,эшкәртеп бетеремен.

( Урам якта капка тавышы ишетелә)

**1 малай**: Шыгыр-шыгыр капканы

Шыгырдатмый япмабыз.

Каз өмәсе булган җирдән,

Беребез дә калмабыз. ( Керәләр)

Малайлар бер-бер артлы:

-Исәнмесез, барчагыз

Бездән сәлам алыгыз!

Сәлам,матур кызларга.

Өмә күрке – казларга. (көлешәләр)

**Әни:** Менә тамаша,егетләрдә килеп җиткән. И-и-и, яшь чакларым искә төшеп китте әле, балалар, шулай каз өмәсендә егетләр  килер иде,китәр иде уен-көлке, җыр-биюләр, бүләк алышулар,бүләк бирешүләр.

**Кыз:** Мин бит күрше егетләрен үзем чакырган идем. Онытмаганнар, рәхмәт, килгәннәр. (малайларга) Кызлар казларны йолкып бетерделәр инде. Кызлар,әйдәгез, казларны монда куйыйк. Казларның эчләрен тазартанчы уйнап-җырлап алыйк. (Казларны өстәлгә,урындыкларын як якка алып куялар. Малайлар, кызлар кара-каршы басалар.)

Җыр "Дүдәк-дүдәк" (т.х.к)

**Кыз:** Күчтәнәчләрем аз гына

Үрдәк белән каз гына.

**Бергә**: Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк

Басма өстендә каз-үрдәк.

**Кызлар**: Кыйгак-кыйгак

**Малайлар**: Бак-бак-бак

**Бергә**: Басма өстендә каз-үрдәк шул,

Басма өстендә каз-үрдәк.

**Малай**: Җаным кебек дусларыма

Җырлап бирим аз гына.

**Бергә**: Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк

Басма өстендә каз-үрдәк

**Кызлар**: Кыйгак-кыйгак

**Малайлар**: Бак-бак-бак

**Бергә**: Басма өстендә каз-үрдәк шул,

Басма өстендә каз-үрдәк.

**Әни**: Бигрәкләр дә матур җырлыйсыз. Сандугачлар кебек сайрыйсыз. Әллә берәр биеп тә күрсәтәсезме?

**Кыз**: Биибез, әни, биибез.

Каз өмәсе бик шәп бәйрәм,

Күңел ачаек әле.

Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр

Бергә басаек әле.

"Күмәк парлы бию"

**Кызлар**: Әйдәгез бергәләшеп уйнап алабыз

Әй әйләнә,әйләнә,

Сихерледер бу тукмак.

Нинди җәза бирер икән,

Безнең каршыда туктап.

**Малайлар**: Карап карыйк әле ,чынлап та сихерле микән? Ә бит бу уенны яшь вакытларында безнең әниләребез дә бик яратып уйнаган.
Уен: “Тукмак” (тукмак кемгә карап туктый аңа җәза бирелә).
**Әни**: Бик матур уйнадыгыз! Егетләрнең килүе әйбәт булды әле. Егетләр ярдәм итсеннәр. Әйдәгез әле,утырып каз канатларын сындырып алыгыз. Ә мин казларны карыйм. (Малайларга, кызларга каз канатлары салынган савыт бирелә, берничә төркемгә бүленеп,канат сындыралар.)
**Малайлар**: Ә нигә су буена төшкәндә каз каурыйларын юл буе сибәләр?
**Кызлар**: Бу – киләсе елда каз күп уссен , йортка тезелешеп  кайтып керсен,дигән теләк белән эшләнә.
**Әни**: Балаларым,казлар әзер,барыгыз су буена төшеп казларны чайкап менегез, каз каурыйларын су юлына чәчеп кайтыгыз.
Икенче күренеш.
(Чишмә күренеше. Кызлар казларны көянтәләргә элеп күтәрәләр. Түгәрәккә басалар. “Су буена” төшәләр. Малайларга иләк белән каз каурыйлары бирелә. Алар түбәндәге сүзләрне әйтеп, каурый сибеп баралар.)
**1 малай**: Каурыйлары,каурыйлары
Сибелсен су буена.
Казларыгыз шулай уңсын
Киләсе ел буена.
**2 малай**: Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Каурыйларын җәлләмә.
Уңсын,уңсын казлары дип,
Менә шулай сипкәлә.
**3 малай**: Алдан барсын әнкәсе,
Арттан барсын әткәсе
Пипелдәшеп йөгереп барсын
Егерме биш бәбкәсә.
**Малайлар,кызлар бергә**:Кырык булсын,
Тыкрык тулсын.
Дөньялар имин булсын.
(Килеп җиткәч, кызлар каз чайкыйлар.)
**4 малай**:Каз чайкыйлар кызлар,
Куллары эшкә ята.
Мактаудан башка бер сүз юк,

Бу кызларга карата.

**Малайлар**:Кызлар, туңгансыз да әйдәгез,”Чума үрдәк,чума каз”-уенын уйнап алабыз.

Җырлы бию:”Чума үрдәк,чума каз”

**Кыз**:Казларыбыз да чистарды,җылынып та алдык .Әйдәгез кайтабыз.

Өченче күренеш.

(Казларны алып түгәрәккә басалар.Музыка астында кайталар.Аларны әни каршы ала)

**Әни**:Кайтып та җиттегезме ,балакайларым?Бигрәк уңган балалар булдыгыз.Мин әле коймакларымны да пешереп бетермәдем.

**Кыз**:Ярар,әни,борчылма,без уйнап алабыз.

Уен:”Наза”(т.х.у)(парлашып бер-бер артлы басалар,аякларын-кулларын хәрәкәтләндерәләр,парсыз бала уенчылар каршында)

1.Наза дигән кыз баланың

Бөрлегәне түгелгән,

“Наза”дигән уенны без

Уйныйбыз чын күңелдән

Наза,Наза,(парсыз бала күпер аша чыга һәм пар сайлый)

Наза матур кыз бала.

Наза тырыш,уңган бала,

Зирәк,акыллы бала.

**Малай**:Әйдәгез,коймаклар пешкәнче”Йөзек салыш” уенын уйныйбыз.

Җәзалар:бию,табышмак әйтү,җыр.

**Кыз**:Гөрләп үтте,шаулап үтте

Авылда каз өмәсе.

Бу айларны,бу көннәрне,

Көтеп ала һәммәсе.

**Малай**:Менә шулай,каз өмәсен

Татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп,

Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Кызлар**:Изге йола,изге бәйрәм,

Ел саен кабатлансын.

**Малайлар**:Һәрбер кеше бу бәйрәмгә,

Чын күңелдән шатлансын.

Җыр: “Каз өмәсе”(Э.Шарифуллина сүзләре,З.Мөхәммәтдинов көе)

**Кызлар**:Каз канатын йомшак диләр,

Ә без шуны белмибез.

Казлар симез булсын өчен,

“Каз канаты”н биибез.

(Кызлар канат тотып бииләр)

**А.б**:Каз канатлары сибәбез,

Сез барасы юлларга.

Каз өмәсе бәйрәмнәрен,

Бергә үткәрергә язсын,

Киләсе елларга да!

**КАЗ ӨМӘСЕ**

***Хәсәнҗанова Гөлнур Юнис кызы***

*Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы*

*Буа шәһәренең "Алтынчәч" гомуми үсеш төрендәге*

*балалар бакчасы" муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»*

Беренче күренеш.

Кызлар түгәрәк булып идәндә утыралар.

(Сәхнәгә биеп Лилия керә)

Лилия: Хәерле көн! Исәнмесез, кызлар!

Кызлар: Исәнмесез!

Лилия: Кызлар! Һәр милләтнең үз исе,

Һәр халыкның үз төсе,

Шулай ук һәр милләтнең үз бәйрәме бар!

Татар халкының да бит үзенә генә хас бәйрәмнәре, бай гореф-гадәтләре, йолалары күп. Ә менә бик матур бәйрәмнәребезнең берсе- Каз өмәсе.

Сылу: Кызлар, ә нәрсә соң ул Каз өмәсе?

Нурия: Мин беләм. Миңа бу йола турында әбием сөйләгәне

бар. Күп көч, вакыт сарыф итә торган, авыр эшне ирекле рәвештә,

түләүсез, бергә-бергә башкару өмә дип атала.  Ә каз өмәсендә

кызлар үзләренең уңганлыгын, булганлыгын күрсәткәннәр. Берсен-берсе узып, әллә ничә каз йолкыганнар.
Лилия: Әйе, бик дөрес, Нурия.
Ә Каз өмәсенең иң кызыгы кич белән булган.
Аулак өйдә, эштән соң, киенеп-ясанып, кул эшләрен тотып, кызлар җыелган. Ә кызларны ишек төбендә гармуннарын асып, егетләр каршы алган. Кызлар, әйдәгез, эшебезне башлыйк.
“Каз канаты” җыры башкарыла, түгәрәккә утырып каз йолкына.
1.Каз канаты каурый- каурый
Хатлар язарга ярый.
Уйнамагач та, көлмәгәч
Бу дөнья нигә ярый.
2.Каз канаты кат-кат була
Ир канаты ат була.
Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,
Сөйгән ярың ят була.
Лилия: Бии, уйный сылу кызлар
Чыңлый чулпы-төймәсе.
Борынгыдан килгән гадәт,
Татарның каз өмәсе.
-Кызлар, әйдәгез, казларны юарга чишмәгә барыйк.
Аннары кич җитә, гармуннарын күтәреп егетләр килә.
Кызлар: Әйдәгез.
(Казларны көянтәгә асып, чишмәгә китәләр)
Кызлар, әйдәгез “Йөзек салыш” уенын уйнап алыйк әле.
Икенче күренеш.
Лилия йөзекне сала.
Лилия: Йөзек кемдә йөгереп чык!
(Йөзек кемдә, шул кыз йөгереп чыга)
Сылу: Кызлар, Нурияне нишләтәбез?
Лилия:Татар халкының милли ризыкларын әйтсен!
Нурия: Әйтәм.Тыңлагыз, кызлар:
Чәк-чәк, Гөбәдия, Вак бәлеш, Өчпочмак,

Кыстыбый, Кош теле.

Кызлар: Әфәрин, Нурия!

Булдырдың, Нурия!

Нурия йөзек сала.

Нурия: Йөзек кемдә йөгереп чык!

Сылу: Йөзек миндә!

Нурия: Кызлар, Сылуны нишләтәбез?

Лилия: Татар халкының милли бәйрәмнәрен әйтсен әле...

Сылу: Әйтәм.Тыңлагыз, кызлар:

Сабантуй, Сөмбелә, Нәүрүз, Карга боткасы, Каз өмәсе!

Кызлар: Әфәрин, Нурия!

Булдырдың, Нурия!

Кыз: Кызлар, ишек шакыйлар, кемдер бар, карап килим әле...

(пышылдап) Егетләр килгән!

Малайлар: Исәнмесез, кызлар!

Кызлар: Исәнмесез, егетләр!

Егетләр, без сезгә бер җыр җырлап күрсәтәбез,

сез безгә кушылыгыз!

Малайлар: Җырлагыз!

Җыр: Минем калфак бик матур,

Минем калфак бик матур.

Әйе шул, әйе шул

Минем калфак бик матур.

Малайлар: Минем түбәтәй матур,

Минем түбәтәй матур.

Әйе шул, әйе шул

Минем түбәтәй матур.

Кызлар: Минем күлмәк бик матур,

Минем күлмәк бик матур.

Әйе шул, әйе шул

Минем күлмәк бик матур.

Малайлар: Минем чалбар бик матур,

Минем чалбар бик матур.

Әйе шул, әйе шул

Минем чалбар бик матур.

Данир: Кызлар, әйдәгез биеп тә алыйк инде

Бергә: Әйдәгез.

Раят: Кызлар, сезнең белән бик күңелле. Әйдәгез, уеныбызны су  буенда дәвам итәбез. Мин сезгә гармунда уйныйм, бергә  биербез, җырларбыз, кыскасы- күңел ачарбыз.

Бергә: Әйдәгез.

Биеп чыгып китәләр. (Каз канаты көе)

## КАЗ ӨМӘСЕ

***Мәҗитова Резидә Илгизәр кызы***

***Салихова Энҗе Әсхәт кызы***

*Яр Чаллы МБДОУ №6 «Незабудка»*

*балалар бакчасы тәрбиячесе*

Әби чыга, сөйләнә –И – и –и , гомеркәйләр, менә тагы каз өмәләре җитте (тәрәзәдән карый). Нишләп бу кызлар һаман юк икән, кояш күтәрелеп бетте бит инде.

«Каз канаты» көенә кызлар көянтәгә чиләк асып керәләр, көянтә – чиләк белән 3-4 күнегү ясыйлар, чиләкләрен илтеп куялар.

**Әби:** Рәхмәт яугырлары килеп җиттегезме?

**1 кыз**: Бездә бүген каз өмәсе!

**«Каз өмәсе» Г.Морат шигыре.**

Атлар чаба урамнан,
Чалулый чаналары.
Җилдерәләрме белеп,
Белмичә чабалармы?
Каз өмәсе ич – бездә
Карда – каз түшкәләре.
Саклаган бәбкәләрем

Исемә төшкәләрме?

**2 кыз:** Авылларда бүген каз өмәсе

Ак мамыкка дөнья күмелгән,

Һәм әбиләр сүзсез генә җырлый

Үз яшьлеген җырын сагынган.

**3 кыз**:Бүген бездә каз өмәсе

Уз, рәхим ит, әйдә кунакка,

Өреләре чыккан каз ашларын

Табалмассың башка эзләп тә.

**Кызлар казларны алып чистартырга утыралар.**

**Әби:** (кызлар янына утыра). И – и –и, үзе кызык, үзе ямансу инде шушы каз өмәләре. Казның итеннән нинди генә ризыклар әзерләмиләр. Алай гына мени әле, татар халкының иң зур күчтәнәче кунакка барганда каз булган. Әй, казларны йолкып бетерә язгансыз бит, телемә салынып утырам икән, өстәл әзерлисем, каз коймагы пешерәсем бар бит. Чыга.

**Кызлар бер – берсенең эшен күзәтәләр:**

**1 кыз:** Алинаның казы безнекеннән чистарак булган бит, кызлар.

**2 кыз:** Әй уңган да инде безнең Алина.

**3 кыз:** Безнеке дә бик чиста булды, менә карагыз.

**Әби**: Бик зур рәхмәт, балалар.Хәзер ял итеп алыгыз әле.

**«Күңелле туп» уены оештырыла.**

Балалар түгәрәккә басалар, тупны бер – берсенә күчерәләр һәм җырлыйлар ( «Ал чия» көенә).

Күңелле туп тиз тиз әйдә,

Кулдан кулга тәгәрә.

Күңелле туп кемдә калса,

Хәзер шул биеп ала.

Соңгы сүзне әйткәндә туп кемдә кала, шул бала бии. (Уен 3 тапкыр уйнала).

**1 кыз:** Тыңлагыз әле кызлар, малайлар килә түгелме соң?

**2 кыз:** Әйе, малайлар җырлап киләләр.

**1 малай**: Кызлар, без килдек.

**Кызлар:** Ишетәбез, ишетәбез! Акча түләмичә кертмибез. Акчагыз бармы?

**Млалайлар:** Акча бездә бер кесә.(Кесәләрен күрсәтәләр)

**Әби:** Кызлар, бу малайларның бернинди дә акчалары юк. Шуңа күрә әйдәгез табышмаклар әйтик, җавапларын белсәләр, кертербез.

**1 кыз**: Соскы борын – бакылдык,

Күп сөйләшә – такылдык.(үрдәк)

**2 кыз:** Башы тарак, койрыгы урак,

Кычкыртып быргысын, уята барысын.(әтәч)

**3 кыз:** Канаты бар – очмый,

Аягы юк – йөри.(балык).

**Әби:** Бигрәк акыллы икәнсез малайлар, әйдәгез керегез.

**Малайлар:** Казларыгыз майлы булсын!

**Җыр «Такмаклар»**

1. Шыгыр – шыгыр капканы,
   Шыгырдатмый ачмагыз.
   Каз өмәсе булган җирдән
   Беребез дә калмабыз.

2. Барасызмы, барабыз
   Каз өмәсен карарбыз,
   Куып чыгармаслар әле
   Берәр эшкә ярарбыз.
3. Каз бәлеше тәмле пешә,
   Кызыл кирпеч мичләрдә,
   Әй, бигерәк күңелле,
   Шушы матур кичләрдә.

**Бию: «Күмәк татар биюе»**

**Әби:** Балакайларым, мин казларның эчләрен алып бетердем. Су буена төшеп юып кайтыгыз. (Кызлар казларны көянтәләргә элеп, чыгып китәләр)

**1 малай**: Авылларда каз өмәсе гөрли

Су буена канат сипкәннәр,

Канат очларына баса – баса

Кызлар каз юарга киткәннәр.

**2 малай:** Каз чайкыйлар безнең кызлар,
Куллары эшкә ята.
Мактаудан башка бер сүз юк,
Бу кызларга карата.

**3 малай:** Менә шулай каз өмәсен
Татарда үткәргәннәр,
Ә яшь кызлар күңел биреп,
Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**(Кызлар керәләр)**

**Әби**: Кайтып та җиттегез мени, кызлар. Кая казларыгызны алып куям. Бигрәк уңган балалар булдыгыз. Мин әле коймакларымны пешереп бетерә алмадым.

**1 кыз:** Борчылмагыз, без уйный торабыз.

**«Чума үрдәк – чума каз» уены.**

**Әби**: Бигрәк күңелле үтте бәйрәмебез, әйдәгез, балалар, коймакларым пеште, чәй эчеп алыйк.

**Малай:** Бик зур рәхмәт сезгә, апа!

**1 бала:** Бәйрәмсез бик күңелсез бит,
Бәйрәмнәр кирәк безгә.
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,
Кирәк һәммәбезгә дә.

**«Каз өмәсе» йола – уены чәй эчү белән тәмамлана.**

## КАЗ ӨМӘСЕ

**Рәхимова Миләүшә Рәфкать кызы**
*Байлар Сабасының 6 нчы номерлы*
*«Балачак» балалар бакчасы*

Көзге кышкы күмәк йолалар һәм бәйрәмнәр арасында *өмә* аерым бер урын тота. Безнең борынгы әби-бабайлар казны бик яратканнар. Беренчедән,аның мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясаганнар. Билгеле булганча, мендәр өеменнән башка татар йортын күз алдына китереп тә булмый. Икенчедән, каз итеннән аш-су өчен бик әйбәтләп файдалана

белгәннәр, шулпасын да яратып ашаганнар. Күп төрле каз ашлары турында әйтәсе дә түгел; каз бәлеше, каз коймагы, каз тәбикмәге, каклаган каз... Каз маен хәтта дәвалау өчен саклаганнар: кышкы суыкларда бит ,колак очлары өшесә, каз мае сөрткәннәр.

Инде борынгыдан калган йолаларга килсәк, анда каз билгеле бер урын алып торган. Улы яки кызының үз тормышын корыр вакыты җитсә, ана кеше берничә казын туйга дип саклап тоткан. Чөнки пар каз-ул туйның хөрмәтле кучтәнәче. Матур табакка салып казны туй мәҗелесенең түренә чыгарганнар.

Каз күтәреп килгән "кучтәнәчле кунак" башка вакытта да, гадәттә, аерым хөрмәткә лаек саналган.

Яшьләр өмәгә бик теләп барган, авыр эшләрне дә бәйрәм кебек итеп башкарып чыга белгән. Йолкыган казларны көянтәгә асып кызлар чишмәгә, су буена юл тотканнар. Анда барып казларны салкын чишмә суында чайкый-чайкый юганнар. Чишмәгә бару-үзе бер йола белән бәйле. Кызлар, гадәттә, гармуннарын алып,егетләр иярә торган булган. Монда да җыр, такмак әйтү, чишмә буенда биюләр башкарылган.

Казларны юып кайтуга хуҗабикә каз маенда бик әйбәтләп коймак, я тәбикмәк пешереп, чәй әзерләп көтеп тора. Ә аш-бәлешләр кич белән була. Кичке мәҗелес тәмамлануга, шул йортта төрле уеннар оештырылган.

**"КӨТҮ ЧЫГАРУ" ЙОЛАСЫ**

**Гимранова Рүзия Габделәхәт кызы**

*Казан шәһәре Совет районының*

*"166 нчы балалар бакчасы"нын татар теле тәрбиячесе.*

Һәрбер кеше үз халкының үткәнен,әби-бабаларының ничек көн күргәнен,гореф-гадәтләрен,йолаларын белергә тиеш.Юкка гына "Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк"димәгәндер халык.Бәйрәмнәр һәм йолалар халыкның олысын-кечесен бергә җыя,шулай итеп үзара дуслык,кешелеклелек,бердәмлек сыйфатларын тәрбияли,туганлык җепләрен ныгыта.

Гасырдан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайларыбыз үзләренең гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен яшь буынга тапшыра килгән. Вакыт узу белән, алар күпмедер дәрәҗәдә үзгәртелгән, югалып бетә язган, кайберләре безнең көннәргә дә килеп җитә алган.

Татарстанның төньяк районнарының берсе булган Әтнә районында Ары авылы бар.Ул Мари иле республикасы белән чиктәш булган кечкенә генә татар авылы. Авыл кечкенә булуга карамастан,анда бик тә тырыш, үз халкының традицияләрен, бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен саклап яшәүче кешеләр яши. Район буенча Ары авылында гына "Көтү чыгару"йоласы сакланып калган. Аны май аенда көтүлекне болынга озатканда үткәрәләр. Көтү чыгасы көнне һәр йортның капкасы зур итеп ачып куела һәм капканың эчке ягына табагач тераәп куела. Бу, терлекләр йортларын онытмыйча әйләнеп кайтсын өчен эшләнелә. Көтү чыгар алдыннан сыернын мөгезләрен төрле төстәге тасмалар яисә тукыма кисәкләре белән бизиләр. Капкадан чыгарып җибәргәндә, сыерга телеме белән ипи каптыралар яисә он ялаталар һәм "исэн-сау йорсә иде, үзебезгә насыйп маллар булса иде" дигән изге теләкләр теләп калалар. Маллар көтүгә киткәч бәйрәм дәвам итә, күрше-күләнгә кукәй кертәләр,бала-чагага кәнфит өләшәләр. Бу йола барлык авыл халкын берләштерә, күршеләр белән татулык урнаштыра, яшь буында үз халкының йола-бәйрәмнәренә карата кызыксыну һәм мәхәббәт уята.

## ТАУ АСТЫНДА


***Хөснетдиновна Дамира Тәлгат кызы***
***Кәримуллина Венера Равкат кызы***

*Казан шәһәре 166 нчы балалар бакчасы*


*Зал тауга охшатып бизәлә. Бер почмакта-су буе, чишмә, татар һәм рус халык бизәкләре төшкән көянтә-чиләкләр, стенада-чигүле сөлге, алъяпкыч, калфак, кулъяулыклар һәм башка әйберләр. Залның түрендә (тау итәгендә) –агач төпләре, яшел келәм җәелгән. Залның бер ягыннан татар халык көенә милли киемнәрдән әби һәм балалар чыга.*

**ӘБИ:** Әйдәгез, балалар, тау итәгенә, уйнап, биеп, җырлап, рәхәтләнеп күңел ачарга. Бу таудан ерак түгел күл бар. Ә ул күлдә Су анасы яши. Шул күлдә безнең бөтен балачак үтте. Сезнең эти-әниләрегез дә кичләрен җыелып, күңел ача, уйный-җырлый торган иде.

Биек тауның башларында
Шаулап үсә пар каен.
Шул каеннар янына

Күңел тарта яз саен.

Әнә шул каеннар арасында безнең балачак, яшь чак үтте, сезнең әти-әниләрегез дә кичләрен алар янына җыела иде. Бу каеннар инде күпме моң, көй, зар ишетте. Ике авыл уртасында булганга күрә, монда күрше авыл яшьләре дә килә иде. Әнә бүген дә киләләр түгелме?

*Рус халык көенә, милли киемнәрдән, оныклары белән сөйләшә-сөйләшә, Матрена әби керә. Очрашып сөйләшкәндә һәр әби үз телендә сөйләшә, ләкин бер –берсен аңлыйлар.*

**МАТРЕНА:** Здравствуйте, соседи!

**ӘБИ:** Исәнмесез, күршеләр! Ничек хәлләрегез?

**МАТРЕНА:** Живы здоровы! А вы как поживаете?

**ӘБИ:** Аллага шөкер, яхшы. Исән-сау гына торабыз. Эй Мәтрүнә, тау итәгендә уйнап, җырлап йөргән чакларны хәтерлисеңме син?

**МАТРЕНА:** Дааа, были времена. Играли, пели, плясали. Вот было веселье. А сейчас что? Дети в телефонах, родители в телефонах на компьютерах.
О скукота!

**ӘБИ:** Әйтмә дә инде Мәтрүнә җаным, бездә дә нәкъ шул хәл. Әйдә әле Мәтрүнә онукларыбызны табигатьтә үзебез яшь чакта уйнаган уеннарны, җыр-биюләрне өйрәтик әле үзләренә.

**МАТРЕНА:** Да Хадича, отличная идея. Сама хотела вспомнить молодость.

**ӘБИ:** Әйдәгез әле, оныкларым, күңел ачыйк.

**БАЛА:** Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел.

**ӘБИ:** Әйдәгез әле, бер бергәләшеп җырлап алыйк.

Җыр “Кояшлы ил –безнең ил” *(берәр куплеты) татарча һәм русча башкарыла*

Кояшлы ил – безнең ил,
Күге аның гел аяз.
Кыш китерсә кыш бабай,
Чәчәк алып килә яз.
Щедро солнце край родной
Озаряет и зимой.
А когда весна придёт-
Белым садом он цветёт.

**ӘБИ:** Хәзер, балакайларым, әйлән – бәйлән уйнап алыйк әле.

*Балалар “АК КАЕН” җырын башкаралар, салмак бию хәрәкәтләре ясыйлар(Зыя Ярмәки сүз. Мөслим Вәлиев көе)*

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәр көн тау ягы.

Яшь балалар, бигрәк матур кызлар
Ак каенны сөеп мактыйлар.
Яз башында алар һәр ел саен
Ак каенда бәйрәм ясыйлар.

Ап-ак каен — инде бик карт каен,
Бизәлә ул язлар килгәндә.
Яшел яфрак яра һәр ел саен,
Кояш җылы нурлар сипкәндә.

**ӘБИ:** Бик күңелле уйнадыгыз, балалар! Инде бераз ял итик, башкаларны да тыңлап карыйк.

**БАЛА:** Мин бер шигырь өйрәндем, сөйлимме, әбием?

**ӘБИ:** Әйдә, балам, сөйлә.

**БАЛА:** Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле затлы тел.
Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
һәм онытма үз телең!

**ӘБИ:** Бик тә дөрес, балам. Үз телеңне белү һәркемгә дә кирәк, чөнки ул - ана теле. Ә дуслар белән аралашу өчен дуслар телен өйрәнү кирәк. Безнең балалар русча да яхшы белә. Кара әле, Матрена ахирәт, синең оныкларың да узең кебек татарча аңлыйлармы соң?

**МАТРЕНА:** Да, они и в садике изучают татарский язык, и я немного практикуюсь с ними. Стыдно не знать языка своих соседей. Некоторые мои внуки уже неплохо разговаривают. Ну-ка, сыночек (доченька), расскажи нам что-нибудь.

**РЕБЕНОК:** Безне бик яраталар

Бакчадагы апалар.

Килгәч тә елмаеп,

Кулларын киң җәеп,

Кочаклап алалар –

Әниләр күк алар.

**ӘБИ:** Ай, афәрин, балам, бик яхшы сөйләдең.

**ӘБИ:** Матрена ахирәт, сезнең авылда рус халкы яши бит инде, бик дус яшәдек Аллага Шөкер. Сезнеңдә киемнәрегез матур, җыр-биюләрегез дә күңелле. Яшь чакта "В саду ли, в огороде…» дип жырлый торган идегез.

**МАТРЕНА**: Да, да Хадича.Русский народ всегда любил песню. И грустную, и весёлую. Она сопровождала людей во время труда и праздников. Мои внуки умеют играть на ложках. Они ходят в ансамбль народной песни. Сыграем на ложках!

*Кашыкларда уйнау (Кашыкларда уйнап бетергәч кинәт Су анасы килеп чыга. Барысы да аптырый, куркышалар, балалар әбиләре янына елыша)*

**ӘБИ:** Туктагыз әле, балалар, курыкмагыз. Гомер буе шушы тау итәгендә уйнап үстек, Су анасының безгә бернинди дә зыян китергәне булмады.

**СУ АНАСЫ:** Юк, юк! Мин сезгә һич тә начарлык эшләмим. Читтән генә күзәтеп тордым, сез бик акыллы балалар икәнсез. Табигатьне дә пычратмадыгыз, бик күңелле уеннар да уйнадыгыз, матур җырлар да җырладыгыз. Рәхмәт сезгә! Куркыткан булсам, гафу итегез инде. Соңгы елларда мондый матур көйләр дә ишетелмәде. Сезнең кебек матур балаларны күрергә, моңлы көйләрне ишетергә язган икән әле. Бөтенләй өмет өзгән идем инде...

**Әби**. Әйе, әле дөньялар бераз чуалып торды шул, халык үз телен, моңын онытa язды. Хәзер балаларыбыз кабат без уйнаган уеннарны уйный, без җырлаган җырларны җырлый. Табигатьне дә бик яраталар, тау астындагы чишмәне дә чистарттылар. *(Чишмә аккан тавыш ишетелә.)*

Чиста, тәмле чишмә суын эчсәң, суы белән битләреңне юсаң, күңелең саф, яхшы булыр. Үзеңнең дә гел яхшылыклар, изгелекләр генә эшләсең килеп торыр. Дус, тату яшик, балакайларым! Ә бу матур калфак сиңа бездән бүләк булыр Су анасы.*(Калфак бүләк итәләр)*

**СУ АНАСЫ:** Ай рәхмәт Сезгә **.**Бик яхшы, изге эш эшләгәнсез. Сезнең белән күңелле. Тагын бер биегәнегезне якыннанрак карыйм әле.

*Рус биюе*

**СУ АНАСЫ:** Рәхмәт, балакайларым, хәтирәләрне яңартканыгыз өчен. Сау булыгыз. *(Китә)*

**ӘБИ:** Без бүген бик күңелле уйнадык, җырладык, биедек. Яшь чакларга әйләнеп кайткан күк булдык, шулай бит Матрена ахирәт?

**МАТРЕНА**: Да, да Хадича. Спасибо вам дети! Вы очень счастливые дети. Будьте здоровы, почитайте своих родителей.

**ӘБИ:** Вакыт соң инде, әйдәгез барыбыз бергә тагын бер жыр жырлыйк та бүгенгә таралышырбыз. Балалар авылдан киткәнче ,кич саен очрашырбыз шушы тау итәгендә, яме, ахирәт. Бәлки үзебез дә яшәреп китәрбез бераз.

*(Кичә ахырында "**Матур булсын" дигән жыр** (берәр куплеты) татарча һәм русча башкарыла*

*(Жыр беткәч, залдан чыгалар)*

## "МИЧ КОТЛАУ" ЙОЛАСЫ

***Гатауллина Гөлназ Госман кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының*

*«Гомуми үсеш бирүче төрдәге Кариле балалар бакчасы»*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Алдан үткәрелгән эш:** мичне ничек чыгаруларын аңлату, мичче һөнәре белән таныштыру.

*Балалар татар көенә биеп керәләр.*

**Дилия:** Туктагыз әле, кая барабыз соң без?

**Сәйдәш:** Мич күрергә барабыз.

**Рияз:** Авылларда бер йортта да мич калмаган ди. Ә менә Рияннар гаиләсендә иске мич урынына яңасын салып куйганнар ди. Әйдәгез шунда мич котларга барабыз.

**Нәфисә**: Ә шулаймени, әйдәгез, бергәләп барабыз.

*Бию көенә бергәләп мичне әйләнеп чыгалар.Әни кеше балаларны каршы ала.*

**Балалар:** Әссәләмәгаләйкем!

**Әни:** Вәгаләйкемәссәлам.Рәхим итегез балалар.

**Рияз**: Без мич карарга килдек.

*Мичне тотып карап әйләнеп чыгалар.*

**Нәфисә:** Мичегез котлы булсын.

**Дилия:** Бәрәкәтле мич булсын.

**Сәйдәш:** Таңнар атып кич булсын.

**Рияз:** Туганлыклар нык булсын

**Барысы бергә:** Дошманнарыгыз юк булсын.

**Әни:** Матур теләкләрегез өчен бик зур рәхмәт, балалар. Амин, шулай булсын. Әйе шул, менә яңа мич  чыгардык. Шуны котлап  мичкә икмәк тә салдым, тәмле коймак та куйдым.

**Рияз:** Мичтә пешкән коймакларның тәмлелеге!

**Дилия:** Ә икмәге..... Телеңне йотарлык.

**Әни:** Әйе шул, мичтә пешкән ризыклар тәмле дә, файдалы да.  Балалар, минем улым Риян кая соң? Сез күрмәдегезме?

**Балалар**: Юк.

**Әни**: Риян, улым, кая соң син?

*Мич артыннан битлек кигән Риян йөгереп чыга.Балалар куркып йөгерә башлыйлар. Боларга ияреп әниләре дә йөгерә.Әниләре балаларны туктата.*

**Әни**: Балалар курыкмагыз бу бит мич иясе.

**Балалар**: Мич иясе? Кем соң ул? Шундый куркынычмы?

**Әни**: Алай ук куркыныч түгел бит. Элек-электән өйләрдә йорт  ияләре булган дип сөйлиләр. Алар мич артында яшәгәннәр һәм өйне саклаганнар. Шуна аларны йорт  яки мич иясе дип йөрткәннәр. Алар балалар белән уйнарга яратканнар. Ягез, балалар,  мич иясен нишләтәбез?

**Балалар:** Биетәбез.

**Әни:** Ярар, әйдәгез биетик. Ләкин гади генә түгел, табага бастырып биетәбез.

*Әни тиз генә таба алып чыгып куя. Мич иясе менеп басып бии башлый.Көй туктагач, битлеген салып ата. Риян килеп чыга. Барысы да көлешәләр.*

**Әни:** Бу бит минем улым Риян булган. Ул безнең белән шулай шаярткан.

*Кулына кәрзин тулы тукмаклар тотып ишектән әти килеп керә.*

**Әти:**  Әссәләмәгаләйкем! Кунаклар бар икән.

**Балалар**: Вәгаләйкемәссәлам.

**Әни**: Менә әтисе балалар  яңа мичне котларга килгәннәр.

**Әти**: Бик әйбәт, рәхмәт. Мичне күрдегезме? Ошадымы сезгә?

**Балалар:** Әйе, ошады.

**Әти:** Күңел җылысын биреп эшләгән һәр әйбер матур һәм җылы  була шул.

*Әти барып утыра, тукмакларны тукылдатып ала.*

**Әти:** Тук-тук тукран

Тукылдатып утырам.

Мичтә икмәк пешәме
Шуны көтеп утырам.

**Дилия:** Әмин тизәйткеч беләм, тыңлап карагыз әле.

Мич башында биш мәче
Биш мәченең биш башы
Биш мәченең биш башына
Ишелмәсен мич ташы.

**Риян:** Мин дә беләм.

Мич авызында капкач,
Җылысы чыкмый япкач.
Бик күңелле уйнавы
Дусларым җыелышкач.

**Әти**: Менә әниегез бәрәңге төяргә тукмак ясарга кушкан иде. *( кәрзиненнән алып күрсәтә)* Ясый башлагач, кызып киттем ахыры, күп итеп ясаганмын. Ләкин шомартырга өлгермәдем.Әйдәгез, бергәләп, икмәк пешкәнче шул тукмакларны шомартып алыйк әле *(тезелешеп утыралар)* Кая әле, әнкәсе балаларның киемнәре пычранмасын, алларына япкычлар өләшеп чык әле.

**Әни:** Кызлар, сез минем яныма килегез. Камыр белән маташып, мин дә йомгакларымны урап бетерергә житешмәдем. Миңа йомгак урарга булышыгыз әле. *(“Күрсәт әле, үскәнем” көенә җырлый-җырлый, бергәләшеп утырып, кул эшләренә тотыналар).*

**Кызлар:** Күрсәтегез малайлар, ничек тукмак ясыйлар,
Күрсәтегез малайлар, ничек тукмак ясыйлар.

**Малайлар:** Менә шулай, менә шулай, шулай тукмак ясыйлар,
Менә шулай, менә шулай, шулай тукмак ясыйлар.

**Малайлар**: Күрсәтегез кызлар, ничек йомгак урыйлар,
Күрсәтегез кызлар, ничек йомгак урыйлар,

**Кызлар**: Менә шулай, менә шулай, шулай йомгак ясыйлар,
Менә шулай, менә шулай, шулай йомгак ясыйлар,

**Бергәләп:** Андый матур тукмакны бездә ясый малайлар.
Андый тигез йомгакны бездә урыйлар, кызлар.

**Әни:** Булдырдыгыз, кызлар, рәхмәт. Бигрәк тигез йомгаклар булган.

**Әти:** Кая әле малайлар миңа тукмакларны алып килеп күрсәтегез әле. Менә монысы бигрәк шома булган. Мә әле, улым икмәк пешкәнче дусларыңа “Тукмаклы” уены уйната тор әле.

**Риян:** Игътибар белән тыңлагыз

“Тукмаклы” уйныйбыз.

Җәза кемгә икәнлеген

Тукмактан сайлатабыз.

*“Тукмаклы” уены берничә мәртәбә уйнала. Тукмак кемдә туктый, шул кешегә җәза бирелә.*

**Әни:** Тәмле исләре дә чыкты. Икмәк тә, коймаклар да пеште бугай. *(Мич янына барып, коймакны ала).*

**Әни:** Мә әле Риян, улым яңа мичтә пешкән коймакларны күршеләргә дә кертеп чык әле. Юкка гына борынгылар: “Күрше хакы- Алла хакы” димәгәннәрдер. Күршеләр белән һәрвакыт дус булырга кирәк. Хәл-әхвәл белешү бик саваплы гамәл дә санала шул әле, балакаем. Балалар, ә сезнең белән алгы якка чыгып, мичтә кабарып пешкән икмәк һәм коймаклар белән чәй эчәбез. *( Әни мичтән икмәк ала).*

**Әти:** Бөртекләп вә берәмтекләп

Җәүһәрләрне барлар чак җиткән.

Гореф-гадәт , һөнәр югалмаган,

Купме еллар, гасырлар үткән.

**Әни**: Илләребез имин булсын,

Тыныч булсын тормышлар.

Бу мирасны дәвам итәр

Уңганнар һәм тырышлар.

## *СЕРЛЕ КИТАП*

*(милли бәйрәм)*

**Әхмәтшина Флера Солтан кызы**

“*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*

*“Рябинушка” Красносельский балалар бакчасы”*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениясе”,*

*татар теленә өйрәтү тәрбиячесе*

Сәхнәдә йон эрләп әби утыра….

Телефон шалтырый,әби сөйләшә:

**ТӘРБИЯЧЕ:** Исәнмесез әби.

**ӘБИ:** Исәнмесез,исәнмесез.

**ТӘРБИЯЧЕ:** Сезнең хәлләр ничек?

**ӘБИ:** Әйбәт, рәхмәт. Сезнең хәлләр ничек?

**БАЛАЛАР:** Исәнме әби!
Хәлләр әйбәт, рәхмәт.
Сәләм ,әби.

**ӘБИ:** Кунакка кайтыгыз балалар. Мин көтеп калам.

**БАЛАЛАР:** Кайтабыз , кайтабыз!Көт безне.

Автобуста барган кебек "Автобус" җырын җырлап балалар керәләр.

**БАЛАЛАР:** Автобуска Утырдык
Сәяхәткә Җыендык
Безгә Яшел Ут Яна
Алга Барырга Куша.

**ТӘРБИЯЧЕ:** Хәзер Нинди Ут Яна?

**БАЛАЛАР:** Сары .

**БАЛАЛАР:** Барабыз Урман Аша
Безгә Кояш Елмая
Сабыр итәргә Куша

**ТӘРБИЯЧЕ:**Хәзер Нинди Ут Яна?

**БАЛАЛАР:** Кызыл .

**БАЛАЛАР:**Арыдык без барып
Безгэ Кызыл Ут Яна
Туктап торырга куша

Автобус туктый, балалар автобустан төшеп, әби өе янына киләләр.Әби балаларны каршы ала, сәләмли һәм өенә чакыра. Алар барысы бергә өйгә керәләр.

**ӘБИ:** Балаларым минем исәнмесез .Мин сезне сагынып көттем.Мин сезне күрүемә бик шат.Юлда арыгансыздыр , әйдәгез керегез өйгә ,түргә узыгыз.Мин сезне тәмле чәй белән сыйлармын.

Чәй эчәбез бал белән ,
Бала –чагалар белән.

Балалар чәй табынына утырып сыйланалар.

**Жыр «Без әзерлибез табын….»**

**ӘБИ:**Балалар сезгә минем күчтәнәчләрем ошадыма**?**

**БАЛАЛАР:**Рәхмәт Әби.Әйе кыймак тәмле.Бәлеш тәмле.Чәк-чәк тәмле.

**ӘБИ:**Балалар сыйландык ,ял иттек , ә хәзер мин ял итеп алам, ә сез миңа шәһәрдә үзегезнен уйнаган уеннарыгызны уйнап күрсәтерсез әле.

**Рус халык уены «СОЛНЫШКО-ВЁДРЫШКО»**

**ӘБИ:** Ай – ай матур уен ,булдырдыгыз.Без дә яшь вакытта бик күп күңелле уеннар уйный идек. Сезне дә өйрәтимме?

Дети:Әйдә ,әйдә әби бик рәхәтләнеп.

**ӘБИ:** Ярар, әйдэгез, балалар, парлашып басыгыз

**ЖЫРЛЫ УЕН «ЧУМА УРДЭК, ЧУМА КАЗ» (ТАТАР ХАЛЫК УЕНЫ)**

**ТАТАР КӨЕ УЙНЫЙ.**

Бер бала сандык күреп ала.

**БАЛА:** Әби, Әби, бу нәрсә? …. (башка балалар да аптырап сорыйлар)

**ӘБИ:** Бу бик борынгы һәм тылсымлы сандык.Бу сандыкта минем әбием үзенең киемнәрен саклаган.

**БАЛАЛАР:**Ә хәзер нәрсә бар анда?

**ӘБИ:** Ә хәзер бу сандык төпләрендә борынгы , тылсымлы , серле китап саклана. Бу китап бик серле китап.Ул үзенең битләрен акыллы, тәртипле , итәгатьле балаларга гына ача.

(әби сандыкны ачып күрсәтә, балалар аптырап шаккатып карыйлар.)Мин сезгә бу китапны бераздан укып алырмын.Ә хәзер мин кәҗәмне савып керәсем бар.Сез ял итеп торыгыз,китапны миннән башка ачмагыз.

(Балалар нәни медәрләрен алып идәнгә яталар.Ә әби балалар арасында йөреп, аларга башларыннан сыйпап, салмак кына бишек җырын җырлый.Балалар йокыга тала) .

**"ӘЛЛИ-БӘЛЛИ-БӘҮ " көе.**

Әби чыгып китә.Салмак кына көй уйный.Зур китап үзенең тылсымлы битләрен ача. Беренче биттә "Шүрәле" әкияте.

**ИНСЦЕНИРОВКА «Шүрәле»**

Салмак кына серле көй уйный һәм китап үзенең икенче битен ача.Ә анда "Бүре һәм җиде кәҗә бәтие" әкияте.

**ИНСЦЕНИРОВКА «Бүре һәм җиде кәҗә бәтие»**

Салмак кына көй уйный.Серле китапның өченче бите ачыла.Матур бизәлешләре бн «Бүләк кемгә?» әкияте күренеше.

**ИНСЦЕНИРОВКА «БҮЛӘК КЕМГӘ»ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕ**

Күренеш ахырында , кояш йолдызлар эләшкән вакытта балалар түгәрәккә басалар.

**Түгәрәк уен «КӘРИЯ-ЗӘКӘРИЯ»**

Уеннан соң балалар үз урыннарына мендәрләренә яталар.Музыка яңгырый.Әби яңа савылган сөт белән килеп керә.

**ӘБИ:** Балакайларым, торыгыз, уяныгыз. Мин сезне хәзер тәмле сөт белән сыйлыйм. Балалар сөт тәмле, файдалы , сыйланыгыз!

(Балалар уянып, өстәл әйләнәсенә килеп сөт эчәләр).

**БАЛАЛАР:** Әби сөт тәмле ,

Әби рәхмәт,бик тәмле.

Әби кинәт китап ачылганын күреп ала һәм аптырап кала.

**ӘБИ:**Абау ,китап үзенең битләрен ачкан... Димәк сез минем бик итәгатьле,сөйкемле , ягымлы ,дус, тату балалар . ( Әби белән балалар кочаклашалар.

**Жырлы – биюле уен «ДУСТЫМ БАР».**

## "БӘЛЕШ ПЕШЕРҮ" ЙОЛАСЫ

***Абдрахманова Гөлия Ришат кызы***

***Миннебаева Зөлфия Әсхәт кызы***

*"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*

*Биектау "Шаян" катнаш төрдәге балалар бакчасы"*

*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе*

Бөек татар халкын, бай тархихын,
Гасырлардан килгән мирасын,
Калдырасы иде яшь буынга,
Һәрбер кеше барлап сокланслын!
Гореф- гадәтләрне, жыр- биюне,
Сабан туен, Жыен, Нәүрүзен,
Белсен иде жирдә һәрбер бала
Әнисеннән алган үз телен!

Әти-әнием топ чыгышлары белән Биектау районы Сая авылыннан минем, шунлыктан балачак хәтирәләрем дәү әти белән дәү әнием белән бәйле. Нинди бәхетле, борчу мәшәкатьсез чор. Бер авылда ике дәү әти, ике дәү әни. барысы да сине ярата. Авыр елларда яшәп,

күбесенчә выкытны эш, хезмәткә биреп, үз балаларына тиешле рәвештә бирә алмаган наз һәм мәхәбәтне үз оныкларына бирә. Кышкы каникулга кайткан бер мизел гел истән чыкмый минем.

Урамда суык кыш иртәсе, күрше апалары безнең йортта, аш-су бүлмәсендә җыелышып гөр киләләр. Баксаң күп итеп бәлеш, тәм- томнар пешерергә ниятләгәннәр икән. Кирәкле савыт-сабаны, онлы чиләкләрне дәү әнием Кәүсәрия кичтән үк әзерләп куйган. Барысы да чиста, пөхтә.

Сул якта яшәүче  күрше Сания апа кечкенә генә, күркәм мәҗлесне "Фатиха" сүрәсе белән башлап җибәрде. Элек-электән  әби-бабайларыбыз диннәрен онытмаганнар, мөмкин булганча фарызларын үтәп, изге гамәлләр белән яши килгәннәр.

Барысы да эшкә кереште. Пич тирәсендә җыелган апаларның өс киемнәре дә бик чиста, пөхтә. Барысы да озын җиңле матур күлмәк, алъяпкыч кигәннәр, башларында яулык. Камыр басып, бәлеш эчлекләрен әзерләүгә керештеләр. Эш эшләгән арада бер- берсенең хәлен, яңалыкларны  белештеләр. Әй гөрләшәләр дә үзләре.Сокланып карап туймаслык күренеш. Араларында җитезрәк булган Сөембикә апа матур итеп җыр җырлап җибәрә:

Каз канаты кат-кат була,<br>
Ир канаты ат була;<br>
Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,<br>
Сөйгән ярың ят була.<br>
Каз канаты каурый-каурый,<br>
Хатлар язарга ярый.<br>
Уйнамагач та көлмәгәч,<br>
Бу дөнья нигә ярый.<br>
Каз канаты ап-ак була,<br>
Ир канаты ат була;<br>
Чит илләрдә йөргән чакта<br>
Бик сагынган чак була.

Җырның эчендә күпме мәгънә, сагыш, тирән яралар, хатирәләр. Олыгаеп, гаилә коргач кына аңлыйбыз, кеше хәленә керә беләбез. Әби-бабайларыбыз хәйран гына сынаулар, сугышлар, югалтулар күргән. Сынмаган, сыгылмаган, матур итеп динен, милләтен саклап яши килгән.

Күрше аплары өйләреннән  бәлеш өчен алып килгән төрле эчлекләрнең рецептлары белән бүлештеләр үз ара. Кемдер көздән алма повидласы ясаган, кемдер творог эчлеге алып килгән. Үзара киңәшләшеп  хәйран гына эшләгәннән соң, бәлешләр олы, авыл пиченә

салынды. Күрше апалары җылы пич янына утырышып, матур гына әңгәмә кордылар. Әлбәттә һәрберсенең күңелендә үз борчу, мәшәкатләр дә булгандыр, ләкин барысында читкә куя белеп, үзара дус мөнәсәбәттә булганнар. Авыл апалары гадилекләре, юмартлыклары, киңкүңелле, ачык йөзле булулары белән истә калган.

Соңрак самовар артында матур итеп, пешкән тәмле бәлешләр белән чәй эчүләр хәтердә. Дәү әни килгән күршеләренә пешергән бәлештән өлеш чыгарып, күршеләрен матур теләкләр белән озатты.

Озак та үтми дәү әни белән бер урамыбызда яшәүче Мөнәвәрә апа янына барып килү дә истә. Бу әби байтак кына авырып, өеннән дә чыкмаслык дәрәҗәдә иде. Безнең килүебезгә бик шатланды күрше апасы. Дәү әни алып килгән бәлешләргә дә бик сөенде. Хәйран гына сөйләшеп утырганан соң, рәхмәтләр укып, озатып калды безне.

Авылыбызның шундый матур бәлеш пешерү йоласы якты, балачак хатирәсе булып минем күңелемдә бүгенге көнгә хәтле уелып калган. Әйе, алар иң якты хатирәләр. Бер кечкенә генә очрашуда күпме күңел җылысы, тәрбия үрнәге.

## ҖОМГА КӨН

***Гарифҗанова Лилия Рәшит кызы***

***Ганиева Люция Альберт кызы***

*Казан шәһәре Совет районының*

*“166 нчы катнаш төрдәге билингваль балалар бакчасы*”

Соңгы елларда халкыбыз тарихын, ата-бабаларның тормышын, аларның шөгылен өйрәнү теләге нык артты. Чөнки элек-электән белем һәм тәрбия эшендә шәхестә кешелек сыйфатларын булдыру-төп бурычларның берсе булган. Ул халык педагогикасының нигезен тәшкил итә. “Балалар -безнең киләчәгебез” дип әйтергә яратабыз. Гаиләнең генә түгел, илебезнең дә киләчәге балаларның бүгенге тәрбиясе белән тыгыз бәйләнгән бит.

Казан шәһәренең Совет районы буенча балалар бакчаларында күп еллардан бирле тәрбиячеләр өчен ”Мирас” дигән семинарлар эшләп килә. Семинарларга тәрбиячеләр бик

теләп йөриләр һәм үзләре дә катнашалар. Шуның нәтиҗәсендә эшләрендә ярдәм итә алырлык эш тәҗрибәсен дә туплыйлар.

Быел без үзебезнең балалар бакчасында да ”Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре үрнәгендә милли мәдәни рухта тәрбияләү” дигән темага “Мирас” семинары үткәрелде. Семинар барышында күп балалы Салаховлар гаиләсе “Җомга бәйрәме” дигән күренеш белән чыгыш ясадылар. “Оясында ни күрсә, очканда шул булыр” ди халык мәкале. Әти-әни балага иң беренче үрнәк.Аларның әйткән сүзе, ягымлы һәм таләпчән мөнәсәбәте тәрбиянең нигезен тәшкил итә. Ягъни, балада тәрбияләнергә тиешле сыйфатларда беренче чиратта әти-әниләр ия булырга тиеш, чөнки бала шуларны күреп үсә, тәрбияләнә.Безнең кайсыбыз гына балаларын тәрбияле,әдәпле итеп күрергә теләми икән?

*Татар ризыклары, самовар, чынаяклар өстәл куелган. Әни балалар белән чыга.*

**ӘНИ:** Әйдәгез әле, сабыйларым, табын түренә рәхим итегез.*(Өстәл артына утыралар).* Балалар, бүген безнең җомга көне. Җомга көне белән барыгызны да!

**Камилә:** Җомга-элек-электән ислам динендә бәйрәм көне буларак саналган. Шулай бит әнием?

**ӘНИ:** Әйе, кызым, бу көнне тәмле таба ашлары пешереп мул табыннар әзерләгәннәр. Изге җомга көнендә укыган догалар кабул була, ярдәмгә мохтаҗларга булышып зур саваплар эшлиләр, балалар.

**САБИНА:** Бүген бәйрәм-җомга көн
Күңел күтәрелгән көн...
Онытылган гореф-гадәтләрне
Яңартырбыз көннән көн.

**ӘНИ:** Әфәрин , кызым. Мин дә, балалар, бүген сез йокыгыздан тырышка тәмле ризыклар әзерләдем. Татарларның халык ашлары бик күп.Балаларым, залда кунаклар күп, алар татар халык ашларын беләләрме икән. Хәзер карыйбыз.

Мәликә, кызым, безнең матур серле капчыгыбызны алып кил әле.

Менә монда табышмаклар, табышмакны тартып чыгарасыз, укыйсыз, җавабын өстәлдә табасыз. Кызым, кунакларыбызга уен уйнарга булышып курайда матур көйләреңне уйнарсың. *(Кунаклар капчыктан табышмакларны алып җавапларын өстәлдән алып күрсәтәләр, һәм ӘНИ җомга күчтәнәче итеп бирә.)*

**Табышмаклар:**

Өсте такта, асты такта,
Уртасында майлы турта. *(Якмыш ,Кыстыбый,Күзикмәк)*

Минем ялгызымны ашамыйлар,
Әмма миннән башка татарга аш булмый.*(Токмач)*
Сары куйлар суга батты,
Шешенде дә өскә калыкты.*( Бавырсак)*
Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар *(Өчпочмак)*
Иттән генә торам мин
Майга чумып чыгам мин. *(Пәрәмәч)*
Вак-вак кына итеп кисеп
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай. *(Чәк-чәк)*
Чың итеп саласың
Бик тиз генә аласың,
Балга манып кабасың,
Ул нәрсә? *(Коймак)*

**ӘНИ:**Рәхмәт. Татар халык ашларын бик яхшы беләсез. Сезгә безнең гаиләдән кечкенә генә күчтәнәч. (*Кунакларга Кыстыбый рецепты. тараталар)*

**ӘНИ:** Балалар, әйдәгез, дәү әни белән Дәү әтиләрегезне дә җомга көне белән котлап күчтәнәчләр илтеп кайтыйк. Улым, Ильяс, юлга чыгар алдыннан әйдә бер дога укып ал әле. *(Ильяс дога укый, аңа калганнар кушыла) (Дога укыгач күчтәнәч тутырылган кәрзинне алып чыгып китәләр)*Әйдәгез, балалар Аллага тапшырдык, хәерле юллар насыйп булсын!

**Алып баручы:** Җомга көн ул зур бәйрәм көн.
Бар көннәрнең изгесе.
Теләкләр кабул булган көн
Дин-Исламның көзгесе.

# МИЛЛИ ХӘЗИНӘЛӘР

***Хәбибуллина Гөлнур Рәфкат кызы,***

***Шарифуллина Розалия Илсур кызы***

*Яр Чаллы шәһәре МБДОУ №28 “Снежинка”*

*балалар бакчасы тәрбиячеләре*

**Эшчәнлек барышы:**

**I. Оештыру өлеше.**

*Балалар бүлмәгә кереп түгәрәккә басалар.*

– Балалар, безгә бүген кунаклар килгән, алар белән исәнләшик әле.

-Эшчәнлегебезне башлаганчы, кәефләребезне күтәреп, кояш нурлары белән уйнап алыйк.

1. Кояш җылысын учыбызга җыябыз.
2. Битләребезне җылытабыз.
3. Күзләребезне сыпырабыз.
4. Үзебезне яратабыз.
5. Бер-беребезгә елмаябыз.
6. Үзебезнең яхшы кәефебез белән кунаклар белән уртаклашабыз (учларыннан өреп очыралар).

*Урындыкларга утырабыз.*

**II. Төп өлеш.**

- Балалар, мин онытып җибәргәнмен, без сезнең белән нинди Республикада яшибез? (Без Татарстан Республикасында яшибез).

- Ә безнең Татарстан Республикасында татарлар гына яшиме? (Юк, күп төрле милләт кешеләре, бик тату, дус яшиләр).

- Татарстанда нинди милләт кешеләре яши? (Татарлар, руслар, чувашлар, марийлар, башкортлар, таджиклар бар).

- Ә сез каян беләсез, аларның кайсы милләт кешеләре икәнен? ( һәрбер милләтнең үз теле бар, гореф – гадәтләре бар, үзләренә генә хас матур җырлары бар, милли киемнәре, ризыклары бар).

- Ә без бүген сезнең белән, балалар, татар милли киемнәрен, милли ризыкларын, гореф-гадәтләрен искә төшерик әле.

- Карагыз әле, балалар, кунаклар безгә күпме күчтәнәч алып килгәннәр.

*Өстәлдәге ризыкларны күрсәтү һәм әйтү. (*Өчпочмак, коймак, кыстыбый, чәк-чәк, бавырсак, вак бәлеш...)

- Болар барысы да нинди ризыклар? (татар милли ризыклары).

- Карагыз әле, балалар, менә монда нәрсәләр бар икән, карыйк әле.

*Милли киемнәр күрсәтү.*

- Алъяпкыч

- Калфак

- Читек

- Камзул

- Бала итәкле күлмәк

- Түбәтәй

- Бер сүз белән боларны ничек  әйтәбез? (Милли киемнәр).

- Әйдәгез, түбәтәй белән уйнап алабызмы?

*"Түбәтәй" уены.*

- Татар халкының бик күп бәйрәмнәре, төрле  гореф – гадәтләре дә бар бит әле, балалар.

- Әйдәгез бәйрәмнәрне дә искә төшереп алыйк әле.

*"Милли бәйрәмнәр" дигән слайдны карау.*

- Каз өмәсе – көз көне уздырыла. Бу өмәдә каз йолкыйлар.

- Нәүрүз –язны каршы алу бәйрәме.

- Сөмбелә – көз көне үткәрәләр.

- Карга боткасы.

- Сабантуй.

- Аулак өй.

- Орчык өмәсе.

- Ә менә хәзер, балалар, бу турыда сезнең әниләр нәрсәләр белә икән, әйдәгез әле аларны тыңлап үтик.

*Балалар әниләреннән алган интервьюны карау. (Видео презентация – әниләр үзләре пешерә торган милли ризык, үзләре белгән милли бәйрәм турында берничә сүз белән әйтәләр).*

- Менә миндә сезне орчык өмәсенә чакырам.

**-** Орчык өмәсенә кирәк – яракларны  барлыйк әле.

**Кызлар:** (җырлап керә):

Өмәләргә барган чакта

Энәләр онытылмасын.

Чамасын бел, күп сөйләшмә

Серләрең ачылмасын.

**-** Килдегезме, кызлар, түрдән узыгыз. Өмәбез уңышлы булсын. Бергә-бергә бик күңелле булыр әле. Әйдәгез, эш бүлешәбез.

1нче кыз. Йонны башта чистартабыз, аннары язабыз, бу эшне мин башкарам.

2 нче кыз: **Кабага** бәйләп, җепне орчыкка чорныйбыз.

3нче кыз: Орчыктан башта йомгакка чорныйбыз.

4нче кыз: Җеп ныклы, җылы булсын өчен, ике йомгакны бергә кушып катабыз.

5нче кыз: Бәйләргә җайлы булсын өчен, җепне кире йомгакка чорныйбыз.

6нче кыз: Әзер җептән оекбаш, башмак, бияләйләр бәйлибез.

Бергә: Менә бу эшләр барысы бергә орчык өмәсе дип атала.

1нче кыз: Кызлар, бер табышмак әйтәм, тыңлагыз: "Кечкенә генә карчык, зыр-зыр әйләнеп йон җыя" (орчык).

2нче кыз: *Әйдәгез "Орчык" уены уйныйбыз.* Мин орчыкны әйләндерәм, кемдә орчык туктала, шуңа җәза бирәбез *(табышмак, мәкаль әйтү, шигырь сөйләү).*

3нче кыз: Хәзер бергәләп җырлап-биеп, уйнап алыйк әле.

*Уен:"Дустым бар"(Түгәрәктә).*

- Татар халкының нинди матур бәйрәмнәре бар. Балалар, әзер җептән нәрсәләр бәйләргә була? (Оекбаш, бияләй, шарф, башмак, кофта, шапка, җиңсез).

- Ә менә бу калган йон белән без нәрсә эшләрбез икән, балалар?

- Балалар, менә хәзер әзер җепләр белән әйдәгез әле матур итеп безнең бияләйләребезне бизибезме?

Хәзер уңайлы итеп урыннарга утырып, үзегез кискән материал белән бияләй бизибез.

*Мөстәкыйль эш.*

- *Хәзер һәркем үз бияләенә парын табып парлашып басыйк әле, балалар.*

**III. Йомгаклау.**

- Балалар, ә сез үз эшегез белән канәгатьме?

- Бүгенге шөгыльдә сезгә нинди биремнәр ошады?

- Сез алар белән кем белән уртаклашырсыз?

- Ә калган йон белән без тагы нәрсә эшләрбез икән, балалар, сез өйдә уйлап килерсез яме?

# “МАЙ УНЫ”

***Гөлнәзирә Рәшит кызы Сәләхова,***

***Гөлчәчәк Садретдин кызы Галимова ,***

***Гөлия Мәгъсүм кызы Маннанова,***

***Юлия Эдуард кызы Петухова***

*Биектау районы Чернышевка*

*“Тамчы” балалар бакчасы*

*Дару үләннәре җыю йоласы сценарие*

*Безнең авылда иске стиль белән 10 нчы май көнне үлән җыю йоласы сакланган. Шул көнне җыйган үләннәрнең файдасы бар дигән ышану яши. Авыру сабыйларны элек-электән киптереп куйган май үләне суын кайнатып, шул су белән коендырып шифасын тапканнар.Төнәтмәләрен авырганда эчсәң дә, файдасы бар. Авырган терлеккә дә шул үләннәр булышкан. Бу дөреслеккә дә туры килә, чөнки май аенда үләннәрнең көче яфракларында, чәчәкләрендә була, орлыкка китмәгән була.*

(**2 хатын көтү куып кайтып килә**)

**Наилә**:  Ахирәт, нихәл, май унына барасыңмы бүген?

**Миләүшә**: Ел да барганны , ничек быел гына калыйм ди. Сөтлебикәмне дә шул май үләннәре генә коткарып калды бит. Шилә Зәйнәп аптыйдан үлән сорап йөреп булмас, үзем җыям, Алла бирсә.

**Наилә**: Мин дә бит кечкенә улым авырганда шуның шифасын таптым. Ярый, ашыга төшик, кош-кортны урнаштырыйк та, кузгалырбыз.(**китәләр)**

( ***хатыннар киләләр, араларында әбиләр , балалар да бар)***

**Әби**: Ягез, балалар, әйберләрне урнаштырыйк. Розалия, кызым, син самавырны куеп җибәр, без үләннәр җыйганчы кайный торсын.

**Розалия**: Була ул, Бибинур аптый.(**җырлый)**

Самавырны тиз кайната

Кызыл миләш күмере

Бибинур аптыебызның

Озын булсын гомере.

**Әби:** Малайлар , әүвәл үләннәр җыеп алыйк, аныңча  самавыр да кайнап чыгар. Үлән җыйганда сөйләшмибез, шуны онытмагыз.

**Миләүшә**: Сөйләшмәгәч тә ни кызыгы бар, мин сүләшмичә түзә алмыймдыр.

**Әби**: Кызыгы соңынтын булыр, тәртибе шулай. Әгүзе бисмилләне әйтеп, эчтән генә, Аллаһы тәгаләдән  саулык сорап җыйганнар элгәреләр. Без дә шулай итәрбез.( ***берсе үләнне таптап чабып уза, икенчесе туктата)***

**Резедә:** Тукта инде, Миләүшә, бөтен үләнне таптама.

**Дания** ( *кыек-мыек атлап*) Кыек-мыек атламыш,

Зачем печән таптамыш?

Келәшеский алан бит,

Яңагыңа салам бит.(*бергә көлешәләр*)

**Әби:** Яңакка салып торышлы түгел, әмма саграк атласагыз анысы мишәйт итмәс .

(*сүзсез генә җыялар, күренеш сәхнәдә булса әкрен генә дога тавышы куярга була)*

**Илсөяр**: Кызлар, булды бу!

**Гөлсинур**: Тукта, аптый дәшми бит әле бер дә

**Әби**: Җитәрлек җыйдыгызмы, кызыкайлар.

**Гөлшат**:  Җитте кебек, Бибинур аптый. Минем бөтен урамга җитәрлек булды.

**Зифа**. Әллә быел үләндә тәгәрәмибезме? Мин бит шуны ел буе шуны көттем.

**Гөлчәчәк**:  Соң тот та тәгәрә, кем мишәйтли сиңа

**Гөлшат**: И, сабырсыз инде син, Зифа, аптый әйткәнне дә көтмисең, чаптырасың гына.

**Зифа**: Чаптырмый ни, түземлегем чамалы гына шул.

**Әби**: (*көлә*) Зифа ул әнкәсе карынында да 9 ай түзеп тора алмады, 7 айдан туды. Үзем кендек әбисе булдым.

**Рузинә**:  Әле 7 аен ничек түзеп яткан диген (көләләр)

**Әби**:  Әйдә, шул хәтле түземсез булгач, Зифа, син тәгәри башла.

( *чирәмдә тәгәриләр*)

Бисмилләһи рахмәниррахим

Чирем –чорым коелсын,

Саулык бирсен, байлык бирсен,

Дөньялар  тыныч булсын!

**Розалия**:  Кызлар, самавыр кайнады, килегез!

**Римма**: Чәй дигәндә, безнең аяк идәндә!

**Миләүшә**:  Идән юк бит әле монда, кая идәнең?

**Гөлчәчәк**: Бибинур аптый, кил монда, иплерәк урынга утыр

*(утырышалар,сөйләшә-сөйләшә  табын коралар*)

**Рузинә**: Печән дигәннән , бер кызык хәл сөйләп алыйм әле сезгә. Асия аптый үлән йолкырга барган икән. Шул тирәдә ирләр дә булган.шуларның берсе, шуграгы : “Аптый. Моный бу

тимерне ирең күптән эзлидерие, алып кайт", - дип күмәсенә зурдый тимер дә салган. Иренә кирәк дигәч. Авыр булса да сөйрәп кайткан аптый. Кайткач бик зур эш кыргандай, тимерне иренә күрсәткән. Ә ул бернигә дә яраксыз, кирәксез икән(*көлешәләр*). Шулай итеп кызык ясаганнар ирләр.

**Резедә:** Әүвәле  андый кызыклар күп инде ул, койрык тагу дисеңме бер-береңә. Үпкәләмәгәннәр дә бит.

**Илсөяр:** Кече күңелле булган халык, прастуй

**Әби:** Шулай ...Малайлар, үләннәрегезне хәсиятләп киптерегез, кирәге чыгар, кыш озын, чир-чорлары да ерак йөрмәс.

**Дания**: Кая киптерергә булыр икән соң?

**Римма**:Чормада инде, тагын кая куясың аны.

**Гөлшат:** Әллә чормаңда урын беткәнме, җиләктән какыларны күп ясадың шул син.

**Дания**: Ясадым шул, әлхәмдүдилиләһи шөкер, сезгә дә авыз иттерермен әле, алла бирсә. Көнгә 2 тапкыр да бардым җиләккә. Фәрхезада аптыйны да дәшкән идем : "гады прошла" гына диде. Ул җиләк остасы ие бит элгәре.

**Румия:** Мин дә бер кызык сөйләп тә алыйм әле. Әллә иренелгән ул елны, әллә әзрәк җыелган, әллә елак кызымны коендырганда тотып бетерелгән май уны үләнен. Сыерым авырып китте бит, берни булышмый. Алай да итеп карыйбыз, болай да. Киттем Мәрфуга аптыйга. Мәйтәм шулай, шулай. Хәзер диде дә, шул арада май үләне күтәреп тә керде. Башка берни бирмә сыерыңа, түлке шуны ашат ди. Алланың рәхмәте белән, рәтләнеп китте бит малкай. И, шатланганнарым. Битонга сөт салдым да, киттем Мәрфуга аптыйга. Нихәл, рәтләндеме ди. Рәхмәт, аптый коткардың, дим. Кетер-кетер көлә. Берничә ел үткәч Мәрфуга аптый, урыны җәннәттә булсын, серне чиште бит, үзем белән алып китә алмыйм, рәнҗемә ди. Мин бик аптырап килгәнне күргәч сүшиләсеннән йомшак печән алып кереп биргән икән миңа.(көләләр) И, аптый, нинди рәнҗү мин әйтәм, сыерымны терелттең бит, минәйтәм.

**Илсөяр:** Аның гомер буе кулы җиңел булды бит.

**Гөлчәчәк**: Әле дә шундый кешеләребез бар, Аллага шөкер.

**Гөлсинур**:Җилле кешеләрнең кулы да җиңел була бит ул. Без кечкенә чакта әнкәй җиләккә аңа ияртеп җибәрә иде. Барганда чак өлгерәбез артыннан, кай арада битонын тутыра да, элдертә генә авылга. Иярсәң ияреп кайтасың, калсаң каласың гына урманда. Гонаһысына кереп булмый, үзе кузгалганда урманны яңгыратып хәбәр бирә иде "кайтабыз!" дип.

**Миләүшә:** Равия апаның да кулы да, сулышы да шифалы иде бит, сыпырып кына төшерә иде авыруыңны, әле менә шулай итеп таптап та куя иде.

**Зифа**: ( *сикереп тора, башкаларны да әйди*) Әйдә булды, сөйләп тә, ашап та туймассыз сез, шушы матур тугайда бер биеп тә аласы иде.

**Әби:**Ашка дога кылып алыйк әүвәл(*дога кылалар*)

**Илсөяр**: Биибез диден дә, гармунчы булмагач ни тулкы.

**Гөлшат**: Нишләп булмасын, самавыр торбасы ниемә ул, бер көй дә чыгармагач!

(***самавыр торбасында көй чыгарып бииләр)***

Бие, бие , бие әле
Биегәнең юк әле
Сине матур бии диләр
Биетеп карыйк әле.
Бие, бие, бие әле
Биючегә бер бәрән
Бии белмәгән кешегә
Чабатасы да әрәм

**Сания:** Кызлар , бер Зәлидә дә, әйләник әле!

(Зәлидә)

Зәлидә яңгырасын
Нурлы йөзләрең саргайган
Кем өчен кайгырасың

Әлләләлем, Зәлидә,
Гөлләләлем Зәлидә,
Чияле тау итәге,
Чияле тау итәгендә
Бергә булдык бит әле.
Сары матур,сары матур
Сары матур сайласаң,
Әллә кайлардан танырмын
Кошлар булып сайрасаң.

**Гөлчәчәк**: Ә хәзер алтылы бию!

**(Алтылы бию)**

(*кечкенә бала килә арба тартып*)

**Иркә**. Әни, әби сине дөньясын онытты, өметсез диде дә, бәбине сиңа илтергә кушты.

**Гөлшат** : И, йолдызым, ничек тартып килдең, ардыңмы.

**Иркә**: Бер дә армадым, бәби дә өйдә елады, елады да, кырга чыккач шып туктады.

**Әби**:Сәхрә килешкән инде аңа, балалар. Барыбызга да сәхрәдә булуның файдасы тисен, җыйган үләннәрнең шифасын табыгыз. Әйдәгез, булмаса, кузгалыйк өйләргә!

Алай да бергә-бергә
Болай да бергә-бергә
Безнең болай утырулар
Калсын бөтен гомергә.
Җыен гөлләр арасыннан
Яратам мин кынаны
Яратмас идем кынаны
Сезгә ошатам мин аны.
Иртән торып тышка чыксам
Урман буйлары томан
Бәлки  син дә искә алырсың
Ләкин анда мин булмам.

**Эчтәлек**

1. Гайфуллина Р.Ә. *Карга боткасы* ....................................................................................4
2. Гарифҗанова Г.Р. *Карга боткасы*.................................................................................... 11
3. Зарипова А.Р. *Нәүрүз – язгы бәйрәм* ...............................................................................20
4. Костюнина М.Н., Закирова А.Ф., Гилетдинова Р.М., Салихова Г.М. *Гаиләм моңы*.........25
5. Сәгыйдуллина Л.Р., Талипова Н.Н. *Кунак каршылау* .................................................... 30
6. Әүхәдиева Н.Ә., Галиәкбәрова А.Ф., Шәрипова Д.И. *Кода төшерү* ............................. 34
7. Загидуллина Г.Ф. *Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк* ........................................... 38
8. Латыйпова Р.Р. *Орчык өмәсе* ......................................................................................... 44
9. Шакирова Э.И., Загидуллина Г.И. *Балага исем кушу йоласы*......................................... 47
10. Шәйдуллина Л.Р., Хөснетдинова Р.А. *Бала туды-шатлык артты*..................................51
11. Якупова Г.Г. *Җитез орчык*................................................................................................54
12. Әхмәдуллина Ф.Ф. *Капка төбендә*...................................................................................57
13. Әдһәмова К.В. *Уятыйк әле, сабый күңелен*.....................................................................62
14. Сабирҗанова Г.Г. *Шыйлык бәйрәме*.................................................................................69
15. Яруллина Л.Ф. *Орлык чыгару*.........................................................................................70
16. Нуриева Г.Р. *Каз өмәсе*.....................................................................................................71
17. Хәсәнҗанова Г.Ю. *Каз өмәсе*...........................................................................................77
18. Мәҗитова Р. И., Салихова Э.Ә *Каз өмәсе*.......................................................................80
19. Рәхимова М.Р. *Каз өмәсе*.................................................................................................83
20. Гимранова Р.Г. *“Көтү чыгару” йоласы*.............................................................................84
21. Хөснетдиновна Д.Т., Кәримуллина В.Р. *Тау астында*.....................................................85
22. Гатауллина Г.Г. *“Мич котлау” йоласы*.............................................................................89
23. Әхмәтшина Ф.С. *Серле китап*...........................................................................................92
24. Абдрахманова Г.Р., Миннебанва З.Ә. *“Бәлеш пешерү” йоласы*...................................... 95
25. Гарифҗанова Л.Р., Ганиева Л. А. *Җомга көн*...................................................................97
26. Хәбибуллина Г. Р,Шарифуллина Р.И. *Милли хәзинәләр*..................................................100
27. Сәләхова Г.Р., Галимова Г.С., Маннанова Г.М., Петухова Ю.Э “Май уны”..................104

# ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН:

# ИСКӘРМӘЛӘР ӨЧЕН:

**ОНЫТЫЛЫП БАРГАН**

**ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

*Татар телендә белем һәм тәрбия бирүче тәрбиячеләр өчен, татар теле укытучылары һәм әти-әниләр өчен методик ярдәмлек*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.04.2024.
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 7.
Тиражы 100 д. Заказ

«Ихлас» нәшрияты. 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
Тел.: 89172836545
E-mail: ilfaz@mail.ru